# ШУРА

№17
2017



Корбан гаете

2000795268300

Дини альманах

1908 нче елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК


ВӘГАЗЬЛӘР

Сабырлык . . . . . . . . . . 9
Пәйгамбәрләр мәрхәмәтлелеге . . . . . . . . . . 15
Шайтанның дүрт вәгъдәсе . . . . . . . . . . 20
Ни ул гыйбадәт? . . . . . . . . . . 26
Караклык . . . . . . . . . . 31
Зәкәт (Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча) . . . . . . . . . . 38
Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көненең фазыйләтләре . . . . . . . . . . 44
Корбан гаете хөтбәләре . . . . . . . . . . 50
Корбан гаете хөтбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . 54
Беренче хөтбә . . . . . . . . . . 54
Икенче хөтбә . . . . . . . . . . 56
Корбан гаете хөтбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . 57
Беренче хөтбә . . . . . . . . . . 57
Икенче хөтбә . . . . . . . . . . 59
Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . 61
Ислам – гакыл дине . . . . . . . . . . 69
Аллаһ ризалыгы өчен син бүген нәрсә эшләдең? . . . . . . . . . . 73
Әти-әниләрнең ризалыгын алу – җәннәткә ачкыч . . . . . . . . . . 79
Гашурә көне . . . . . . . . . . 87
Исламда вәгъдә төшенчәсе . . . . . . . . . . 92

СОРАУ-ҖАВАП

Үлем түшәгендәге кеше янында үзеңне ничек тотарга? . . . . . . . 97
Вафат булган кеше алдындагы вазыйфаларыбыз . . . . . . . . . . 99
Кешегә зур күләмдә акча тиешле булсалар, ул зәкәт алырга хокуклымы? . . . . . . . . . . 100

ҮРНӘК ЗАТЛАР

Сәгъд ибн Әбү Вәккас . . . . . . . . . . 103

МӨСЛИМӘ

Бала һәм дин . . . . . . . . . . 110

ФӘН

Хәнәфи мәзһәбенең барлыкка килүе һәм таралуы . . . . . . . . . . 117

Җәһәннәм мәңгелекме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Коръән турында гыйлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
«Рисәләи-нур» хәрәкәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

МИРАС
Мәрҗанинең хаҗ сәфәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Пәйгамбәрләр тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Некролог, яки кыскача сийр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Алуши-Ибраһимов Ризван (1883-1938) . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

ТАРИХ
Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт . . . . . 179
«Ислам баласы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190

НӘСЫЙХӘТ
Дингә карата ник җавапсызбыз? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Тәүбә. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204

ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА
Гает намазы ни рәвешле кылына? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216

КОРБАН
Корбанның мәгънәсе һәм тарихы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Корбан чалуның әһәмияте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223

ХАҖ
Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хаҗы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
Пәйгамбәребезнең ﷺ саубуллашу хөтбәсе. . . . . . . . . . . . . . . . . 238

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Муса Акъегет «Хисаметдин мелла». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 242

**«ШУРА» дини альманах, №17**

июль – сентябрь 2017
шәүвәл 1438 – мөхәррам 1439

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 нче елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 нче елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
12+

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 264-64-19 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Нияз Сабиров
Илдус Фәиз
Фәрид Сәлман

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП:**
Лилия Ильясова
Телефон: +7 (843) 202-07-74

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ӘДӘБИ РЕДАКТОР:**
Рәмзилә Шафикова

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 202-07-74
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

Типографиянең адресы:
«Комбинат программных средств» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.
420044, Казан ш., Ямашев проспекты, 36 Б
Тел./факс: +7 (843) 519-91-10
Сайт: http://kpkps.ru/

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 22.06.2017
График буенча: 22.06.2017

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим**

**Әс-сәләмү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәракәтүһ!**

Хөрмәтле дин кардәшләр, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән сезне, туганнарыгызны һәм кардәшләрегезне Корбан гаете – Гыйд әл-әдха белән тәбрик итәргә рөхсәт итегез! Аллаһы Тәгалә барыбызның да изге гамәлләрен кабул итеп, гыйбадәтләребез өчен савапларын арттырса һәм чиксез рәхмәте илә ике дөнья сәгадәте насыйп итсә иде! Зур бәйрәмебез имин булсын, һәр өйгә куанычлар, тынычлык, мул тормыш һәм Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алып килсен.

Корбан – Аллаһ безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән сансыз нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү. Изге Коръәндә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»** – диелгән.

«Кәүсәр», 108:2

Корбан бәйрәме – җәмгыятебез өчен дә файдалы бәйрәм, чөнки корбан итенең өчтән ике өлеше ятимнәргә, мохтаҗларга, фәкыйрьләргә, күршеләргә таратыла. Гает көне туганлык, кардәшлекне ныгыта, шәфкатьле, юмарт һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан китерелгән хайванда, аның итендә түгел, ә күндәмлек күрсәтү, тәкъвалык һәм диндарлыкта яшерелгән. Коръәндә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ كَذَٰلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ ۗ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ ﴿٣٧﴾

**«Чалган корбаннарыгызның итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, ләкин сездән Аллаһыга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер,»** – диелгән.

«Хаҗ», 22:37

Ел да корбан чалу – ул Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсыну һәм гыйбадәт хакына бар милкеңне корбан итәргә әзер булуның символик чагылышы.

Башка аятьтә:

وَلِكُلِّ أُمَّةٍ جَعَلْنَا مَنسَكًا لِّيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَىٰ مَا رَزَقَهُم مِّن بَهِيمَةِ الْأَنْعَامِ ۗ فَإِلَٰهُكُمْ إِلَٰهٌ وَاحِدٌ فَلَهُ أَسْلِمُوا ۗ وَبَشِّرِ الْمُخْبِتِينَ ﴿٣٤﴾

**«Барча мөэмин җәмәгате өчен корбан чалырга урын кылдык ягъни хаҗга бармаган мөэминнәр өйдә корбан чалырлар, Без аларга биргән дөя, сыер, куйларны корбан итеп чалганда Аллаһ исемен зекер итсеннәр. Сезнең Илаһыгыз ялгыз бер Аллаһ. Аңа итагать итегез, ә син (Мөхәммәд) ихлас мөэминнәрне җәннәт белән шатландыр»,** – диелгән.

«Хаҗ», 22:34

Корбан гаете бар дөньядан миллионлаган хаҗилар Хаҗ гыйбадәтен үтәгән вакытка туры килә. 2017 елда 20 меңнән артык Россия гражданнары, бу дөньяның мәшәкатен онытып, Раббыларының әмерен үтәргә һәм Аның рәхмәтенә ирешергә омтылып, изге җиргә юнәлер. Аллаһы Тәгалә аларның гыйбадәтләрен кабул итсә һәм туган җирләренә исән-сау кайтып җитәргә насыйп итсә иде.

Бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ: «Аллаһы Тәгалә каршында иң яхшы көн – ул Корбан гаетенең беренче көне», – дигән.

Гает намазында янәшәбездә төрле шәһәр, ил, кыйтгалардан килгән мөселманнар, һәм, тышкы кыфәтләребез, телләребез, тән төсебез төрле булуга карамастан, без терәлеп торабыз, бер-беребезгә сәлам җиткерәбез, бер Аллаһка бергәләп гыйбадәт кылабыз.

Раббыбыз шушы көнне ихластан дога кылырга, корбан китерергә, рухи тынычлык алып, Аның мәрхәмәтенә ирешергә насыйп итсә иде.

Аллаһы Тәгаләдән безгә бәхет, сәламәтлек, илебезгә һәм Татарстан Республикасына тынычлык, иминлек, муллык һәм үсеш сорыйм. Гает мөбарәк булсын!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөселманнарының*

*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

# Вәгазьләр

*14 июль вәгазе,*

*Шәввәл аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Сабырлык

Барча мактау-шөкерләребез Аллаһ Тәгаләгә булса иде. Аның хак хәбибе Мөхәммәдкә ﷺ күңелләребезнең түрләреннән чыккан салаватларыбыз ирешсә иде. Аллаһ Тәгалә һәрберебезнең дә тәннәребезгә сәламәтлек, ил-көннәребезгә тынычлык, күңелләребезгә мәгърифәт нурлары салып, тормышларыбызга бәрәкәт биреп, Үзе риза булырлык гамәлләр кылырга насыйп әйләсен.

Аллаһ Тәгалә безне һәрберебезне сабырлыкка өндәп: «Сабыр булыгыз, Аллаһ Тәгалә сабыр булган коллары белән бергә була», – ди.

Шулай ук:

وَاسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلَاةِ ۚ وَإِنَّهَا لَكَبِيرَةٌ إِلَّا عَلَى الْخَاشِعِينَ ﴿٤٥﴾

**«Авырлыкны күтәрергә чыдамлы булып, ягъни сабыр килеш вә намаз укып Аллаһтан ярдәм сорагыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:45

Аллаһ Сөбханә вә Тәгаләдән ярдәм сорыйсыз икән, ул вакытта, мөселман кардәшләрем, сабырлык белән һәм шулай ук догалар, намазлар белән Аллаһ Тәгаләдән берәр нәрсәне сорагыз.

«Сабыр төбе – сары алтын» ди татар халкы да, ягъни ниндидер авырлык килеп, мусыйбәтләр килеп, аларга түзә алсаң, сиңа хәерле булыр, ди.

Хәзрәти Госман ؓ: «Нинди генә авырлыклар килсә дә, нинди генә мусыйбәтләр килсә дә, түзегез, сабыр булыгыз, тешегезне кысыгыз. Бу Аллаһ Тәгаләнең бер рәхмәте, бер бәрәкәте. Ул сезгә шуңа карап игътибар итә», – дип әйткән.

Аллаһ Тәгалә Үзе дә әйтә:

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٥﴾

**«Дөреслектә, файдалы булган җиңеллек авырлыктан соң».**

«Инширах / Ачмак», 94:5

Һәм тагын бер кат әйтә:

إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ﴿٦﴾

**«Дөреслектә, авырлыктан соң гына файдалы җиңеллек табыла».**

«Инширах / Ачмак», 94:6

«Инширах» сүрәсендә ике тапкыр кабатлап куя: авырлыктан соң җиңеллек килә, сабыр булыгыз, ди. Андый кешеләр белән Мин янәшә торам, ди.

Әюб ﷺ тормышына күз салыйк әле. Ул Аллаһ Тәгаләгә шуның кадәр күп итеп гыйбадәт кыла торган кол иде, ки, беркөнне шайтан Аллаһ Тәгалә каршына килеп басып:

– Я Раббым, миңа шушы ихлас колыңны туры юлдан саташтырырга рөхсәт ит әле, – ди.

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә ихлас булырга чакыра. Ихлас булсагыз, сезгә шайтанның солтанаты, ягъни хөкеме җитмәячәк, сезне адаштыра алмаячак, ди.

Әюб ﷺ белән дә шулай ук. Аның тормыш рәвеше һәр кешегә таныш. Аллаһ Тәгалә биргән ризыктан төрле-төрле җирләргә, төрле-төрле хәерчеләргә, мескеннәргә, ярлыларга үзе капчык-капчык ризык өләшә торган булган. Үзе дә ярлы булган бер бәндә иде, хәерле вәгазе өчен аңа бер солтан бераз җир һәм терлек биргән була. Аның байлыгы бик тә ишәеп

китә. Шайтан Аллаһ Тәгаләдән рөхсәт алгач, Әюб ﷺ янына килеп, аның игеннәрен яга.

Шайтан Әюбне эзләп тапканда, ул мәчеттә Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылып утыра иде. Ул бер карт рәвешендә Әюб ﷺ янына килә дә:

– Әй Әюб, синең анда барлык игеннәрең дә янып бетте. Харап булды! Харап булдың бит, инде хәзер ни эшләрсең? – дип фетнә чыгара башлый.

Әюб ﷺ намазыннан сәлам әйтеп чыга да:

– Йә Раббым, шөкер, өстемнән бер йөкне төшердең. Минем һаман да зикер кылган вакытта, игеннәрем нишли икән, дип бер фикер туып ала иде. Күңелемне бераз гына борчып, Сиңа зикер кылудан тыеп тора иде, – дип Аллаһка дога кылган.

Болай да булмагач, Шайтан икенче көнне Әюбнең ﷺ барлык терлекләренә мур (холера) җибәрә, барчасы да егылып үлә. Кабаттан Әюб ﷺ янына бара, һәм ул, гадәттәгечә, мәчеттә намаз укып утырган була. Йөгереп килеп:

– Эһ Әюб, харап булдың, харап булдың, анда бөтен терлекләреңә мур төште: сарыкларың да, сыерларың да егелып үлде бит, – дип фетнә чыгара башлый.

Әюб ﷺ кабаттан намазыннан сәлам әйтеп чыга да:

– Йә Раббым, шөкер, өстемдәге бу йөкне дә алып шатландырдың мине. Мин бит Сиңа тагын да ныграк гыйбадәт кыла алам, – дип, шатланып дога кыла башлый.

Шайтан кызып чыгып китә. Өченче көнне ул Әюбнең балалары җыелган өйгә килә. Бер баласының туган көне була, һәм балалар гына җыелып, туган көнен үткәрә торган булганнар. Шулвакыт шайтан болар өстенә йортның түбәсен төшерттерә. Бер генә баласы да исән кала алмый, һәм шайтан кабат мәчеткә йөгереп китә. Әюбнең ﷺ намаз укыган вакытына туры килә, һәм сәлам биргәнен көтеп, артында тыз-быз йөри башлый. Сәлам бирүен күргәч тә:

– Харап булдың, ий Әюб, харап булдың! Балаларыңның өстенә түбә җимерелеп төште, барысы да һәлак булды. Нинди кайгы, нинди хәсрәт, – дип, янәдән фетнә чыгармакчы була.

– Йә Раббым, шөкер, мин гыйбадәт кылган вакытта, ничек кенә гаиләмне туендырырмын, тәэмин итеп торырмын икән, дигән фикерләр килеп китә иде. Хәзер Син андый фикердән дә азат иттең, йә Раббым, рәхмәт Сиңа, – дип дога кыла Әюб ﷺ.

Моны күреп, шайтан аның йөзенә төкерә, һәм шул төкеректән аның йөзендә ниндидер җәрәхәтләр пәйда була. Бераздан соң Әюбнең ﷺ тәне чери башлый, кортлап, начар исләр чыга башлый. Күрше-күләмнәре: «Тормасын безнең янда, әйдәгез читкә, авыл читенә чыгарып куйыйк», – дип аннан ерагая башлыйлар. Хатыннарының берсе генә, Рокыя исемлесе генә кала, калганнары шулай ук ташлап китәләр. Әюбне чүплек янына чыгарып аталар. Берүзе, ашарына юк, ә ул: «Аллаһка шөкер», – дип дога кыла. Үзенең сабырлыгын җуймый, киресенчә, тагын да күбрәк шөкер итә башлый.

Бервакыт хатыны Рокыя, аңа ипи сыныклары алыр өчен, үзенең чәчләрен кисәргә була. Бу вакытта чәч кисү – урам хатыны булу дип саналган. Әюб ﷺ, сәбәпнең нидә икәнен дә белмәве бар, үзе сәламәтләнгәч, Рокыяне кыйнарга нәзер әйтә. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә аңа катырак сынау бирә: бөтен тәне череп бетә. Кортлар бөтен тәнен ашап бетереп, ике генә корт кала – берсе телендә, берсе йөрәгендә. Шулвакыт Әюб ﷺ Аллаһ Сөбханә вә Тәгаләгә дога кыла:

– Йә Раббым, минем йөрәгем белән телемне булса да ашатма, йөрәгем ашалса, ничек зикер кылырмын, телем ашалса, ничек тәсбих әйтермен соң?

Шул кортларның берсе умарта кортына әверелә, берсе – сөлеккә, ягъни файда китерүче кортларга алышыналар. Аллаһ Тәгалә Җәбраил ﷺ

аша аңа шифа җибәрә, аякларыннан чишмә чыгып, шул сулар сәбәпле Аллаһ Тәгалә дәвасын бирә һәм Әюб ﷺ сәламәтләнә.

Онытмагыз, авырлыктан соң җиңеллек килә. Нинди генә авырлык, мүсыйбәт килсә дә, сынма, сабыр бул. Аллаһ сабыр булучылар белән икәнен онытма, ий мөселман кардәшем!

Рәнҗетсәләр дә, мыскыл итсәләр дә, телеңне Әбү Бәкер кебек тешләп тор. Ачлык-ялангачлык, нинди генә бүтән төр галәмәт килсә дә, безнең әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз кебек сабыр булыйк. Нинди тормыш кичергән кешеләр алар да: ачлыкны үткәргәннәр, бер сынык ипигә канәгать булганнар. Өч-дүрт балага бер ыштан, бер күлмәк, мәктәпкә бара алмаслык дәрәҗәдә аякларына да юк иде. Аллаһ Тәгалә ташламас диделәр, Аллаһ Тәгалә ташламады. Менә бүгенге көнгә карыйк әле: нинди авырлыктан соң җиңеллек килде. Аллаһка шөкер, нинди гүзәл заманда яшибез бит.

Тагын бер мәсьәлә – нәзер мәсьәләсе бар. Аллаһ Тәгалә Әюбкә нәзере турында исенә төшерә: «Сәламәтләнгәч хатынымны кыйныйм», – дигән идең, хәзер нәзереңне үтә», – дип әйтә. 10 чирәмне өзеп, бер тапкыр сугарга куша Аллаһ Тәгалә. Монда да ике төрле мәсьәлә: берсе – нәзерне тоту, икенчесе – үз әһеленә кул күтәрмәү.

Күргәнебезчә, бар җирдә дә сабыр булырга кирәк. Гыйбадәттә 5 вакыт намаз укыйбыз, авыр булса да, аннан аерылма, картайгач, я урын өстенә калгач кына, сабыр булып урын өстендә укырсың. Сабырлык белән үзеңнең уразаларыңны тот, сабырлык белән зикер-тәсбихләреңне кыл, сабырлык белән Коръән укы, сабырлык белән кешеләргә изгелек эшлә.

Сабырлык белән, мөселман кардәшем, икенче мөселманга ихтирам күрсәт, күрше-күләмнәрең белән яхшы мөгаләмәдә бул. Күршеләрнең дә төрлесе була бит: яхшылары, явызлары. Нинди генә явыз күршеләрең булмасын, аларга карата ихтирамлы бул. Сине мыскыл итеп, сүгеп, кешеләргә синең турында начар итеп сөйләп йөрсә дә, аңа кадер-хөрмәт

күрсәт. Пәйгамбәребез ﷺ үз күршеләренә карата иң күркәм холык мисалын күрсәткән кеше. «Мин инде күршеләремнең минем мирасыма балаларым кебек хаклары бар кешеләр кебек күрә башлаган идем», – дип әйтә ул.

Кадерле кардәшләр! Һәр囲 эштә, һәр җирдә сабыр булырга тырышыйк. Үзебезгә йөкләнгән вазыйфаны сабыр булып үтә, үзебезнең өйдә чыккан ызгышларга, күршеләр тарафыннан чыккан сүзләргә – барысына да сабыр булып, Аллаһка шөкер итәргә тырышыйк. Бу – Ислам диненең төп асылы, нигезе. Аллаһ Тәгалә безнең халкыбызга, милләтебезгә, бабаларыбызга зур сабырлык биргән.

Аллаһ Тәгалә барыбызга да күркәм сабырлык биреп, Үзенең каршысына изге гамәлләребез белән басып, Үзенең йөзен күрергә насыйп әйләсә иде.

*Илдус хәзрәт Фәиз,*
*«Болгар» мәчете имам-хатыйбы*

*21 июль вәгазе,*

*Шәвввәл аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

## Пәйгамбәрләр мәрхәмәтлелеге

Галәмнәрне юктан бар итеп, безне төрле нигъмәтләр белән нигъмәтләндерүче Аллаһ Раббыбызга дан-мактауларыбыз булса иде. Бу дөньялыкка җибәрелгән соңгы расүл Мөхәммәдкә ﷺ күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Без, кардәшләрем, үзебезнең бу дөньяда бер кунак икәнебезне бөтенебез дә беләбез һәм аңлыйбыз, бу дөнья бер сынау мәдрәсәсе икәненә төшенәбез һәм бу дөньядагы һәр нигъмәт безгә вакытлыча бирелгәнен дә беләбез. Беләбез, әмма без бу дөньяда яшәгәнгә карап, дөньяга күп алданабыз, без һаман да канәгать түгел, булган саен безгә тагын да күбрәк кирәк. Үзебезнең төп максатыбызны онытабыз. Ә нәрсә соң безнең төп максат? Төп максатыбыз – Аллаһ Раббыбызга гыйбадәт кылу, Расүлебез ﷺ сөннәте белән яшәп, кешелек дөньясына Аллаһ ризалыгы өчен хезмәт итү. Коръән һәм сөннәт белән яшәүне, кайвакыт, күп мөселманнар фәкать бер формаль рәвештә генә аңлый, әмма бу төшенчәләр бик киң мәгънәгә ия: Ислам сүзе «сәлам» сүзеннән килеп чыга. Димәк, тынычлык тарату, мәрхәмәтлелек тарату. Әгәр пәйгамбәрләр тарихына карасак, алар бу дөньяда нинди генә авырлыклар күрмәгәннәр, әмма кешелек сыйфатын югалтмый яшәгәннәр. Сабыр булганнар, юмартлык һәм изгелек орлыгы чәчкәннәр. Пәйгамбәрләр тарихын бәян иткәндә, Аллаһ Раббыбыз кайбер пәйгамбәрләрнең гүзәл тормышларын сөйләп, матур һәм күркәм тормыш итүләрен сөйли, ә кайбер пәйгамбәрләрнең кыйссаларын аз бәян кыла яки бөтенләй дә бәян итми. Тик шулай да Аллаһ Тәгалә изге китапта бик күп вакыйгаларның иңдерелү сәбәбен аңлатып бирә. Бу хакта Аллаһ Тәгалә әйтә:

أُولَٰئِكَ لَمْ يَكُونُوا مُعْجِزِينَ فِي الْأَرْضِ وَمَا كَانَ لَهُم مِّن دُونِ اللَّهِ مِنْ أَوْلِيَاءَ ۘ يُضَاعَفُ لَهُمُ الْعَذَابُ ۚ مَا كَانُوا يَسْتَطِيعُونَ السَّمْعَ وَمَا كَانُوا يُبْصِرُونَ ﴿٢٠﴾

**«Расүлләр хәбәрләреннән хикәя итсәк, һәрберсендә синең күңелеңдә сабит булырга кыйссалар иңдерәбез, вә ошбу сүрәдә сиңа хак хәбәрләр вә мөэминнәргә вәгазь һәм гыйбрәтләр килде».**

«Һуд», 11:120

Пәйгамбәрләр күп авырлыклар күреп, төрледән-төрле сынауларга дучар булып, сабырлык белән җиңеп, ике дөнья дәрәҗәсенә ирешәләр. Кайсы гына пәйгамбәрне алсак та, кыйссалары гаҗәпләнерлек. Раббыбыз безгә аларның ничек итеп тәүбә кылуларын һәм башка гыйбадәтләрен дә нәсыйхәт итеп бәян итә. Коръән Кәрим китабында нәкъ тә менә бүгенге җәмгыятькә җитми торган игътибар, үзара аңлашу һәм мәхәббәт урын алган. Сөләйманга ﷵ Аллаһ Раббыбыз бик күп нигъмәтләр биреп олылый вә патша дәрәҗәсен дә бирә. Әле алай гына да түгел, хайваннарны, җеннәрне аңа буйсындыра. Аллаһ Тәгалә Сөләйманга ﷵ хикмәт бирүе хакында болай ди:

وَوَهَبْنَا لِدَاوُودَ سُلَيْمَانَ ۚ نِعْمَ الْعَبْدُ ۖ إِنَّهُ أَوَّابٌ ﴿٣٠﴾

**«Вә Без Даудка Сөләйманны һибә кылдык, нинди хуш бәндәдер ул Сөләйман, ул һәрвакыт тәүбә-тәсбих илә Аллаһка кайтучыдыр».**

«Сад», 38:30

Бер вакыт ул үзенең гаскәре белән барганда, бер кырмысканың үз кабиләсенә мөрәҗәгать иткәнен ишетә. Корьәндә Раббыбыз ул вакыйганы шулай бәян итә:

حَتَّىٰ إِذَا أَتَوْا عَلَىٰ وَادِ النَّمْلِ قَالَتْ نَمْلَةٌ يَا أَيُّهَا النَّمْلُ ادْخُلُوا مَسَاكِنَكُمْ لَا يَحْطِمَنَّكُمْ سُلَيْمَانُ وَجُنُودُهُ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ ﴿١٨﴾ فَتَبَسَّمَ ضَاحِكًا مِّن قَوْلِهَا وَقَالَ رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَىٰ وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَدْخِلْنِي بِرَحْمَتِكَ فِي عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ ﴿١٩﴾

**«Сәфәрендә бер кырмыска чокырына җиткәндә, кырмыскаларның патшасы Сөләйман гаскарен күреп әйтте: «Ий кырмыскалар, Сөләйман гаскәре белән килә, тапталырсыз, алар сезнең тапталганыгызны сизмәсләр, өйләрегезгә кереп качыгыз», – дип. Сөләйман кырмысканың сүзеннән елмаеп көлде һәм әйтте: «Ий Раббым, үземә вә ата-анама биргән нигъмәтләреңә шөкер итәргә миңа илһам бир, дәхи Син риза була торган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир, һәм рәхмәтең белән мине изге бәндәләрең арасына керт!»**

«Нәмел / Кырмыска», 27:18-19

Аллаһ иңдергән китапта безгә менә шушындый кыйссалар бар. Бу – безнең өчен, кардәшләрем, зур нәсыйхәт, шушы кыйссадан без пәйгамбәрләр кешелек дөньясына гына түгел, һәр җан иясенә мәрхәмәтлелек кылганнарын күрәбез.

Пәйгамбәребез ﷺ бер хәдисендә миграҗда булганда, җәһәннәмдә бер хатынны күрүе хакында әйтә, ул хатынның ни сәбәпле шушындый хәлгә төшүе белән кызыксына һәм җавап ала: бу хатын мәчесен бикләп

куя һәм аңа ашарга бирми. Мәче ачтан үлә вә шул сәбәпле бу хатын җәһәннәмгә керә.

Бу кыйссалар, меңләгән кыйссаларның аз гына өлешедер, чөнки Аллаһ Тәгалә безгә һәр эштә сабырлык, йомшаклык һәм акыл белән эш йөртүне йөкли. Расүлебез хакында да бит Аллаһы Тәгалә Коръәндә түбәндәгечә әйтеп аңлата:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللَّهِ لِنتَ لَهُمْ ۖ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ ۖ فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ ۖ فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ ﴿١٥٩﴾

**«Ий Мөхәммәд, Аллаһның рәхмәте белән өммәтеңә шәфкатьле булдың, әгәр каты күңелле булсаң, әлбәттә, синең тирәңнән качар иделәр...»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:159

Сабыр һәм аек акыл белән эш итү – ул пәйгамбәрләр сыйфаты. Кайберләре үз кавемнәрен бик күп еллар дәверендә дингә чакырганнар, халыклар нинди генә кабахәт эшләр эшләсәләр дә, Аллаһтан аларга кичерү сораганнар, сабыр итеп, хикмәт белән өндәгәннәр. Мескеннәргә һәм ятимнәргә карата яхшы мөгамаләдә булганнар.

Пәйгамбәребез тагын бер хәдисендә: «Җәннәткә йөрәкләре, ягъни күңелләре кошларныкына охшаган кешеләр керер», – дип әйтә.

Имам Нәвәви бу хәдискә шәрехендә кошларныкы кебек күңел – ул йомшаклык, ягъни мәрхәмәтлелек, ди.

Газиз дин кардәшләрем, бу вакыйгалар һәм кыйссалар безнең өчен меңнән бер үрнәк кенә. Әгәр дә без Раббыбыз күрсәткән шушындый кыйссаларны санасак, безгә берничә том язарга кирәк булыр иде. Бу вәгазьдә мин, әлбәттә, бик кечкенә өлешен генә яза алдым, әмма шушы өлешне генә дә, яхшылап уйлап, үзебезнең калебләребезне пәйгамбәрләр

кебек йомшатырга тырышсак, Аллаһның рәхмәте белән, тирәбездәге тормышыбыз бик күпкә яхшы якка үзгәрер. Аллаһы Тәгалә сөйләүчегә дә, тыңлаучыга да шушы сөйләнгәннәр белән гамәл кылырга насыйп әйләсә иде. Әмин!

*Алмаз Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең*
*яшьләр эше буенча урынбасары*

*28 июль вәгазе,*

*Зөлкагдә аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Шайтанның дүрт вәгъдәсе

Бөтен галәмне юктан бар кылучы, тәрбия кылучы Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнә мактауларыбыз булса иде. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә илләребезгә һәм көннәребезгә хәерле иминлекләр, тынычлыклар, авыруларга хәерле шифалар, тәүфыйксызлыкта, намазсызлыкта, динсезлектә йөрүчеләргә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә тәүфыйк-һидият (туры юлга керүчеләргә хас сыйфатлар: күркәм әдәп-тәрбия, яхшы әхлак), истикамәтләр (турылык, намуслылык, дөрес юнәлеш) насыйп кылса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ күңелләребезнең түреннән чыккан салаватшәрифләребез, догаларыбыз ирешсә иде.

Мөхтәрәм газиз кардәшләрем, җомга көннәребез мөбарәк булсын! Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә ике җомга арасында вафат булган мөселман кардәшләребезнең рухларына догаларыбызны ирештерсен иде. Ике җомга арасында никахлашкан яшьләребезнең Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә күңелләренә өлфәт-мәхәббәт салып, мәхәббәтләрен дәвамлы кылып, алардан туган балаларны да Ватаныбызга, динебезгә, милләтебезгә игелекле, файдалы балалар насыйп кылса иде.

Аллаһ Тәгалә шайтанны җәннәттән җиргә төшергәч, шайтан Аллаһка дүрт вәгъдә бирде.

Бу вәгъдәләр «Нисә» сүрәсенең 119 аятендә килә.

Беренче вәгъдәсе:

وَلَأُضِلَّنَّهُمْ ... ﴿١١٩﴾

**«Мин аларны хак юлдан аздырырмын».**

«Нисә / Хатыннар», 4:119

Ягъни Аллаһның диненнән аздырырмын, артларыннан, алларыннан, сулдан, уңнан килеп вәсвәсә кылырмын, хак юлдан аздырырмын, диде. Вә ни гаҗәп, ул үзенең шул вәгъдәсен бүгенге көнгә кадәр үтәргә тырыша. Инде ничә мең ел узды, ә ул һаман үзенең мәкерле эшен дәвам итә. Моның дәлиле – «Йәсин» сүрәсенең 61-62 аятьләре:

وَأَنِ اعْبُدُونِي ۚ هَٰذَا صِرَاطٌ مُّسْتَقِيمٌ ﴿٦١﴾ وَلَقَدْ أَضَلَّ مِنكُمْ جِبِلًّا كَثِيرًا ۖ أَفَلَمْ تَكُونُوا تَعْقِلُونَ ﴿٦٢﴾

**«Ий Адәм балалары, Мин сезгә шайтанга гыйбадәт кылмагыз дип гәһед кылмадыммы һәм белдермәдемме, вә аның сүзе белән йөрмәгез, әлбәттә, ул сезгә ачык дошмандыр. Сез Миңа гына гыйбадәт кылыгыз: «Миңа гына гыйбадәт кылу һәм Мин күрсәткән юлдан гына бару – шулдыр туры юл», – дип әйтмәдемме? Тәхкыйк, ул шайтан сездән бик күпләрне адаштырды, аздырды, шуны уйлап карамыйсызмы?»**

«Йәсин», 36:61-62

Дөреслектә, безнең хакыйкый дошман – ул шайтан, шуңа күрә Аллаһ Тәгалә бу аятьнең мәгънәсендә: «Миңа гына гыйбадәт кылыгыз, минем генә динем, юлым хак, шайтанның вәгъдәләренә алданмагыз, вәсвәсәләренә бирелмәгез, мине зикер кылыгыз, менә бу инде дөрес юл булыр», – дип әйтә.

Шуннан соң Аллаһ Тәгалә: «Шайтан күпчелек халыкны адаштырды», – дип әйтә, ягъни күпчелек халык адашуда, ди Раббыбыз. Әгәр дә уйлансаң, безнең халыкта шундый сүз бар: «Күпчелек кеше мәчеткә йөрми, күбесе шулай яши, күбесе шулай эшли, бөтен кешегә намаз укырга димәгән бит, шулай булгач, күбесе дөрес түгел дип әйтеп булмый

бит, – дип әйтәләр. Әмма Раббыбыз: «Күпчелек – адашуда», – дип әйтә. Бүгенге көн статистикасы буенча, җир йөзендә җиде миллиардка якын кеше яши, шуның миллиард ярымына гына Аллаһ Тәгалә мөселман булу бәхетен насыйп итте. Тузан бөртеге хәтле генә иман, ихласлык булган кешеләрне сайлап алды. Аллаһ Тәгалә «Әл-Әграф» сүрәсенең 179 аятендә безгә әйтә:

وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِّنَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ ۖ لَهُمْ قُلُوبٌ لَّا يَفْقَهُونَ بِهَا وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَّا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَّا يَسْمَعُونَ بِهَا ۚ أُولَٰئِكَ كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ ۚ أُولَٰئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ ﴿١٧٩﴾

**«Тәхкыйк, кешеләрдән вә җеннәрдән күпләрне җәһәннәм өчен бар иттек, аларның гакыллары бар, ләкин хакны аңламыйлар, аларның күзләре бар, ләкин гыйбрәтләрне күрмиләр, аларның колаклары бар, ләкин Аллаһ сүзләрен ишетмиләр, алар хайван кебекләр, бәлки хайваннарга караганда да файда белән зарарны аера алмауда гакылсызраклар, чөнки бер хайван да утка керми, ә динсез кешеләр утка керергә хәзерләнәләр. Алар камил гафилләр, үз киләчәкләрен һич тә уйлап карамыйлар».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:179

Бу аятьтән аңлашылганча, халыкның күпчелеге җәһәннәмгә барыр, чөнки күпчелеге дөнья ләззәтен сайлады. Шайтан шушы дөньяны шул кадәр бизәде, хәтта кешеләр шушы дөнья максатыннан башка бер мәгънә күрмиләр. Кызганыч, әмма мөселманнар арасында да адашкан кешеләр аз түгел, төрле фиркаларга бүленеп, намазның, доганың, зикернең ләззәтен югалтып, дөньяны сөеп яшиләр. Дөреслектә, хөрмәтле мөселман кардәшләрем, гыйбадәтнең ләззәтен, күңел белән дөньядан ваз кичмәсәк, татып булмый!

Икенче вәгъдәсе. Коръәндә әйтелә:

وَلَأُضِلَّنَّهُمْ ... ﴿١١٩﴾

**«күңелләренә төрле батыл, ялган сүзләрне салырмын».**

«Нисә / Хатыннар», 4:119

Ягъни бу тормышка зур өметләр баглап, хыял белән генә яшәрләр: зур кеше булырмын, күп байлык җыярмын, дип. Кызганыч, бүгенге көндә əти-əниләр балаларын кечкенәдән үк шул хыял белән яшәргә, шул дөньяның дәрәҗәсенә ирешергә өндиләр. «Математиканы, физиканы, рус телен яхшы итеп укы, үскәч зур кеше булырсың, җитәкче, банкир булырсың, ә дин, мәчет юлы нәрсәгә инде ул сиңа, карьераны үстерергә кирәк, дип балаларын диннән ерагайталар. Дөньяви гыйлемне алмагыз дип әйтә алмыйм, киресенчә, дөньяви гыйлем дә, дини гыйлем дә бертигез булырга тиеш, рухи кыйммәтләрне онытырга ярамый, чөнки ул бердәнбер бәхет вә котылу юлы.

Өченче вәгъдәсе. Коръәндә әйтелә:

... وَلَآمُرَنَّهُمْ فَلَيُبَتِّكُنَّ آذَانَ الْأَنْعَامِ ... ﴿١١٩﴾

**«янә хайваннарыгызның колакларын кисегез, дип әмер бирермен».**

«Нисә / Хатыннар», 4:119

Гарәпләр пәйгамбәрлек килгәнче шушы төр хайваннарны олылаганнар. Әгәр дә аларда биш дөя туып, дүртесе ана дөя булып, берсе ата дөя туса, шул ата дөягә тимәгәннәр, итен ашамаганнар, башкалар белән бер көтүгә чыгармаганнар: «колакларын кисегез вә моңа гыйбәдәт кылыгыз», – дип әйткәннәр.

Дүртенче вәгъдәсе. Коръәндә әйтелә:

... وَلَآمُرَنَّهُمْ فَلَيُغَيِّرُنَّ خَلْقَ اللَّهِ ۚ ... ﴿١١٩﴾

**«янә Аллаһ төзегән мәхлукларны үзгәртегез, дип әмер бирермен».**

«Нисә / Хатыннар», 4:119

Ягъни, «Аллаһ халык кылган нәрсәләрне үзгәртергә әмер итәм». Хәсән Әл-Басри дигән галим: «монда тәндәге рәсемнәр турында сүз бара», – дип әйтә Ә икенче галим «Рум» сүрәсенең 30 аятен китерә:

فَأَقِمْ وَجْهَكَ لِلدِّينِ حَنِيفًا ۚ فِطْرَتَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا ۚ لَا تَبْدِيلَ لِخَلْقِ اللَّهِ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٣٠﴾

**«Йөзеңне бер Аллаһның диненә юнәлт, кешеләрне шул ислам диненә яраклы итеп төзеде, ягъни кешеләрне Аллаһ ислам дине өчен генә халык кылды, димәк кешенең чын кеше булуы ислам дине беләндер, югалган кешелекне исламнан табып алыгыз! Аллаһның диненә үзгәрү юктыр, бу ислам дине гаять туры, гаять көчле, Кыяматкә чаклы каим диндер, ләкин күбрәк кешеләр исламның хаклыгын белмиләр».**

«Рум», 30:30

Һәм болай дип әйтә: «диннәрен үзгәртерләр, дингә яңалыклар кертерләр». Әгәр дә игътибар итеп карасак, бүгенге көндә ирләр белән хатыннар үзләренең җенси агзаларын да үзгәртәләр – монысы инде бөтенләй бернинди канунга сыймый.

Күргәнебезчә, Шайтан үз максатларына иреште, үз вәгъдәсендә тугрылык күрсәтте, ә без аңа каршы нәрсә эшлибез?

Аллаһ Тәгалә аятьнең азагында әйтә:

وَمَن يَتَّخِذِ الشَّيْطَانَ وَلِيًّا مِّن دُونِ اللَّهِ فَقَدْ خَسِرَ خُسْرَانًا مُّبِينًا ﴿١١٩﴾

**«Берәү Аллаһ хөкемнәрен куеп, шайтан хөкемнәренә иярсә, аны үзенә вәли итеп алса, дөреслектә, ул кеше ачык һәлак булу белән һәлак булды, мәңгегә хәсрәттә калды».**

«Нисә / Хатыннар», 4:119

Аллаһ Тәгалә безне шайтанның зарарыннан, вәсвәсәсеннән саклап, Аллаһка гына гыйбадәт кылып, Аңың рәхмәтенә ирешергә насыйп кылса иде.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Галиев» мәчете имам-хатыйбы,*
*МДН Дәгъвәт бүлегенең баш белгече*

*4 август вәгазе,*

*Зөлкагдә аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Ни ул гыйбадәт?

Безләрне юктан бар иткән, халык кылган Аллаһ Тәгаләгә хәмед вә сәнәләребез булсын. Хак хәбибе, расүлүллаһ Мөхәммәдкә дә салават шәрифләребез булса иде.

Безнең җаныбыз, тәнебез кебек үк, ризыкка мохтаҗ, тик бу ризык – рухи ризыктыр. Бу рухи ризык – иманыбыз һәм гыйбадәт кылу. Аллаһка гыйбадәт кылу күңелләрне йомшарта, гөнаһлы гамәлләр кылудан читкәрәк этәрә һәм, иң мөһиме, иманыбызны саклый.

Гыйбадәт кылу тәнебезгә дә файда бирә: намаз алдыннан тәһарәт алабыз, ә ул, үз чиратында, тәнебезгә чисталык бирә. Вакытында 5 вакыт намазны укып барсаң – ул да безгә физик активлык бирә. Ураза тоту – ашказаны өчен файдалы һ.б. Бервакыт, остаз булган кешедән: «нәрсә соң ул гыйбадәт?» дип сораганнар. Ул исә:

– Гыйбадәт – ул Аллаһ яраткан вә разый булган барлык гамәлләрдер: сүзләр булсынмы, ачык вә ябык (кеше күрмәгән) кылына торган гамәлләр булсынмы – болар барысы да гыйбадәттер, – дип җавап кайтарган.

Бүгенге көндә бик күп тапкырлар:

– Әнә, мәчетеңдә гыйбадәт кылып утыр инде шунда;

– Мәчет карты кебек йөрисең инде.

Йә булмаса:

– Гел гыйбадәт кылып кына, тамак туйдырып булмый шул, – кебек сүзләр ишетергә мөмкин.

Әлбәттә, муллалар турында 19 гасыр ахырларыннан вә 20 гасыр башларыннан калган гыйбарәләр бу сүзләрне әйттерә дә. Аштан ашка йөрер өчен генә мулла булмаганнардыр да, әмма әдәбият битләрен ачып

карасаң, анда муллалар укымышсыз, ишаннар – хатын-кызлар артыннан гына чабып йөри торган, гарәп сүзләрен әйткән булып, үзләреннән галим кыяфәте чыгарып йөриләр, дип язалар. Бу әсәрләрдә хакыйкать юктыр дип әйтә алмыйбыз, әмма шул әсәрләр белән «тәрбияләнгән» буын киләчәк буынга дин турында бер генә җылы сүз дә җиткермәс шул. Берәр эшне эшлисе килмәсә, өйдә тизрәк нинди гыйбарәне әйтәбез? Искә төшерегез әле, бөтен кеше яратып әйтә торган сүз: «Син дә мулла, мин дә мулла – атка печән кем сала?»

Мәкаль-әйтемнәрне халык педагогикасы, милли педагогика диләр. Балаларны тәрбияләгәндә дә озын итеп вәгазь укыганчы, бер кыска гына мәкаль әйтеп, аның күңеленә тәэсир ясыйлар. Хәзер күз алдыгызга китереп карагыз: бу әйтемне кем генә белми, кем генә кулланмый икән? Ә башка бер кергәнне тиз генә чыгарып атып булмый. Без, хәтта мөселманнар да, шул ук сүзне әйтмибезме? Уйнап булса да әйткәләп, бер-беребезне көлдереп куйгалыйбыз. Мулла, хәзрәт, имам – болар мәчет хезмәткәрләре булып халыкка кереп калган. Аларның төп эше – мәчеттә утыру, гыйбадәт кылу. Әйтерсең лә бу электрик, экономист, хирург кебек бер профессия гына. Һәм хәзрәтнең вазыйфасы мәчетендә утырырга, биш тапкыр азан әйтергә, исем кушарга һәм башка шундый гамәлләр эшләргә тиеш сыман.

Бу вәгазьнең язылу сәбәбе дә башкада иде. Без сезнең белән гыйбадәт сүзенең мәгънәсен карый башладык. Алдагы мисаллар барысы да халкыбыз өчен гыйбадәт сүзе нәрсә аңлатканын бәян итте. Ислам динендә исә гыйбадәт кылу 3 төрле була ала:

**– Тән белән, ягъни кешенең үзе нидер эшләве**

Намаз уку, ураза тоту. Бу гыйбадәтне һәр кеше үзе башкарырга тиеш һәм бүтән кешегә йөкләргә тиеш түгел, ягъни үзең өчен башка кешегә намаз укырга кушарга ярамый.

**– Мал-мөлкәт белән гыйбадәт кылу**

Бу төр гыйбадәткә сәдака, зәкәт бирү, корбан чалу керә. Бу очракта кемдер аша эшләсәң дә була, мәсәлән, сәдаканы бүтән кеше аша биреп була.

**– Мөселманның үзе һәм мал-мөлкәте белән гыйбадәт кылуы**

Бу төр гыйбадәткә хаҗ кылу, гөмрә кылу кебек гамәлләр керә. Бу очракта безнең мал да тотыла, тәнебез белән дә гыйбадәт кылабыз.

Бу – һәр кешегә таныш гыйбадәт төрләре дип әйтсәк, ялгышмабыз, ләкин, кадерле дин кардәшләрем, тагын нинди гыйбадәт төрләре бар соң? Күп кеше өстәрәк санап кителгәннән артык гыйбадәт төрен әйтә дә алмас.

Вәгазебезнең башында гыйбадәт – Аллаһ кабул кыла торган гамәлләр, дип әйттек. Аны тулырак карар өчен гыйбадәт сүзенең нәрсә аңлатканын карап үтик. Гарәп телендә гыйбадәт сүзе «буйсыну», «кол булу», «тыйнак булу» кебек мәгънәләргә ия. Кол булу дигән сүз күп кешеләрне уйландырып куярга мөмкин. Аллаһ Тәгаләгә кол булу һәм үзеңә тиң кешегә кол булу – икесе ике нәрсә. Аллаһ Тәгаләгә кол булу, ягъни Җиһанны бар кылган, барча галәмнәрне барлыкка китергән, ә шул галәмнәр арасында – син дә бар кылынган, ошбу Җир шарын, суларны, һаваны барлыкка китергән Раббының кушканнарын үтәү вә тыйганнарыннан тыелу буладыр.

Аллаһка кол булу – хактыр, чөнки без Аның хөкеме астында һәм Аңа кайтабыз.

Аллаһка кол булу – көчтер, чөнки барча фәрештәләр, мәхлүкләр, күкләр һ.б. – болар барысы да Аллаһка буйсынганнар.

Аллаһка кол булу – дәрәҗәдер, чөнки бу – Кыямәт көнендә зур әһәмияткә ия булачак, кеше дә шуның белән горурлана алачак.

Аллаһка кол булу – тынычлыктыр, чөнки Аллаһка гына кол буласың, ә бу дөньяның колы булсаң, син теге кешегә дә, бу кешегә дә ярарга тырышып, тормышыңны тыз-быз чабып йөрүгә корачаксың.

Аллаһка кол булу – намуслылык һәм абруйдыр, чөнки гыйбадәт кылу әхлаклыкны, әдәплелекне саклый. Ә кем дә кем үзенең нәфсенең колы

була – аңа бернинди дә чикләр куелмый. Ул үзенең дәрәҗәсен дә, намуслылыгын да онытып, хайван дәрәҗәсенә төшә ала, Аллаһ сакласын.

Аллаһка кол булу – зур бәхеттер, чөнки Аллаһның җәннәтенә Аның ихлас колларыннан башкалар кермәс һәм җәһәннәмнән алардан башка беркем дә саклана алмас.

Кадерле дусларым, һәрбер кеше, Аллаһка ышанамы ул, юкмы, Аның колы булып санала. Ул һәр кешене барлыкка китерүче, аларның җаннарына, тәннәренә хуҗа булучы, аларның тормышлары белән идарә итүче. Һәр кеше Ул барлыкка китергән галәмдә яши, һәм, иң мөһиме – без барыбыз да бу галәмне Аллаһ Тәгалә барлыкка китергәненә инанган затлар. Һәм соңыннан үлеп, барыбыз да Аның хозурына кайтачакбыз.

أَفَغَيْرَ دِينِ اللَّهِ يَبْغُونَ وَلَهُ أَسْلَمَ مَن فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ طَوْعًا وَكَرْهًا وَإِلَيْهِ يُرْجَعُونَ ﴿٨٣﴾

**«Бит җирдәге вә күкләрдәге һәрбер мәхлук теләп һәм теләмичә дә Аллаһка итагать итәр. Вә барчалары да Аллаһка кайтырлар».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:83

Аллаһ Тәгалә Үзе моны «теләмичә итагать кылу» дип атады, шуңа күрә, кадерле мөселман кардәшләрем, без сезне теләп итагать итүгә чакырабыз. Бу очракта, гыйбадәт кылучы мөселман кешесе Аллаһның Барлыкка китерүче, безнең Хуҗабыз икәнен, Аңа гына итагать итәргә тиешлеген үзе аңлый, һәм боларны теләп башкара.

Гыйбадәт сүзе «кол» дигәнне дә аңлата, дип әйттек. Гадәттә, коллар үз хуҗаларына ниндидер бер эштә генә, яисә көннең аерым бер өлешләрендә генә буйсынып яшәмиләр. Шуның кебек, мөселманнар да, үзләренең Аллаһка буйсынуларын тәүлек дәвамында өзмичә башкаралар, ягъни «мәчет эчендә мин гыйбадәт кылам, урамга чыккач – мин гади кеше» дигән фикер бер генә мөселманда да юк.

Аллаһ Тәгалә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Кеше илә җенне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым»,** – ди.

«Зарият / Таратучы», 51:56

Безнең барлыкка китерелүнең төп сәбәбе – Аллаһка гыйбадәт кылу, Аңа кол булу, әйткәнебезчә, көне буе гыйбадәт кылу. Өстәрәк санап киткән дәлилләр, аргументлар безгә гыйбадәтнең асылын аңларга ярдәм итә:

– гыйбадәт – төгәл вазыйфалар: намаз, хаҗ, ураза һ.б;

– гыйбадәт – Пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтләрен үтәү;

– гыйбадәт – гөнаһлы нәрсәләрдән тыелу: хәмер эчү, гайбәт тарату, ялганлау, рәнҗетү, мыскыллау, урлау, кеше үтерү һ.б;

Гыйбадәт – Аллаһ риза булган һәр гамәл, ягъни берәр яхшы эш алдында бисмилләһне әйтеп эшли алсак, бу да гыйбадәт була. Иртән торып тешләрне чистарттың, берәр кешегә карап елмайдың, мохтаҗга булыштың, эшеңдә үз вазыйфаңны төгәл һәм ихлас башкардың – болар барысы да гыйбадәт. Гаиләңне тәэмин итү, балаларыңны дөрес тәрбияләү, күршеләрең, туганнарың белән яхшы мөгаләмәдә булу – бу да гыйбадәт. Онытмыйк, мәчеттән чыккач та, без мөселман булып калабыз, мөселман кардәшләр яныннан киткәч тә, без мөселман булып калабыз, ә димәк, Аллаһның колы булып калабыз, шуңа күрә гомеребез буе Аллаһка гыйбадәт кылабыз булып чыга.

Аллаһ Тәгалә һәрберебезне Үзенең ихлас колларыннан кылып, Үзенең җәннәтендә очраштырырга насыйп әйләсен.

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

*11 август вәгазе,*

*Зөлкагдә аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Караклык

Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмед-сәнә, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафага ﷺ күңелебезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде. Раббыбыз Аллаһның әмерен үтәп, җомга намазына килгән мөэмин-мөселман кардәшләрем, әс-сәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Һәрберебезгә дә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримнең «Мәидә» сүрәсенең 38 нче аятендә әйтә:

وَالسَّارِقُ وَالسَّارِقَةُ فَاقْطَعُوا أَيْدِيَهُمَا جَزَاءً بِمَا كَسَبَا نَكَالًا مِّنَ اللَّهِ ۗ وَاللَّهُ عَزِيزٌ حَكِيمٌ ﴿٣٨﴾

**«Карак ир һәм карак хатыннарның кәсеп иткән явыз эшләренә Аллаһтан җәза йөзеннән кулларын кисегез. Аллаһ үч алуда көчле һәм гадел хөкем итүче.»**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:38

Адәм баласын иманнан яздыра торган зур гөнаһларның да иң зурысы, җәмгыять өчен иң зарарлысы – караклык, угрылык белән шөгыльләнү. Караклык – кеше әйберен, зурлыгына карамыйча, рөхсәтсез алуны аңлата. Бүгенге җәмгыятьнең көнкүрешендә урлау, бер-берсен алдау шул кадәр гадәти хәлгә әйләнде ки, караклык, алдау белән шөгыльләнмәүчегә гаепле кешегә караган кебек карап, «булдыксыз, кәсеп итә белмисең, заманча яшәргә кирәк», дип түбәнсетеп көлә башладылар.

Кеше малын хәрам юллар белән үзләштерү, гөнаһлы гамәлләр икәнлеген, Аллаһ Тәгалә тарафыннан ләгънәт кылынганлыгын берәүләре белмәсәләр, икенчеләре битарафлык күрсәтерләр.

Сөекле Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Урлаган кешеләрне Аллаһ Тәгалә ләгънәт кыла».

Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә «Ән-Нисә» сүрәсенең 29 нчы аятендә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُم بَيْنَكُم بِالْبَاطِلِ إِلَّا أَن تَكُونَ تِجَارَةً عَن تَرَاضٍ مِّنكُمْ ۚ وَلَا تَقْتُلُوا أَنفُسَكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا ﴿٢٩﴾

**«Ий мөэминнәр! Үзара малларыгызны хыянәт, золым юллар белән ашамагыз, мәгәр риза булган хәлдә сәүдә белән кәсеп итеп ашагыз»,** – ди.

«Нисә / Хатыннар», 4:29

Кайберәүләр кешедән бурычка алып, бурычын кайтарырга мөмкинлеге булса да, бурычын бирми. Икенче берәүләр урлауның төрле ысулларын эзлиләр. Болар өчен кеше, әлбәттә, Кыямәт көнендә җавап бирәчәк.

Гобәдә бин Сәмит ﷺ риваять итә: Расүлуллаһ ﷺ болай дип әйтте: «Килегез һәм Аллаһтан башка беркемгә һәм бернәрсәгә дә гыйбадәт кылмаска, урлашмаска һәм зина кылмаска, балаларыгызны үтермәскә, йөрәкләрегез уйлап чыгарган ялганны таратмаска, шәригатьтә дөрес булган нәрсәләрдә минем сүземнән чыкмаска миңа ант итегез. Бу антны тотучыны Аллаһ бүләкли, әгәр берәрегез антын бозса, бу дөньяда җәзасын ала һәм бу җәза кәффарәт түләү була, ә инде берегез антын бозып, Аллаһ Тәгалә аны капласа, Аллаһ Тәгалә Үзе карар кабул итә: теләсә җәзалый, теләсә аны гафу итә»[1].

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: Мина үзәнлегендәге беренче ант – Гәкабәдә турында.

Гәкабәнең икенче анты турында Җәбир ؓ әйтүе буенча риваять ителгән хәдистә дә: «... шәригатьтә дөрес булган нәрсәне эшләргә һәм шелтәле нәрсәләрдән тыелырга... Моның әҗере сезгә җәннәт булыр», – дип сөендерә Пәйгамбәребез ﷺ.

Күп кешеләр Кыямәт көне турында исләреннән чыгаралар. Урланган мөлкәтне хуҗаларына кайтарып, хуҗасы урлаучыны гафу итсә генә, Аллаһ Тәгалә дә гафу итәчәген оныталар.

Динебездә башка берәүнең, мөселманмы яки мөселман булмавына карамастан, малын-мөлкәтен урлау катгый тыелган. Сүземне вәгаземнең башындагы аятькә, ягъни Коръәни Кәримнең «Мәидә» сүрәсенең 38 нче аятенә кайтарам:

وَالسَّارِقُ وَالسَّارِقَةُ فَاقْطَعُوا أَيْدِيَهُمَا جَزَاءً بِمَا كَسَبَا نَكَالًا مِّنَ اللَّهِ ۗ وَاللَّهُ عَزِيزٌ حَكِيمٌ ﴿٣٨﴾

**«Карак ир һәм карак хатыннарның кәсеп иткән явыз эшләренә Аллаһтан җәза йөзеннән кулларын кисегез. Аллаһ үч алуда көчле һәм гадел хөкем итүче».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:38

Динебездә караклык юкка гына ләгънәт кылынмаган. Әлбәттә, каракның кулын кисү җәзасын, аның гаебен раслаган очракта гына, шәригать мәхкәмәсе карары белән, шәригать кануннары белән яшәгән җәмгыятьтә генә кулланалар. Кеше хәтта бер карандаш урласа да, әгәр дә җинаятьтә тотылса, аның да җәзага тартылуын Аллаһы Тәгалә Үзе таләп итә. Күршенең генә түгел, башка кешенең дә бакчасында үскән бер җимешне рөхсәтсез алсаң, ул да караклыкка керә.

Беркөнне Мөхәммәд Мостафа ﷺ янына урлашканда тотылган бер хатын китерелә һәм бу хатынга җәза бирү карары кылына. Бу хатын мәшһүр Корәеш кабиләсеннән була. Аның туганнары килеп (алар арасын-

да хөрмәт казанган затлар да була), бу хатын өчен шәфәгать кыла башлыйлар. Аларга җавап итеп Пәйгамбәребез ﷺ: «Ий кешеләр! Бу дөньядан яшәп киткән кавемнәр тик шул сәбәптән һәлак булганнар: аларның зыялылары бер нәрсә урласа, аны җибәргәннәр, зәгыйфьләре урлашса, аңа җәза биргәннәр. Аллаһ белән ант итәм! Мондый эшне кызым Фатыйма эшләгән булса, һичшиксез, аның кулын да кистергән булыр идем,» – дип әйткән.

Кешеләр бер-берсеннән шикләнеп, караклардан саклану йөзеннән фатирларга икешәр кат тимер ишекләр, тәрәзәләргә тимер рәшәткәләр куеп бетерделәр. Видеокүзәтүләр, әллә нинди саклану чаралары күрелсә дә, караклар барыбер керәчәкләр. Ошбу кабахәт җаннар Аллаһ Тәгаләнең йорты булган мәчетләрнең ишекләрен, тәрәзәләрен ватып кереп, булган әйберләрне урлый башладылар.

Раббыбыз Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең әмерен ишетеп, Аның рәхмәтенә ирешер өчен диеп җомга намазына килгән мөселман кардәшләребезнең кесәләреннән әйберләрен урлыйлар. Бер угры, бүтәнчә булдыра алмагач, куртка өстеннән куртка киеп киткән. Аллаһы Тәгаләдән курыкмаган, Аллаһының рәхмәтеннән ерагайган! Аллаһның ләгънәте булган имансызлар гына болай эшли ала.

Бик күп кешеләр ислам дәүләтләрендә каракларга карата шундый каты җәза бирүне аңламыйлар, үзләренең ахмаклыклары аркасында Аллаһ Тәгаләнең хөкеме һәм әмере белән килешәселәре килми, янәсе караклык кылган кешенең кулларын кисү – урта гасырдан калган кыргый гадәт дип, үзләренә җиңеллек эзләп, җаваплылыктан качып, акланмакчы булалар. Бүгенге көндә кемнәргә Аллаһы Тәгаләнең боерыклары караклык-угрылык кылырга комачаулый?! Әлбәттә инде, караклыкка – халыкны талау юлына баскан, караклык белән шөгыльләнгән кешеләргә комачаулый. Әгәр дә безнең илебездә, мөселман илендәге кебек, кеше әйберен урлаган өчен, каракларның кулларын киссәләр, иманым ка-

мил, берәү дә кеше малын, кеше әйберен урламас иде. Фатирларны басып йөрүче дә, машина ишекләрен җимереп талаучы да, бакчаларда күп хезмәт түгеп үстергән җиләк-җимешләрне урлаучы да, үлчәгәндә ким үлчәүче дә, сатканда бәясен тиешледән артык куючы да булмас иде: илебездә тәртип булыр иде. Бүгенге көндәге кебек күп санда милиция һәм суд хезмәткәрләрен тотарга да кирәк булмас иде. Төрмәләр дә бушап калыр иде. Үз чиратында төрмәдә бушка дәүләт җилкәсен, халык байлыгын күсе кебек кимереп ятучылар да булмас иде. Аллаһы Тәгалә чыгарган хөкемнәрне үтәп яшәүдән халыкка, дәүләткә күпме файда, чөнки Раббыбыз Аллаһ үзенең хөкемнәрен хикмәт белән билгеләгән. Каракны төрмәгә утыртып кына урлашудан котылып булмый. Төрмәдән иреккә чыккан кеше барыбер урлау кәсебенә тотыначак.

Мөселманнар ни өчен урлашудан ерак торалар? Урлаган өчен кул киселүдән курку гына түгел, ә төп сәбәбе – Аллаһ Тәгаләдән курку, Аллаһ Тәгаләнең хәерле рәхмәтеннән мәхрүм калудан курку – мөселман кешене урлашудан тыелырга мәҗбүр итә. Хәләл кәсепкә, хәләл малга кызыктырып, Ислам дине кешеләрнең холыкларын, намусларын тәрбияли.

Ни өчен соң кайберәүләр караклык белән көн күрә? Җавабы бик гади: карак ач яки ярлы булганы өчен түгел, ә ачкүзлелектән, комсызлыктан, эшләмичә баерга, башкалар хисабына яшәргә омтылудан урлый. Ул үзенең шул кабахәт чире белән җәмгыятьнең тынычлыгын бетерә, кешеләрне дә үзләренең хәләл юл белән тапкан малларын тынычлап файдаланудан мәхрүм итә.

Ислам динен тотмаучы АКШның Йель университеты психиаторлары тикшерүләрдән соң, кул кисү куркынычы – кешеләрне урлашудан туктата дигән нәтиҗә чыгарганнар.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Кем үзенеке булмаган әйберне минеке дип дәгъва кыла, ул кеше бездән түгел, үзенә җәһәннәмдә урын хәзерләсен».

Кеше әйберен үзләштерүче – мөселман түгел, ә җәһәннәмгә керергә хәзерләнүче булып чыга. Икенче бер хәдистә: «Берәү, урланганлыгын белә торып та, шул әйберне сатып алса, ул хурлыкка калуда һәм гөнаһлы булуда урлаучының тиңдәше булыр»[1], – диелгән.

Урлаучы да, урланганын белә торып, әйберен сатып алучы да җәһәннәм утына ризык булалар икән.

Имам Әгъзам хәзрәтнең әтисе Сәбит хәзрәт егет чагында, суда агып килгән алманы алып тешләгәне өчен дә, алманың хуҗасын бәхилләтер өчен, өч ел хезмәтче булып эшләргә риза була.

Локман Хәким дә: «Кеше кулындагыга кызыкма. Кирәк әйберне иң элек Аллаһтан сора, Ул бер хәерле бәндәсе аркылы сиңа сәбәбен чыгарыр һәм син сөенеч табарсың, теләгеңә ирешерсең», – дип әйткән.

Бервакыт чүлдә яшәүче гарәпләргә Англия илчесе килә. Үтеп барышлый бер өй алдында күп акча ятканын күрә, ә янәшәдә беркем дә булмый. Аптыраганнан йортка кереп хуҗага: «Сездә караклар юкмы әллә?» – дип сорау бирә. Ә йортның хуҗасы: «Юк, бездә каракларның кулларын кисәләр!» – дип җавап кайтара. Илче исә: «Нинди кыргыйлык!» – дип әйткәч, гарәп кешесе сорау бирә: «Дөресен генә әйт әле: сезнең илегездә көненә ничә кеше урлашкан өчен җавапка тартыла?» Илче исә: «Иң кимендә, 50 кеше», – ди, ә гарәп: «Ә бездә 40-50 елга бер мәртәбә генә каракның кулы киселде», – дип җавап бирә.

Коръәндә болай диелә:

فَمَن تَابَ مِن بَعْدِ ظُلْمِهِ وَأَصْلَحَ فَإِنَّ اللَّهَ يَتُوبُ عَلَيْهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣٩﴾

**«Берәү, угрылык кылып, золым иткәннән соң, тәүбә итсә, алган малны иясенә тапшырса һәм бөтен эшен төзәтсә, Аллаһ**

[1] «1001 хәдис»-782

**тәүбәсен кабул итеп, гөнаһын ярлыкар. Аллаһ, әлбәттә, ярлыкаучы һәм рәхимле».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:38

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә барчабызны да кеше малына кызыгудан, кеше малына кул сузудан сакласын. Нәфесебезнең хуҗасы булып яшәргә насыйп әйләсен. Әмин!

*Равил хәзрәт Нуруллин,*

*Яр Чаллы шәһәре «Туфан» мәчете имам-хатыйбы,*

*Аксакаллар шурасы рәисе*

*18 август вәгазе,*

*Зөлкагдә аеның 26 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Зәкәт (Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча)

Галәмнәрне, безне юктан бар итеп яратучы, безгә бу дөньяны бүләк итүче Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмде-сәнәләребез, барча мактауларыбыз булса иде. Аның сөекле бәндәсе, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд Мостафага салават-шәрифләребез булса иде. Мөхтәрәм дин кардәшләребез, әс-сәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам дине 5 баганага нигезләнгән[1]:

1. Аллаһтан башка һичбер иләһ булмавына вә Мөхәммәд ﷺ Аның расүле икәненә шәһадәт китерү.
2. Намаз уку.
3. Зәкәт бирү.
4. Рамазан аенда ураза тоту.
5. Хаҗ кылу.

Күргәнебезчә, намаздан соң Аллаһ Тәгалә тарафыннан мөселманнарга фарыз кылынган гамәлләрнең берсе – зәкәт. Аллаһ Тәгалә Үзенең китабында бик күп тапкыр зәкәт турында искә төшерщә[2]:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ ... ﴿٤٣﴾

**«...Намазларыгызны үтәгез, зәкәтләрегезне түләгез».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:43

Аллаһы Тәгалә Коръәндә зәкәт түбәндәгеләргә бирелер ди: беренчесе – зәкәт бирерлек нисабка ия булмаган фәкыйрьләргә. Нисабка

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 «Бәкара» / «Сыер», 2:43; «Бәйинә» / «Аңлатма», 98:5 һ.б.

килгәндә, без аны ничек аңларга тиеш? Кеше бай булуының шартлары бар. Динебездә мин бай дигән сүз ул, әгәр дә алтын белән исәпләсәк, 85 грамм алтының булса. Бүгенге көндә якынча 198 мең сум акчасы булса, ул нисабка ия кеше, бай кеше булып санала.

Икенчесе – зәкәт бернәрсәләре дә булмаган мескеннәргә бирелер. Димәк, беренчесе фәкыйрьләр булды, икенчесе – мескеннәр. Мескеннәр – ул бернәрсәләре дә булмаган, йортларында бернинди уңайлыклар, шартлары булмаганнар.

Өченчесе – зәкәт җыючы махсус кешеләргә бирергә, диелгән.

Дүртенчесе – мүаләфәи кулүб. Бу – Ислам диненә әле генә килгән, әмма йөрәкләре Исламда әле ныгымаганнар. Пәйгамбәребез ﷺ вакытында ганимәтләрдән кайбер сәхабәләргә әзрәк бирелгән, әмма яңа гына дингә килгән сәхабәләргә күбрәк бирелгән. Алар нәкъ мү’әлләфәтүлкулүб. Шундыйларга да зәкәт тиешле.

Алдагысы – коллыктан котылырга теләүче кешеләр. Безнең җирлектә бүгенге көндә андыйлар инде юк.

Алтынчы – бурычын түли алмаучы кешеләргә. Аларга шулай ук зәкәт бирелергә тиеш.

Җиденче – Аллаһ Тәгалә юлында йөрүчеләр.

Сигезенче – юлда, сәфәрдә акчасыз калучыларга. Алар мөселман булса – зәкәт бирелә. Мөселман булмаса ярдәм итәргә мөмкинме? Әйе, ярый. Бу сәдака булып саналачак, ин шә Аллаһ. Сәдаканы без көн саен бирә алабыз, ә зәкәт елына бер бирелә.

Зәкәтне кем бирергә тиеш? Ул кеше:

1. Мөэмин мөселман булырга.
2. Үз акылында булырга, ягъни мәҗнүн түгел.
3. Балигълык яшенә җиткән булырга.
4. Ирекле булырга.

5. Матди яктан хәлле булырга тиеш, ягъни бурычларыннан кала мал-мөлкәте билгеле нисаб күләменә ия булырга тиеш. Нисаб турында алдарак әйтеп узган идек – 85 грамм алтын, безнең акчалар белән – якынча 198 мең сум.

Бу нисаб турында тулырак әйтсәк, шушы 85 грамм алтын күләмендәге мал – ул акча яисә берәр төрле товар рәвешендәге булган мал була ала. Мәсәлән, кемнеңдер 500 меңлек товары булып, бер ел үтеп, бу мал артса, ул бу малдан 2,5 %, ягъни кырыктан бер өлешен зәкәт итеп түләргә тиеш.

Тагын бер очрак – ул терлек тоту. Мәсәлән, берәр кеше сарык тотса, ул зәкәтне сарыклар белән түләргә тиеш. Әгәр сарыклар 40-тан ким булса, зәкәт түләнелми. Әгәр сарыклар саны ел дәвамында 40-120 җитсә – 1 сарык, 120-200 җитсә – 2 сарык түләнелә. Бу шулай ук кәҗәләргә дә кагыла.

Сыер тота икән, ул очракта, әгәр 30-дан ким булса, зәкәт түләнелми, әгәр 30-дан 39-га кадәр булса, ул чакта 2 еллык бозау белән түләнелә, әгәр 40 булса, 3 еллык бозау белән түләнелә.

Җир зәкәте дип нәрсәне атыйлар? Бу – алынган уңыштан зәкәт. Сугару ысулыннан чыгып, булган уңышның 1/10 яки 1/20 өлеше зәкәт итеп түләнелә. Әгәр чәчүлек яңгыр суы белән һәм җир асты сулары белән сугарылса – 1/10 өлеше, әгәр ясалма юл белән сугарылса, уңышның 1/20 өлеше түләнелә. Икенче төрле без аны гошер сәдакасы дип йөртәбез. «Гошер» сүзе гарәп телендәге гәшәра – ун – санныннан чыккан. Мисалга, 10 капчык бәрәңгенең 1 капчыгын без гошер сәдакасы итеп бирергә тиешлебез.

Зәкәт биргәндә ният белән бирергә кирәк, шуңа да һәрбер сәдака бирүне зәкәт дип әйтеп булмый. Кайбер кеше «мин бит инде көн саен мәчеткә сәдака биреп торам», дип, ялгыша. Зәкәт нәкъ «зәкәт бирәм» дигән ният белән, алда санап киткән сыйныфларга кергән кешеләргә бирелә. Бу категория кешеләрне Аллаһ Тәгалә «Тәүбә» сүрәсенең 9 нчы

аятендә әйтеп үтә, шуңа күрә зәкәт бары тик кулдан-кулга бирелергә тиеш. Мәчет тартмасына зәкәт дип салынган акча шунда югалачак та.

Тагын бер сорау: зәкәт бирүне кемнәрдән башларга кирәк? Алар:

1. Бертуган кыз һәм ир кардәшләр, аннан соң аларның балалары.

2. Әти ягыннан абый-апа, аннан соң әни ягыннан абый-апалар.

3. Якын туганнар.

4. Фәкыйрь күршеләр.

Әгәр безнең күршеләр фәкыйрь икән, Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә бездән: «Син бай идең, ашарыңа-эчәреңә булды, әмма күршеңдә ризык булмады, син аңа булыштыңмы?» – дип сораячак.

5. Үз районыңда, мәхәлләңдә яшәүче мохтаҗлар.

6. Үз шәһәреңдә (район, авыл) яшәүче мохтаҗларга зәкәт түләнергә тиешле. Ягъни шушы тәртиптән түләнә башланырга тиеш.

Ә зәкәт кемгә бирелми соң? Соңгы арада ошбу сорау күпләрне борчый башлады. Кадерле мөселман кардәшләрем, зәкәт түбәндәге кешеләргә түләнелми:

1. Әти һәм әнигә.

2. Әби белән бабайга (дәү әни, дәү әти).

Ни өчен аларга зәкәт түләнелми? Әти-әни – алар безнең иң якын кешеләребез, без аларны гомеребез буе карарга тиешбез. Бер тапкыр зәкәт биреп, «калганын үзегез карагыз инде», – дип әйтү динебездә дөрес түгел. Аларны тәрбияләп, карап тору гел безнең өстебездә булырга тиеш.

3. Үзеңнең улыңа, кызыңа, аларның балаларына.

4. Матди яктан хәлле булган кешеләргә.

5. Мөселман булмаган кешеләргә. Мөселман булмаганнарга зәкәт бирелми, ә сәдака итеп бирелә.

6. Үзеңнең хәләл җефетеңә, ягъни ире бай булып, хатынына зәкәт бирә алмый, шулай ук хатыны бай булып, иренә бирә алмый.

7. Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәзрәтләре һәм аның гаиләсенә.

8. 7 яшьтән кече балаларга.

9. Психик авыру кешеләргә зәкәт бирелми.

Мөмкинчелекләре булып та, зәкәт түләмәнгән кешенең хәле нинди? Бу сорауга Аллаһ Тәгалә «Тәүбә» сүрәсендә җавап бирә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّ كَثِيرًا مِّنَ الْأَحْبَارِ وَالرُّهْبَانِ لَيَأْكُلُونَ أَمْوَالَ النَّاسِ بِالْبَاطِلِ وَيَصُدُّونَ عَن سَبِيلِ اللَّهِ ۗ وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللَّهِ فَبَشِّرْهُم بِعَذَابٍ أَلِيمٍ ﴿٣٤﴾ يَوْمَ يُحْمَىٰ عَلَيْهَا فِي نَارِ جَهَنَّمَ فَتُكْوَىٰ بِهَا جِبَاهُهُمْ وَجُنُوبُهُمْ وَظُهُورُهُمْ ۖ هَٰذَا مَا كَنَزْتُمْ لِأَنفُسِكُمْ فَذُوقُوا مَا كُنتُمْ تَكْنِزُونَ ﴿٣٥﴾

**«Янә бар шундый кешеләр: алтын вә көмешне җыеп асрарлар, Аллаһ юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетүче газаб булачагы турында хәбәр бир. Кыямәт көнендә җыйган ул алтын-көмешләре җәһәннәм утында кыздырылып маңгайларына, вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз».**

«Тәүбә», 9:34-35

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Зәкәт бер һиҗри ел үтмичә, зәкәт малыннан алынмый». Без исә зәкәтне еш кына Рамазан аенда бирергә тырышабыз. Ни өчен? Чөнки Рамазан аенда Аллаһ Сөбханү вә Тәгалә эшләгән һәрбер гамәл өчен калган айлардагы фарыз әҗерен бирер, ди. Рамазан ае үтү белән, шәүвәл аеның беренче көнендә, ураза гаете намазы укылганчы, зәкәтнең бер төре булган сәдака – фитыр сәдакасы бирелә. Ибн Гомәрдән килгән хәдистә Пәйгамбәребез ﷺ әйткән:

– Ураза гаете көнне, бәйрәм намазына чыгар алдыннан, мөселман булган һәркемгә – колга һәм ирекле кешегә, ирләргә һәм хатын-кызларга, олысына һәм кечесенә – бер сагъ[1] хөрмә, яки арпа күләмендә сәдака өләшү фарыз итеlә[2].

Кадерле дин кардәшләрем, зәкәт – Исламның 3 нче баганасы булып тора. Әгәр зәкәт түләнелмәсә, Аллаһ Тәгалә яңгырларны туктатыр; Кыямәт көнендә ул байлык елан булып килер. Шулай ук, зәкәтне биргәндә бары тик сыйфатлы маллардан гына бирергә онытмыйк. Аллаһ Тәгалә һәрберебезгә ихлас мөселманнардан, Үзенең яраткан колларыннан булырга насыйп әйләсен иде.

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*

*«Зәкәт» хәйрия фонды җитәкчесе*

1 Сагъ – үлчәү берәмлеге, 5142,5 граммга тигез.

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

*25 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 3 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Зөлхиҗҗә аеның беренче ун көненең фазыйләтләре

Хөрмәтле мөселманнар! Бүген изге зөлхиҗҗә аеның өченче көне. Бу айның беренче ун көне аеруча фазыйләтле. Әлеге көннәрнең бөеклегенә Коръәндә һәм Пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтендә күрсәтмәләр бар.

Беренчедән, Аллаһы Тәгалә Үзенең Изге Китабында шул көннәр белән ант иткән:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

**«Таң һәм ун төн белән ант итәм».**

«Фәҗер / Таң», 89:1-2

Ибн Габбас, ибн Зөбәер, Мөҗәһид, ибн Кәсир кебек соңгы чорның күп галимнәре аңлатуынча, Аллаһ зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне белән ант иткән.

Икенчедән, бу көннәрдә кылынган игелекле гамәлләр иң яхшылары булып исәпләнәләр, алар Аллаһ юлындагы җиһадтан да яхшырак бәяләнәләр. Бу турыда Пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйткән: «Аллаһ бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Кешеләр аннан сораганнар: «Ий Аллаһның Расүле, әгәр дә башка көннәрдәге эш Аллаһ юлындагы җиһад булсадамы?» Аллаһның Расүле ﷺ әйткән: «Хәтта бу эш Аллаһ юлында

җиһад булса да. Әмма Аллаһ юлына чыгып, үз-үзен һәм үз мөлкәтен корбан иткән кешеләрдән тыш»[1].

Өченчедән, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне Аллаһ каршында бөек һәм Аллаһы Тәгалә аларда башкарылган игелекле гамәлләрне барысыннан да ныграк ярата. Габдуллаһ ибн Гомәрдән ﷺ Пәйгамбәребезнең ﷺ шулай дип әйтүе тапшырыла: «Аллаһ каршында шул ун көннән дә бөегрәк көннәр юк, һәм дә башкарылган игелекле гамәлләрне Аллаһы Тәгаләнең алардан да ныграк яраткан башка көннәре юк. Шуңа да аларда ешрак «Лә иләәһә иллә-Лләһ» дип, тәһлил, «Аллаһу әкбәр!» дип, тәкбир, «Әлхәмдүлилләһи» дип, тәхмид әйтегез»[2].

Дүртенчедән, ул беренче ун көн арасында елның иң яхшы ике көне бар. Алар – Корбан бәйрәме (зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне) һәм Гарәфәт көне (зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне). Корбан гаетенә килгәндә исә, бу уңайдан Пәйгамбәребезнең ﷺ Габдуллаһ ибн Курт Әс-Сумали Әл-Әзди ﷺ тапшырган шундый сүзләре бар: «Аллаһы Тәгалә каршында иң бөек көннәр булып Корбан бәйрәме һәм Әл-Карр көннәре тора»[3]. Әл-Карр көне – зөлхиҗҗә аеның унберенче көне, ул гарәп теленнән сүзен сүзгә тәрҗемә иткән вакытта – «урнашу, булу»ны аңлата, чөнки, хаҗ кылучылар бу көнне хаҗ кылуның бар йолаларын да башкарып бетереп (тәваф әл-ифада (Кәгъбә тирәсендә җиде кат әйләнү), корбан чалу), Мина үзәнендә булалар, урнашалар.

Гарәфәт көненең фәзыйләтләре турында Аллаһ Расүленең ﷺ Гайшә ﷺ тапшырган хәдисе бар: «Аллаһның Үз колларын Тәмуг утыннан Гарәфәт көненнән дә күбрәк коткарган башка көне юк. Чынлап та, Аллаһ (Ул Изге һәм Бөек), (Үз колларына) якынлаша, һәм фәрештәләр каршында алар белән мактана. Һәм аннан соң сорый: «Ни телиләр алар?»[4]

---

1 Имамнар Бохари, Тирмизи хәдис җыентыкларыннан

2 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан

3 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан

4 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Аллаһның Расүле ﷺ тагын шулай дигән: «Гарәфәт көнендә укылган дога – иң яхшы дога»[1].

Икенче хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Гарәфәт көнендә тоткан ураза өчен, Аллаһ үткән ел һәм киләсе ел гөнаһларын кичерер дигән өметтәмен...»[2] Гарәфәт көнне ураза тоту – хаҗ кылмаган кешеләр өчен хупланган гамәл булып тора, ә хаҗ кылучылар, Аллаһ Расүленә ﷺ тәкълид итеп (ияреп, ә ул Гарәфәт көнендә ураза тотмаган), Аллаһны зикер итәргә һәм Аңа дога кылырга көчләре калсын өчен, ул көнне ураза тотмыйлар.

Хөрмәтле мөселманнар! Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә нинди гыйбадәтләр кылырга кирәк?

Беренчедән, бу көннәрдә иң яхшы эшләр булып хаҗ һәм кече хаҗ – гомрә кылу санала.

Аллаһның Расүле ﷺ әйткән: «Кем, хатынына якын килмичә һәм гөнаһ кылмыйча, бу Йортка хаҗ кыла, ул аннан аны анасы тудырган көндәге кебек булып кайта»[3]. Мөслим китергән риваятьтә: «Кем, хатынына якын килмичә һәм гөнаһ кылмыйча, бу Йортка килә, ул аннан аны анасы тудырган көндәге кебек булып кайта».

Аллаһ Расүле ﷺ тагын болай дигән: «Элекке гомрәдән соң кылынган гомрә алар арасында кылынган гөнаһлардан пакьлану булып тора. Мөкаммәл хаҗның әҗере – Җәннәт»[4]. Мөкаммәл хаҗ – күз буяу яки шөһрәт алу өчен башкарылмаган, аны башкарган вакытта гөнаһ кылынмаган хаҗ. Мөкаммәл хаҗның дәлиле булып, хаҗ кылучының, хаҗ кылып кайткач, күпкә яхшырак кешегә әйләнүе, элеккеге гөнаһларына башка кире кайтмавы тора.

1 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

3 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

4 Имамнар Бохари, Мөслим хәдис җыентыкларыннан

Икенчедән, «Аллаһу әкбәр» дип тәкбир әйтү, Аллаһны зикер итү – иң яхшы гамәлләрдән исәпләнә.

Ибн Гомәрдән ﷺ Аллаһ Расүленең ﷺ шул сүзләрен тапшыралар: «Бу көннәрдә ешрак «Лә иләәһә илла-Ллааһ» дип, тәһлил, «Аллаһу Әкбәр!» дип, тәкбир, «Әлхәмдүлилләһи» дип, тәхмид әйтегез». Имам Бохари әйткән: «Бине Гомәр һәм Әбү Һөрәйра ﷺ Зөлхиҗҗәнең беренче ун көнендә базарга чыгып, «Аллаһу Әкбәр!» – дип, тәкбир әйтәләр иде, ә башка кешеләр алар артыннан кабатлый иделәр. Мөхәммәд бине Гали нәфел намазлардан соң тәкбир әйтә торган булган».

Имам Бохари әйткән: «Гомәр ﷺ Мина үзәнендә үзенең чатырында тәкбир әйтә иде, ә мәчеттә булган кешеләр аның тавышын ишетеп, аның артыннан кабатлый башлый иделәр. Алар артыннан базарда булган кешеләр дә кабатлый башлыйлар иде, бар Мина үзәне тәкбир әйтүләрдән тетрәп тора иде...»

Тәкбир дигән вакытта «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Лә иләәһә илла-Ллааһу үәЛлааһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! үәлиЛләһил-хәмд!» сүзләрен әйтүне күз алдында тоталар.

Өченчедән, бу тугыз көндә (яки шул тугыз көннәрнең кайберләрендә) ураза тоту – иң яхшы эшләрнең берсе.

Пәйгамбәребез ﷺ әйткән: «Аллаһ бу ун көндә кылынган игелекле эшләрне башка көннәрне кылынган игелекле эшләргә караганда ныграк ярата». Ә ураза – иң яхшы, иң игелекле, иң зур саваплы эшләрнең берсе. Аннан тыш, Аллаһның Расүле ﷺ кешеләрне ураза тотарга өндәгән. Мәсәлән, үзенең хәдисләренең берсендә ул шулай дигән: «Аллаһ юлында тоткан бер көн ураза Аллаһ колының йөзен Тәмуг утыннан җитмеш еллык ераклыкка читләтер»[1].

Имам Нәсаи әйткән: «Пәйгамбәр ﷺ зөлхиҗҗәнең тугыз көнендә ураза тота иде».

---

[1] Имамнар Бохари, Мөслим хәдис җыентыкларыннан

Шулай ук, хаҗ кылучылардан тыш, калган бар мөселманнарга да Гарәфәт көнендә ураза тоту яхшы, чөнки, Аллаһның Расүле ﷺ ул көн турында шулай дигән: «(Бу ураза) үткән ел һәм киләсе ел өчен йолу булып тора»[1].

Дүртенчедән, тәүбә итү, гөнаһларны йолу да – иң яхшы гамәлләрдән исәпләнә.

Бишенчедән, башка төрле игелекле, саваплы гамәлләрне, иреклe гыйбадәтләрне ешрак башкару (намаз уку, сәдака тарату, Изге Коръәнне күбрәк уку, хәләлне куллану һәм хәрамнан тыелу, күршеләреңә хөрмәт күрсәтү, туганлык бәйләнешләрен тоту, башка игелекле эшләр).

Алтынчыдан, гает намазын уку һәм вәгазь тыңлау өчен мәчеткә иртәрәк килергә тырышырга кирәк. Гает намазы – Исламның олуг йолаларының берсе.

Җиденчедән, бәйрәм көнне һәм Тәшрик көннәрендә корбан чалырга дип күрсәтмә бирелгән.

Корбан китерү – безнең олуг бабабыз Ибраһимның ﷺ сөннәте. Аллаһ, корбан бирү өчен, Ибраһимның улы Исмәгыйльне тәкә белән алмаштырган. Бу турыда Аллаһы Тәгалә әйткән:

وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾

**«Без аңа Исмәгыйль урынына корбан итеп бугазлар өчен җәннәттән бер зур тәкә бирдек».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:107

Хак Сөннәттә әйтелгән: «Пәйгамбәр ﷺ «Бисмилләһ, Аллаһу әкбәр!» дип әйтеп, аягын аларның кабыргасына куеп, күзләре янында ак таплар булган мөгезле ике тәкәне үз куллары белән чалып, корбан итеп бирде»[2].

Аллаһы Тәгалә тагын шулай дигән:

---

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

2 Имамнар Бохари, Мөслим хәдис җыентыкларыннан

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне, фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»**

«Кәүсәр», 108:2

Аллаһы Тәгалә барчабызга зөлхиҗҗә аеның беренче ун көненең фазыйләтләрен истә тотып, изге гамәлләрне, гыйбадәтләребезне арттырырга насыйп итсә иде. Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбызны Үзенең чиксез рәхмәтеннән аермаса иде.

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*ТҖ МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе,*

*Апанай мәчете имам-хатыйбы*

## Корбан гаете хөтбәләре

## خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلَامُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَاۤءُ وَالْعَرْجَاۤءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللَّـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللَّـهَ اِنَّ اللَّـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللَّهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللَّهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللَّـهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللَّـهَ وَمَلاَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللَّـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللَّهِ، اِنَّ اللَّهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللَّهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللَّهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

## Корбан гаете хөтбәсенең кириллицага транслитерациясе

### Беренче хөтбә

**Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр үә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү гәниш-ширки үәззәүәәл. Үә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли үәл-җәмәәл.**

**Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү үәл-әфһәәм, үә гәҗзә гән идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.**

**Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гибәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри үәл-әййәәмил-фисааль. Үә әүҗәбә фии һәәзиһил-әййәәми гәләл-әгънийәәил-хәҗҗә үәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гиндәл-кәбиирил-мүтәгәәль.**

**Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, үәллааһү әкбәр, үә лилләһил-хәмд. Нәхмәдуллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә үәләдә, үә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, үә ләм йәкүнләһү үәлиййүн-минәҙ-ҙүлли үә кәббирһү тәкбиираа. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Үә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән гәбдүһүү үә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә'и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгәәль. Салләллааһү тәгааләә үә сәлләмә галәйһи үә галәә әәлиһи үә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый үә әтъйәбил-әхүәәл.**

**Әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн үә гиидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый үәл-гәүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәзәл йәүмә бил-ингәәми үәл-**

**ихсәәни үә иисаалил-әрхәәм. Үә иннәллааһә тәбәәракә үә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи үәнхәр. Үә әмәра халииләһүү би ẓәбхи үәләдиһил-әшһәри үә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би үәәситатил-мәләкил-мукарраб, үә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри гәләл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү гәу сәбгәтин үәд-да’нү үәл-мәгзү гән үәәхидин мүҗзиәтү үә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә’ү үәл-гарҗәәә’ү үә мәкътуугәтүл-үẓүни үәл-илйьәти үәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәẓһәбил-мүгътәбәр.**

**Даххүү гән әтъйәби әмүәәликүн үә гаẓẓыймүүһәәмтиṣәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи үә сәлләм: «Гәẓẓыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Үә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәẓкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүẓү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләẓиинә әәмәнүт-тәкуллааһә үәлтәңẓур нәфсүм-мәә каддәмәт лигаад. Үәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.**

**Бәракә Ллаһу ләнә үә ләкум фил-Куръәнил-гаẓыйм, үә нәфәгәнәә үә ийәкум бил-әәйәәти үәẓ-ẓикрилхәкиими үә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии үә ләкүм үә лисәә’ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.**

## Икенче хөтбә

**Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү үә нәстәгинүһү үә нәстәгъфируһү үә нү’минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи үә нәгүүẓү билләәһи мин шүрүүри әңфүсинәә үә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-**

**Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү үә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Үә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү үәхдәһү ләә шәриикә ләһү үә эшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү үә расүүлүһ.**

**Иннәллаһә үә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә гәлән-нәбий. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнү саллүү галәйһи үә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә үә саам. Аллаһүммә салли гәләә Мүхәммәдин үә гәләә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә үә каам.**

**Саллии үә сәллим гәләйһи үә гәләә җәмиигиль-әнбийәә’и үәл-мүрсәлиин. Үә гәләә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә үә гәләә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти үәл-әрадиин. Үәрхәмнәә үәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.**

**Аллаһүммә-гъфир лилмү’миниинә үәл-мү’минәәт, үәл-мүслимиинә, үәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә’и минһүм үәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт үә мүнзилүл-бәракәәт, үә раафигуд-дәраҗәәт, үә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.**

**Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә’әр-раашидиинә үәл-үмәрааа’әл-мәдыйнәл-ләҙиинә кадау билхәккы үә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә үәһди мән хаҙәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ’мүрү бил-гадли үәл-ихсәәни үә ийтәәәи ҙил-курбәә үә йәнһәә ганил-фәхшәәәи үәл-мүнкәри үәл-бәгъйи йәгыйиҙукум ләгәлләкүм тәҙәккәрүүн. Үҙкүруллааһәл-галийййәл-гаҙыымәл-хәййәл-каййүүм, йәҙкүрүкүм үәшкүрүүһү йәзидкүм, үәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм үә ләҙикруллааһи тәбәәракә үә тәгәәләә әгләә үә әүләә үә әгәззү үә әҗәллү үә әгҙаму үә әтәмму үә әкбәр.**

## Корбан гаете хөтбәсенең тәрҗемәсе

### Беренче хөтбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлуклар дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле зат булганына) акыл ияләре хайран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд ﷺ) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Корбанны «Корбан чал!» дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһимгә ﷺ) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы расүленең әмеренә буйсынып корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле ﷺ әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикъне Гарәфәт көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», —дигән. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

(«Хәшер» сүрәсе, 18 нче аять)

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хөтбә

Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыгынабыз. Кемгә Аллаһы һидәят бирсә —аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидият бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки, Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәре салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәре салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә

һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт индерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидәят бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәляләтле, иң бөек, иң камил, иң зур гамәл.

*2 сентябрь вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Корбан гаете вәгазе

**Бисмилләһир-рахмәнир-рәхим**

**Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!**

**Мөхтәрәм дин кардәшләр!**

Бүген без сезнең белән зур бәйрәм – Гыйд әл-әдха, Корбан гаетен каршы алабыз. Аллаһы Тәгалә барлык яхшы гамәлләребезне кабул итеп, гыйбадәтләребез өчен савапларын арттырып, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен насыйп итсә иде! Гаетебез мөбарәк булсын, һәр йортка да шатлык, иминлек һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килсен.

Корбан – Аллаһ безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән сансыз нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү. Изге Коръәндә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»** – диелгән.

«Кәүсәр», 108:2

Корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан китерелгән хайванда, аның итендә түгел, ә күндәмлек күрсәтү, тәкъвалык һәм диндарлыкта яшерелгән. Коръәндә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَـٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ كَذَٰلِكَ
سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ ۗ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ ﴿٣٧﴾

**«Чалган корбаннарыгызның итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, ләкин сездән Аллаһыга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер,»** – диелгән.

«Хаж», 22:37

Ел да корбан чалу – ул Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсыну һәм гыйбадәт хакына бар милкеңне корбан итәргә әзер булуның символик чагылышы.

Корбан чалу бай кешеләргә аларның Аллаһы Тәгалә каршында да, мөселман өммәте каршында да билгеле бер бурычлары барлыгын искә төшереп тора. Кеше ниндидер мөмкинчелекләргә ия икән, димәк аларны үз байлыгыңны арттыру өчен генә түгел, ә изге максатларда кулланырга кирәк. Аллаһы Тәгалә бай кешеләргә мохтаҗ һәм фәкыйрьләрне кайгыртырга, бар кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булырга омтылырга боера.

Коръәндә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ
وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ
بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ
مُخْتَالًا فَخُورًا ﴿٣٦﴾

**«Аллаһның Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!»** – диелгән.

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ юкка гына: «Күршесе ач булганда тук булган (кеше) бездән түгел», – димәгән.

Пәйгамбәребезнең ﷺ бу хәдисеннән кешегә, әгәр аның мөмкинлеге бар икән, башкаларга ярдәм күрсәтү җаваплылыгы йөкләнелгәне аңлашыла.

Корбан чалу кешеләр арасындагы аермалыкларны бетерә, аларны берләштерә, кардәшлек-дуслык җепләре ныгуга китерә, чөнки бәйрәм көннәрендә мөселманнар якыннарына гына түгел, ә бар кешегә дә яхшы эшләре вә изге гамәлләре белән ярдәм итәргә омтыла, корбан итләрен тарата. Бу көнне һәр мөселман өендә кунакчыллык, шатлык, юмартлык хөкем итә. Балаларыбызда башка көннәр түгел, ә барыннан да бигрәк мөселман гаетләре шатлык, куаныч һәм бәхет хисләре тудырсын өчен, бу көннәрдә аларга бүләкләр бирү, татлы ризыклар белән сыйлау киңәш ителә.

Гает вакытында юмарт һәм гакыллы кеше күпләргә шатлык һәм куаныч китерә ала, ә иң мөһиме – Раббысының рәхмәтенә ирешеп, кайбер кешеләр гомере дәвамында да тоя алмаган җан тынычлыгына ирешергә мөмкин.

Бер хәдистә Пәйгамбәребезнең ﷺ мондый сүзләре китерелә: «Саран кешеләрдән иң начары – моны эшләргә тиеш булып та, корбан чалмаучылары».

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ Корбан бәйрәмендә үзе ике корбан чала торган булган: берсен – үзе, ә икенчесен бар мөселман өммәте өчен. Шуңа күрә, җитәрлек байлыклары булган мөселманнар тагы да күбрәк савап алырга теләсәләр, шулай ук ике яки аннан күбрәк корбан чала ала.

Шул рәвешле, корбан чалу мөэминнең үзенең рухи чистарынуын гына түгел, ә күпмедер вакытка булса да, мохтаҗларны ризык белән дә тәэмин итә.

Корбан гаетенең тарихына тукталып китик. Ул бөек пәйгамбәр, Аллаһның дусты Ибраһим ﵇ һәм аның улы Исмәгыйль ﵇ белән бәйле.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә ﵇ зур сынау әзерли. Аңа үз улын корбан китерергә әмер итеолә. Ибраһим ﵇ иң кадерле, көтеп алган һәм йөрәгенә якын булган кешесен корбан китерергә кирәклеген аңлый. Беләбез, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга улын ул инде бик өлкән яшьтә булганда гына бирә.

Шушы бар кыенлыкларга карамастан, Ибраһим ﵇ Аллаһы Тәгаләнең әмеренә карусыз буйсына. Әмма барча галәмнәр Раббысы беркемнең дә корбанына мохтаҗ түгел, һәм, әлбәттә, кеше үтерелүен теләми! Аллаһ әмеренә буйсынып, Ибраһим ﵇ улы Исмәгыйль ﵇ өстенә пычак күтәргәндә мондый сүзләр ишетә:

قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ ﴿١٠٥﴾

**«(«Ий Ибраһим) төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсъдыйк кылдың, үтәгән хөкемендә булдың». Әнә шулай Үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:105

Шул рәвешле, улы урынына корбан хайваны бирелә, һәм Ибраһимга ﵇, киләчәктә шулай ук пәйгамбәр булачак, икенче улы – Исхак ﵇ бүләк ителә.

Корбан чалу – гыйбадәтнең бер төре һәм аны билгесез вакытка кичектерү дөрес түгел. Мисал өчен, кайберәүләр намазны, уразаны пенсиягә чыккач үти башлармын, баегач корбан чалырмын, дип әйтә. Бу дөрес түгел, чөнки иртәгә нәрсә буласын беребез дә белми. Бик тәкъвалы кеше Хәсән Әл-Бәсри ﵁: «Көн киткәндә синеңдә бер өлешең китә», – дигән.

Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуның кыйммәтен һәм әһәмиятенә килгәндә, мәшһүр Исмәгыйль Хаккы Бурсави язган «Рухул-бәйан» (1/363) тәфсиреннән бер гыйбрәтле хикәя китерергә мөмкин.

Шакик Әл-Бәлхи гыйбадәт юлына басып, гыйлем алырга керешкәнче, һәрдаим христиан илләренә барып йөреп, сату эшләре белән шөгыльләнгән.

Шундый сәфәрләрнең берсендә христиан короле аның күпме вакытын юлда үткәрүе белән кызыксынган. Шакыйк Әл-Балхый:

– Мин монда өч айда килеп җитәм, тагы өч ай дәвамында монда кирәк товарларны алам, өч ай туган җиремә кайтам һәм тагы өч ай товарларымны сатып бетерергә кирәк була, – дигән.

Король:

– Синең сәфәрләрең һәм сату эшләрең бер ел дәвам итә, ә Раббыңа кайчан гыйбадәт кыласың соң? – дип сорый.

Бу сорау Шакик Әл-Бәлхигә бик тәэсир итә, ул сату эшләрен калдыра һәм үзен гыйбадәткә багышлый.

Кеше нинди шартларда гына булмасын, нәрсә белән шөгыльләнмәсен, бу аның гыйбадәтенә зыян китерергә тиеш түгел, һәм ул Аллаһ әмерләрен үтәргә тиеш. Эш, гаилә, балалар, кешенең яше дә гыйбадәткә комачауларга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә эшләүчеләр гыйбадәт кылмаса да ярый димәгән. Киресенчә, Коръәндә:

وَاعْلَمُوا أَنَّمَا أَمْوَالُكُمْ وَأَوْلَادُكُمْ فِتْنَةٌ وَأَنَّ اللَّهَ عِندَهُ أَجْرٌ عَظِيمٌ ﴿٢٨﴾

**«Янә белегез, малларыгыз вә балаларыгыз фетнәдер, әмма Аллаһ юлында булганнарга Аллаһ хозурында олугъ нигъмәтләр бар, малларыгызны вә көчләрегезне Аллаһ юлына тотыгыз! Вә балаларыгызга дини тәрбия бирегез, ләкин аларга серләрегезне сөйләмәгез»,** – диелгән.

«Әнфәл / Табыш», 8:28

Бу сүзләр өстендә уйланыйк, дин кардәшләр, намазга, гыйбадәткә, котылуга ашыгыйк!

Ураза гаете, Корбан гаете намазларында, бу намазларның хөкеме вәҗиб булуына карамастан, мәчетләребезнең тулы булуы сөендерә. Ә көндәлек биш намазның хөкеме – фарыз. Мәзһәбебезнең имамы Әбү Хәнифә: «Фарыз вәҗибтән күк җирдән аерылып торган кебек аерыла», – дип әйткән. Башка сүзләр белән әйткәндә, көн дә укыла торган биш вакыт намаз гает намазларыннан күпкә өстен.

Шул сәбәпле, хөрмәтле дин кардәшләрем, барчагызны Аллаһ йортлары – мәчетләребезгә – һәр намазга чакырабыз, ә булдыра алмасагыз, һәр җомга намазына чакырабыз. Гомер тиз уза, ә намаз – ул Кыямәт көнендә бездән беренче соралачак иң мөһим гыйбадәт.

Корбан гаетенә килгәндә, кем өчен корбан чалу тиешле икәнен искә төшерик.

Корбан чалучы:

1. Мөселман булырга.
2. Үз акылында булырга.
3. Бәлигъ булырга.
4. Ирекле булырга.
5. Сәфәрдә булмаска.
6. Нисаб күләмендә мал-мөлкәткә ия булырга тиеш.

Корбан чалу ничек һәм кайда башкарыла?

Корбан гаетнең беренче өч көнендә чалына, әмма беренче көнне чалынса яхшырак. Гает намазы укылган шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларында корбанны бәйрәм намазыннан соң чалалар. Ә бәйрәм намазы укылмый торган авылларда корбанны таң аткач чалалар. Сахих хәдистә: «Бүген (ягъни гает көнне) безнең беренче эшебез – (гает) намазын уку, аннан соң – корбан чалу. Моны үтәүче сөннәтебезне үтәр. Кемдер корбан-

ны моннан (намаздан) иртәрәк чалса, бу үз гаиләсенә бирелгән гади ит булып саналачак», – диелгән .

Төнлә корбан чалу макруһ, чөнки караңгыда кеше хата эшли ала, ә әгәр урын яхшы яктыртыла икән, макруһ хөкеме юкка чыга.

Бәйрәмнең өченче көненең ахшам намазыннан соң корбан чалырга ярамый.

Корбан чала белүче моны үзе эшли, әгәр чала белмәсә, башка мөселманга йөкли ала. Динсезләр һәм мәҗүсиләрнең корбан чалуы тыела.

Корбанга китереләчәк хайванны җәфаламас өчен, сак булырга кирәк, пычак үткен булырга тиеш. Хайванның башын кыйблага каратып, сулъяк сыртына яткызу яхшы. «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр» сүзләрен әйтеп, хайванның бугазын, сулыш алу юлларын, муенындагы кан тамырларын кисәргә кирәк.

Хайванның җаны тәненнән аерылганчы, башын кисә яки тиресен туный башларга кирәкми. Корбан чалганда «Бисмилләһ» дип әйтү генә җитми, «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр» дип әйтү кирәк. Корбан чалучы кеше аңлы рәвештә «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр» дип әйтмәсә, бу хайванның ите хәрамга әйләнә. Әгәр әйтергә онытса, бу гафу ителә.

Корбан итен кешеләргә таратырга яисә үзеңә калдырырга була. Аны өч өлешкә бүлсәң хәерлерәк: бер өлешен туганнарга һәм дусларга таратырга, икенчесен фәкыйрьләргә өләшергә, ә өченче өлешен үзеңә калдырырга.

Корбан итеп чалынган хайванның итен һәм тирене сатарга яки ит чабучыга түләр өчен куллану мәкруһ, киңәш ителми. Тирене үзең куллансаң була ,шулай ук аны мохтаҗларга яисә хәйрия оешмасына тапшырырга мөмкин. Мөселман булмаганнарга да корбан итен күчтәнәч итеп бирергә ярый.

Гает намазында хәзер янәшәбездә төрле шәһәр, ил, кыйтгалардан килгән мөселманнар, һәм, тышкы кыфәтләребез, телләребез, тән төсебез төрле булуга карамастан, без терәлеп торабыз, бер-беребезгә сәлам җиткерәбез, бер Аллаһка бергәләп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде, бар мөселманнарны кардәш итте.

Раббыбыз шушы көнне ихластан дога кылырга, корбан китерергә, рухи тынычлык алып, Аның мәрхәмәтенә ирешергә насыйп итсә иде. Аллаһы Тәгаләдән безгә бәхет, сәламәтлек, илебезгә һәм Татарстан Республикасына тынычлык, иминлек, муллык һәм үсеш сорыйм. Гает мөбарәк булсын!

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөселманнарының*

*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

*8 сентябрь вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Ислам – гакыл дине

Бүгенге көндә җир йөзендәге кайсы гына кешене туктатып: «Без хайваннардан нәрсә белән аерылып торабыз?» – дип сорама, җавап бер: «гакыл». Без һәрберебез үзебезне акыллы дип саныйбыз. Кешегә акыл бирергә тырышабыз. Ни өчендер «мин акыллы да, башкалар акылсыз», дип уйлыйбыз. Башкалар да үзләрен генә акыллы дип саный. Шуннан бәхәс китә. Бәхәстә һәрберебез үзебезнең акыллырак икәнебезне исбат итәргә тырышабыз. Әмма гамәлдә, кызганыч, гел киресен эшлибез. Хәтта хайваннардан да уздырабыз. Әллә шулай түгелме? Нәкъ шулай.

Нәрсә соң ул гакыл? Кем ул акыллы кеше? Моның барысына да җавапны Аллаһы Тәгаләнең Коръән китабында һәм сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафаның ﷺ хәдисләрендә таба алабыз. Әлһәмдүлилләһ.

Акыл – Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләнең хөкеменнән кешегә фикерли алыр өчен бүләк ителгән, башка бөтен җан ияләреннән аерып тора торган әйбер ул.

Аллаһы Тәгалә «Гыймран» сүрәсендә болай ди:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِّأُولِي الْأَلْبَابِ ﴿١٩٠﴾

**«Дөреслектә, җир вә күкләрнең төзелешендә һәм төн белән көн бер берсен алмаштыруда акыл ияләренә Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышанырга, әлбәттә, көчле дәлил».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:190

Без барыбыз да Аллаһы Тәгаләнең галәмнәрне, гомумән бар нәрсәне дә юктан бар кылганын беләбез. Ягъни, бернинди күзәнәк тә, микроб та, хайван да, кеше дә үз-үзен бар итмәгән, үз-үзен тудырмаган, һәм беребез дә аны булдыра алмый. Һәр нәрсә Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсына.

Һәрберебез кечкенә генә эксперимент ясап карый ала: янәшәдәгеләргә каләм вә кәгазь битләре таратып, каләмне шул битләргә ташлап карагыз. Билгеле, каләм үзе бернинди җөмлә төзи дә, яза да алмый. Ничек соң Галәмдәге йөз меңнән артык галактикаларны, йөз миллиардтан артык йолдызларны үзеннән үзе барлыкка килгән дип әйтә алабыз? Без яши торган Җир шары Кояшны үзе сайлап алганмы? Һәм Кояштан никадәр ераклыкта булырга, ягъни тормыш итәр өчен мөмкинчелекләр булсын өчен, шартларны Җир шары үзе чутлап чыгарганмы?! Аллаһы Тәгалә галәмдәге булдырган бөтен әйберләр дә, ни өчен яратылган, бар кылынган булсалар, шуның барысын да башкаралар, Аңа буйсыналар. Ягъни планеталар әйләнеп тора (алар тик тормый!), Кояш җир йөзен яктыртып һәм җылытып тора, көн белән төн бер-берсен алыштыра. Шулай ук барлык җан ияләре дә үз бурычларын үтиләр: кошлар оча, балыклар йөзә, ишәк йөк ташый, сыер сөт бирә, бал кортлары бал җыя...

Алар барысы да бары тик кешегә файда китерер өчен яралтылган. Ә кеше исә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга битараф карый. Кешегә «азатлык һәм иреклек» сайлау, кабул итәргә яки кабул итмәскә мөмкинчелек бирелгән.

Һәр нәрсә, һәр зат үз вазифаларын үтәгәндә генә хуҗасын канәгатьләндерергә мөмкин. Без дә үзебезнең хуҗабыз – Раббыбыз – алдында үз вазифаларыбызны үтәп кенә бәхеткә ирешергә мөмкинбез. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**« кеше белән җенне Үземә гыйбадәт кылсыннар өчен генә бар иттем».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

Бервакыт бер кеше сукырая һәм табиб янына бара. Табиб аны карый да, күзлек бирә. Бу кеше шатлыгыннан табибка җанын бирергә әзер булуын әйтә. Карагыз әле: нинди юмарт кеше! Ике пыяла һәм каймадан торган күзлек биргән табибка үзенең җанын бирергә әзер, ә аңа күзләр бүләк итүчегә биш-ун минут вакыт таба алмый. Күзләре булмаса, аңа бернинди табиб күзлекләре дә булыша алмавы турында уйлап та карамый. Димәк, кирәк чагында ул үз акылын куллана белми.

Бу гүзәл принципны сине юктан бар иткән, сиңа күз, колак, куллар, аяклар биргән, сине иң яхшы сурәттә ишетү һәм күрү сәләтләре белән яраткан, сиңа буй-сын биргән, яшәр өчен матди байлык белән тәэмин иткән, сине үстерүче, сине акыллы һәм фикер йөртүче итеп яралткан Аллаһы Тәгаләгә карата куллансаң икән! Аллаһы Тәгалә сиңа биш вакыт намаз кылырга боера, син аны кылсаң икән! Аллаһы Тәгалә сиңа елга бер тапкыр Рамазан аенда ураза тотарга куша, син ураза тотсаң икән! Аллаһы Тәгаләне «Лә иләәәһә илләллаһ, Мөхәммәдүррасүлуллаһ!» дип кабатлап, исеңә төшереп торсаң икән!

Ислам – гакыл дине. Ислам акыллы кешеләргә мөрәҗәгать итә. Ислам акыллы кешеләргә бурычлар йөкли.

Без акылга материаль караштан җавап бирә алмыйбыз. Дөресен генә әйткәндә, материаль караш бернәрсәгә дә төпле җавап бирми. Мәсәлән, без бер профессорны акыллы дип әйтергә мөмкинбез. Аның ачышлары уку әсбапларына кертелгән булырга мөмкин. Аны якыннан белмәгән кешеләр үз балаларына үрнәк итеп күрсәтәләр. Әмма ул үз гаиләсе өчен әдәпсез, акылсыз кеше булырга мөмкин. Эштә үрнәк булып, шәхси тормышта исерек, зина кылып йөрүче, гаиләсен рәнҗетүче кешеләр азмы ни?

Икенче берәүнең белеме булмавы да бар, ләкин ул авылда көтүче яисә шәһәрдә гади җыештыручы, йөк ташучы булып эшләп, гаиләсен бөтен кешене гаҗәпкә калдырырлык итеп тотарга мөмкин. Бу очракта гаиләсе һәм якыннары аны иң акыллы кеше буларак кабул итәләр.

Кемнең акыллы икәне Кыямәт көнендә күренәчәк. Анда кешеләрне ике төркемгә бүләчәкләр: акыллылар, алар Аллаһның барлыгын белеп гыйбадәт кылучылар, һәм акылсызлар, бүтән төркем булмаячак. Акыллылар җәннәткә керәчәк, акылсызлар – җәһәннәмгә. Дөньялыкта без акыллы дип йөргән күп кешеләр Кыямәт көнендә акылсызлардан булырга бик мөмкин, Аллаһ Үзе сакласын. Ул көнне тәүбәләр, үкенүләр, вәгъдәләр бирсә дә кабул булмаячак. Ашыгыйк, кардәшләрем, бүгеннән акылыбызда булырга ашыгыйк.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Хикмәтнең башы – Аллаһыдан куркудыр».[1] Шушы дөньяда һәм Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең акыллы колларыннан булырга насыйп булса иде. Әмин.

*Ихсанов Рүзил, Әлмәт районы,*

*«Яшь вәгазьче» бәйгесе җиңүчесе*

---

[1] Имам Әл-Бәйһакый, «Шугубүл Иман» җыентыгы, №729

*15 сентябрь вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 24 нче көне, һиҗри исәп буенча 1438 ел*

# Аллаһ ризалыгы өчен син бүген нәрсә эшләдең?

Бар галәмнәрне, барча мәхлукатларны бар кылган Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булса иде. Без Аңа иман китердек вә Аңа өметләнәбез. Бары тик Аллаһ Тәгаләдән ярдәм, мәгъфирәт, һидаяткә һәм туры юлга бастыруны сорыйбыз. Без, гөнаһлы уй-фикерләр, гамәлләрдән ерагаеп, Аңа мөрәҗәгать итәбез.

Дөреслектә, Бер булган Аллаһтан кала бүтән иләһ юк! Аның камиллегенә беркем дә вә һичкайчан да ирешә алмас. Бары тик Ул гына бар нәрсәгә дә кодрәтле.

Шулай ук Мөхәммәд ﷺ Аллаһның илчесе вә Аның колы дип шәһадәт китерәбез. Я Раббым, Мөхәммәдкә ﷺ Үзеңнең рәхимлелегеңне ирештерсәң иде. Аның туганнарына, сәхабәләренә вә алардан соң килгән мөэминнәргә дә Үзеңнең юмартлыгыңны күрсәтсәң иде.

Я Аллаһ, Үзеңнең чиксез рәхмәтләреңне вә мәрхәмәтлелегеңне безгә дә күрсәтсәң иде. Синең хакыйкый бөеклегеңне аңлауда көчсез вә Синең хакыйкый кодрәт иясе булуыңны аңлауда артык белемсез булган колларыңа Үзеңнең шәфкатеңне күрсәтсәң иде.

Аллаһ Тәгаләнең ризалыгын алу өчен бик күп төрле юллар, гамәлләр барлыгын барыбыз да беләбез һәм, әгәр дә без бу рәхмәткә ирешә алсак, безнең мәңгелек дөньябыз тыныч һәм бәхетле үтәр. Аллаһ насыйп әйләсен!

Аллаһ Тәгалә изге Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَعَدَ اللَّهُ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا وَمَسَاكِنَ طَيِّبَةً فِي جَنَّاتِ عَدْنٍ ۚ وَرِضْوَانٌ مِّنَ اللَّهِ أَكْبَرُ ۚ ذَٰلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ﴿٧٢﴾

**«Аллаһ Тәгалә Коръән белән гамәл кылучы мөэмин ирләргә вә мөэминә хатыннарга асларыннан елгалар агучы җәннәтләр хәзерләде, алар анда мәңге калырлар, вә Гаден җәннәтләрендә яхшы урыннар хәзерләде, вә аларга Аллаһның ризалыгы булыр, Аның ризалыгы һәрнәрсәдән олуг. Бу әйтелгәннәр зур теләккә – мәңгелек бәхеткә ирешүдер».**

«Тәүбә», 9:72

Кабатлап үтәм: «Аның ризалыгы һәрнәрсәдән олуг».

Аллаһның рәхмәтенә ирешер өчен без фарыз гыйбадәтләрдән кала тагын ни кылабыз соң? Йокларга ятканда аларның (фарыздан кала гамәлләр) бер өлешен булса да үтәп, тыныч күңел белән ятканыбыз бармы икән? Әллә инде, белә торып, аларны эшләмәс өчен сәбәпләр генә эзләп йөрибезме?

Гомәр Әл-Фарук: «Үзегездән үзегез, сезгә хисап ясап биргәнче, хисап сорагыз, вә шул гамәлләрегезне, сезгә башкалар үлчәп биргәнче, үзегез үлчәп карагыз», – дип әйтә.

Бер мизгелгә генә үзегездән сорау алып карагыз әле: Аллаһ ризалыгы өчен күпме кешегә бүген ярдәм кулын суздыгыз? Берәр фәкыйрьне ашата алдыңмы, әллә инде мескенгә сәдака бирдеңме? Хуҗасыз калган берәр хайванны ашаттыңмы? Агач утырттыңмы? Ә бәлки наздан мәхрүм калган ятим балалар янына барып кайттыңмы? Аллаһ ризалыгы өчен дип өеңә кунак чакырдыңмы, туганнарың янына яисә берәр авыруның хәлен белергә бардыңмы? Аллаһ ризалыгы өчен дип, юлчыларга комачаулаган ташны юлдан алып куйдыңмы? Ә бәлки син бүген

мәчет җыештыргансыңдыр? Галим, яки гыйлем алучыларга булыштыңмы бүген? Арган яисә олы кешегә транспортта урын бирдеңме?

Бәлки син бүген талашкан ике кешене дуслаштыргансыңдыр? Сиңа кылынган начарлыклары өчен, Аллаһ ризалыгы дип, дошманнарыңны кичердеңме соң әле? Ниндидер яңалыкка, яңа эшкә, гыйлемгә ирешә алдыңмы яисә калганнарны нинди дә булса яңа нәрсәгә өйрәтә алдыңмы? Кешеләр синннән сораганнарны үти алдыңмы бүген?

Боларны үти алмасаң да, бәлки син начар сүзләр вә гайбәттән ерак булгансыңдыр?

Үзебезгә аклану табуны җиңел гамәл итеп кылдык. «Кем дә кем нәрсәдер эшләргә теләсә, мөмкинлекләр эзли. Калганнар соң аклanулар эзли», дигән гыйбарә бар. Бәлки без дә нәкъ менә аклanулар эзләүчеләр рәтендәдер…

Сәхабәләребез тормышына күз салыйк әле. Гомәр бин Әл-Хаттаб ﵁ Әбү Бәкернең ﵁ көн саен иртәнге намаздан соң каядыр барганын күреп ала. Аның кая барганлыгы турында үз-үзенә сораулар да биргәли иде.

Беркөнне ул аның артыннан күзәтеп, Әбү Бәкернең ﵁ бер чатырга керүен күрде. Әбү Бәкер чатырдан чыккач, Гомәр анда кереп, балалары белән бер сукыр апаны күрде.

Гомәр аннан: «Я Аллаһның колы, кем син?» – дип сорады.

Ул: «Мин бу чатырда ошбу кызларым белән яшәүче карт хатын. Әтиләре вафат инде һәм безнең Аллаһтан кала бүтән ашатучыбыз да юк», – дип җавап кайтара.

Гомәр кабаттан: « Ә сезгә килүче кеше кем ул?» – дип сорады.

Бу хатын: « Мин аның исемен белмим, ләкин ул һәркөн иртән килеп безнең идәнне себерә, иртәнге аш пешереп, кәҗәләребезне савып китә», – дип әйтә.

Гомәр ﵁ елап җибәрә һәм: «Ий Әбү Бәкер… Синнән соң килгән хәлифәләргә синең кебек булырга бик авыр булачак», – дип әйтә.

«Йә, ә мин берәр нәрсә кыла аламмы соң?!»

Ничә тапкыр берәр проблема турында ишеткәч, иңбашларыбызны сикертеп куябыз икән? Ул проблема зур я кечкенә, безнең өммәтебезгә кагылышлы яки дустыбызның өендәге берәр проблема була ала – иңбашларыбызны гына сикертәбез шул.

Бер хатын көчкә генә диңгез яры буйлап сөйрәлеп бара иде. Су чигенгән вакыт булганлыктан, суүсемнәрдә буталып калган бик күп балыкларны күрә ул. Балыкларның саны йөз меңләгән иде. «Мин аларга булыша аламмыни?» Бу хатын, бер балыкны алып, берничә метр эчкә керде дә, аны суга төшерде. Соңыннан икенчесе артыннан бөгелеп, шулай ук эшләде. «Бу икесе өчен мин бик күп нәрсә эшли алам, ахрысы...»

Без зур-зур проектлар турында еш ишетәбез. «Бөтен мөселманнарны берләштерергә иде, ислам социаль челтәре төзергә иде, ислам китапханәсе төзергә иде, хәләл кафелар челтәре булдырырга, мәчет, мәдрәсә яисә башка нәрсә төзергә иде...»

Бу, һичшиксез, бик күркәм гамәлләр, ләкин безне я вакыт булмау, я финанс мәсьәләсе туктата, яки без үзебез уйлаган әйберләребезгә ышанмый башлыйбыз. Нәрсәдән башларга белмәгәнлектән, безнең энтузиазмыбыз, дәртебез кими башлый һәм күркәм булган проектлар тормышка ашмый калалар.

Кайвакыт кечкенә һәм сизелми торган эш тә зур нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Мөселман буларак, син бүген шәһәрең өчен, мөселман өммәтең өчен нинди гамәл кыла аласың? Үз гаиләң өчен, мөселман өммәте һәм синең янындагыларың өчен ни эшли аласың?

Әйдәгез сезнең белән кечкенә генә бер тест эшләп алыйк.

Мисал өчен, мәчетегездә берәр төрле проблема килеп чыкты: коммуналь хезмәтләр өчен түли алмый башладыгыз. Сезнең моңа карата реакциягез:

а) бик тирән кызгану хисләрен белдертәм, тик пассив калам;

б) бик тирән итеп тәэсирләнеп, «кемдер нидер эшләргә тиеш», дип зарланам;

в) бу мәсьәләне чишү юлларын эзләргә тырышам.

Әгәр сезнең җаваплар «а» яисә «б» пунктларына туры килсәләр, сездә «КНЭТ» синдромы – «Кемдер Нидер Эшләргә Тиеш!».

Бу, әлбәттә, дәвалана торган синдром һәм хәзер үк керешергә киңәш итәм.

Аллаһ Тәгаләдән дәва юлы:

فَإِذَا فَرَغْتَ فَانصَبْ ﴿٧﴾

**«Бер хәерле эштән бушансаң, икенче хәерле эшне эшләргә тырыш».**

«Инширах / Ачмак», 94:7

لَهُ مُعَقِّبَاتٌ مِّن بَيْنِ يَدَيْهِ وَمِنْ خَلْفِهِ يَحْفَظُونَهُ مِنْ أَمْرِ اللَّهِ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُغَيِّرُ مَا بِقَوْمٍ حَتَّىٰ يُغَيِّرُوا مَا بِأَنفُسِهِمْ ۗ وَإِذَا أَرَادَ اللَّهُ بِقَوْمٍ سُوءًا فَلَا مَرَدَّ لَهُ ۚ وَمَا لَهُم مِّن دُونِهِ مِن وَالٍ ﴿١١﴾

**«Тәхкыйк, Аллаһ бер кавемнең хәлен, хәтта ул кавем үз хәлен үзе үзгәрткәнгә чаклы, үзгәртмәс».**

«Рәгыд / Күк Күкрәү», 13:11

Әгәр дә сез үзегез җәмгыятебездәге проблемаларны чишү өчен бернинди дә көч куймыйсыз икән, димәк, сез үзегез үк бу проблеманың бер өлеше булып торасыз. Бүгенге көндәге иң зур проблема – мөселманнарның пассивлыгы.

Ислам җәмгыятеннән кала, без барыбыз да кемнеңдер күршеләре, танышлары һәм, ниһаять, шушы шәһәрдә торучы халык.

Кадерле кардәшләр! Сезнең тәртибегезгә карап, калган кешеләр Ислам турында, мөселманнар турында хөкем итәләр. Ә бәлки син – аларга күрергә, белергә насыйп әйләгән бердәнбер мөселмансыңдыр.

Бер мөселман кардәшем, хастаханәдә ятканда көненә 5-6 кеше килә иде, дип сөйләде. Ятуын да бик озак ятты ул. Мөселманнар арасында булган ошбу дуслык – авырулар һәм анда эшләүчеләрнең күңелләрендә бик тирән эзләр калдырган. «Менә бу мөселманнар!» – дип сокланганнар алар. Дуслык җепләрен ныгытып, сез өммәтебезнең генә ныклыгын көчәйтеп калмыйсыз, ә Исламга якын тирә-юньдә уңай имидж да булдырасыз.

Коръәни Кәримдә күп җирдә иман белән берлектә изге гамәлләр кылу да искә алына: «… иман китерүче вә изге гамәлләр кылучылар…»

Турылыклы Гали ﷺ үзенең тормышы турында болай дип әйтә: «Мине куандыра торган ике төрле хәерлелек бар һәм мин аларның кайсысы зуррак икәненә төшенә алмыйм. Беренчесе – берәр кешенең, аның авырлыкларын чишә алырмын дигән өмет белән, миңа мөрәҗәгать итүе. Икенчесе – Аллаһ Тәгалә минем сәбәпле бу кешенең авырлыкларын җиңеләйткәндә, яки, гомумән, аны бетергәндә. Мин, чиге булмаган алтын-көмешкә ия булганчы, бер мөселманның хәлен җиңеләйтер идем»[1].

Безнең исәптә ничә яхшы гамәл бар икән?

Тирә-якка карап алыгыз әле, бәлки сезнең өй тирәсендәге балалар мәйданчыгын төзекләндереп буладыр. Бәлки таганнарны рәтләргә мөмкиндер. Чәчәкләр утыртып буладыр. Бәлки сезгә балагыз йөри торган балалар бакчасына, мәктәпкә, сездән ярдәм сораганчы ук, үзегезнең ярдәм кулын сузаргадыр?

Без, мөселманнар, үзебез яши торган җәмгыятьнең бер өлеше, шуңа күрә, әйдәгез, аның актив бер төркеме булыйк. Бер-берләребез белән изге гамәлләр кылуда ярышыйк. Аллаһ һәрберебезне дә ошбу эшләрдә Үзенең ярдәменнән ташламасын.

*«Хозур» редакциясе*

[1] «Гали Әл-Мутакки», VI, 598 / 17049

*22 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Әти-әниләрнең ризалыгын алу – җәннәткә ачкыч

Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гааләмииин, вәссаләәтү вәссәләәмү галәә расүүлиһил кәрим үә галәә әәлиһи үә әсхабиһи әҗмәгыйн.

Бөтен җанлы һәм җансыз барлыкларны яралткан, безгә Үзенең нигъмәтләрен һәрдаим биреп торган Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә иксез-чиксез мактауларыбыз, шөкраналарыбыз, рәхмәтләребез булса иде. Безгә бу һәм киләсе дөньяда да бәхетле булырга, хакыйкатьне ялганнан аерырга өйрәткән, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә күңел түрләребездән чыккан сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.

Ислам дине кеше тормышын һәрьяклап бизи. Ул зәгыйфьләргә мәрхәмәт күрсәтергә дә, ярлыларга, мохтаҗларга хәйриячелек итәргә дә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә дә, үз гаиләң турында кайгыртырга да, авыр хәлдә калган яки җәбертелгән кешеләргә ярдәм итәргә дә өйрәтә. Ул безне әти-әниләребезне, дус һәм коллегаларыбызны, абый-апа һәм энесеңелләребезне хөрмәт итү әдәбенә дә өйрәтә.

Коръәннең күп кенә аятьләре ата-аналарны хөрмәт итәргә, аларга карата игелекле эшләр эшләргә куша. Әти-әниләрең динсез булган очракларда да, Коръән алар белән игелекле, миһербанлы, дусларча

мөнәсәбәтләрдә булуны, аларны ихтирам итүне таләп итә[1]. Ата-аналар Аллаһы диненнән яки Раббыбызның күрсәтмәләрен үтәүдән баш тартуны таләп иткән очракта гына, аларның бу таләпләрен үтәү кирәк түгел.

Коръәндә, Аллаһы Тәгалә Үзенә иптәшкә иләһләр китермәскә кушканнан соң, Ул ата-аналарга игелек кылырга, аларны хөрмәт итәргә, алар белән яхшы мөнәсәбәттә булырга куша[2]. Бу – ата-аналарны хөрмәт итүнең Исламда нинди зур кыйммәткә ия булуын күрсәтә.

Имам Әл-Бохари һәм Мөслим күрсәткән хәдисләр буенча, ата-аналарны хөрмәт итмәү, рәнҗетү, җәберсетү, үпкәләтү, аларга башка газап һәм әрнүләр китерү бик зур гөнаһ булып исәпләнә. Аллаһы Тәгалә этиәнисен рәнҗеткән кешеләргә Кыямәт көнендә үз хәер-фатихасын бирмәс, андый кеше җәннәтнең исен дә тоймас, аның өчен Җәннәт капкалары ябык булыр, аның саваплы гамәлләре кабул ителмәс, андый кешене бик тиз кайгы һәм хәсрәт басар, Аллаһы Тәгалә андый кешене ләгънәт итәр, эти-әниләрен тыңламавының газапларын ул бу дөньяда ук татыр, үлгән вакытта шәһадәт әйтер өчен дә аның теле әйләнмәс. Пәйгамбәрнең ﷺ күп хәдисләрендә шулай дип әйтелә.

Шуның өчен Аллаһы Тәгалә һәм Кыямәт көненә ышанган һәр кеше ата-аналарны хөрмәт итү әдәбенең түбәндәге кагыйдәләрен үтәү өчен бар тырышлыгын да куярга тиеш:

1. Һәр кеше, аның ата-аналарының (аеруча аның әнисенең) аны үстерү өчен нинди көч салуларын, күпме күңел көчләрен, нервларын сарыф итүләрен, моның өчен күпме кыенлыклар, авырлыклар кичерүләрен бервакытта да онытырга тиеш түгел.

Коръәндә шулай дип әйтелә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنْسَانَ بِوَالِدَيْهِ إِحْسَانًا حَمَلَتْهُ أُمُّهُ كُرْهًا وَوَضَعَتْهُ كُرْهًا ﴿١٥﴾

---

1 «Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:8; «Локман», 31:19

2 «Ниса / Хатыннар», 4:36

**«Без кешегә ата-анасына һәрьяклап изгелек итәргә, аларга файдалы булырга әмер иттек, аны анасы мәшәкать белән корсагында күтәрде вә мәшәкать белән тудырды».**

«Әхкаф / Комлык», 46:15

2. Кеше үз ата-аналарының гөнаһларын ярлыкавын сорап һәрвакыт Аллаһка ялварырга, Аннан аларга карата рәхим-шәфкатьле булуын сорарга тиеш. Коръәндә шулай дип әйтелә:

وَاخْفِضْ لَهُمَا جَنَاحَ الذُّلِّ مِنَ الرَّحْمَةِ وَقُلْ رَبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَارَبَّيَانِي صَغِيرًا ﴿٢٤﴾

**«Вә аларга шәфкать, шәфәгать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Вә әйт: «Ий Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкатьлелек кыл!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:24

3. Синең аларга ниндидер үпкәң бар икәнен әти-әниләреңә беркайчан да күрсәтмәскә кирәк, беркайчан да аларга тавышыңны күтәрмәскә, алар белән йомшак, ягымлы, итагатьле, мәрхәмәтлелек күрсәтеп сөйләшергә кирәк. Кәламе шәрифтә «Бәни Исраил /Ягъкуб балалары» сүрәсенең 23 нче аятендә безгә шулай куша:

إِمَّا يَبْلُغَنَّ عِنْدَكَ الْكِبَرَأَحَدُهُمَا أَوْكِلَاهُمَا فَلَا تَقُلْ لَهُمَا أُفٍّ وَلَاتَنْهَرْهُمَا وَقُلْ لَهُمَا قَوْلًا كَرِيمًا ﴿٢٣﴾

**«Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23

4. Балалар бар мәсьәләләр буенча да үз әти-әниләренең сүзләрен тыңларга, аларга итагать итәргә тиешләр. Алар кәферлеккә илтә яки Аллаһ күрсәтмәләрен үтәүдән читләштерә торган эшләр кушкан вакытта гына искәрмә булырга мөмкин. Ата-анага итагать итү – аларны сөюнең чагылышы, алар кушканны тыңламау – аларның каефен төшерә, аларны җәберсетү булып тора.

Бервакыт Пәйгамбәрдән ﷺ сораганнар: «Аллаһ иң сөйгән гамәл нәрсә булыр?» Аның җавабы: «Вакытында укылган намаз», – булган. «Ә аннан соң нинди эш булыр?» – дип аннан тагын сораганнар. «Ата-аналарга итагатьле булу һәм аларга игелек эшләргә тырышу», – дип җавап биргән Аллаһның Расүле ﷺ. Ә аннан соң ул: «Ислам юлында тырышлык күрсәтү», – дип өстәгән[1].

Бу сахих хәдистә ата-аналарга карата итагатьле булу газаваттан алда китерелә, аннан алгарак куела.

5. Балалар ата-аналары белән югары тонда сөйләшергә тиеш түгелләр. Балаларга үз әти-әниләреннән ялыкканнарын яки аларның сезне башкача борчуларын күрсәтергә ярамый. Әти-әниләрнең ни әйтергә теләгәннәрен, киңәшләрен тыңларга, кабул итә белергә, алар белән сөйләшкән вакытта йомшак, мөлаем тавыш белән сөйләшергә, аларга караңгы чырай катмаска, төксе, усал йөз белән карамаска кирәк.

Хәдистә шулай диелә: «Ата-анасына төксе йөз белән караган кеше, ул аларны тыңламый дигән сүз»[2].

6. Ата-аналарның вафатыннан соң да, Аллаһтан аларның гөнаһларын кичерүен, Аның аларга рәхим-шәфкать күрсәтүен сорап, догалар укуны дәвам итәргә кирәк.

Хәдистә шулай дип әйтелә: «Әгәр дә кеше алар исән вакытта үз әти-әнисен җәберсеткән икән, аларның вафатыннан соң чын ихлас тәүбә итү – Аллаһтан аларга карата рәхим-шәфкатьле булуын сорау гына булырга

[1] Имам Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

[2] Имам Ад-Дарукутни хәдисләр җыентыгыннан

мөмкин. Ягъни, әгәр дә ул кеше Аллаһтан аларның гөнаһларын кичерүен сорап бик еш дога укый икән, Аллаһы Тәгалә аның исемен ата-аналарына итагатьле булучылар исемлегенә язар»[1].

7. Әти-әниләреңә алар өчен кирәкле һәм файдалы әйберләр бүләк итәргә, аларга өс һәм аяк киеме һ. б. сатып алып бирергә кирәк. Бу Коръән Кәрим аятенең мәгънәсенә салынган, ә бу аятьтә шулай дип әйтелә:

وَقَضَى رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا ﴿٢٣﴾

**«Аллаһ фәкать Аңа гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә әмер бирде».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23

8. Ата-аналарның вафатыннан соң аларның васыятьләрен үтәргә, аларның дуслары белән дуслык бәйләнешләре булдырырга, алар яраткан-нарны яратырга кирәк. Сахих хәдистә шулай диелә: «Ата-аналарга карата эшләнгән игелекле эшләрдән иң игелеклесе – алар яраткан кешеләр белән яхшы бәйләнешләр тоту»[2].

9. Ата-аналар янында үзеңне аларга карата ихтирамлы тотарга кирәк. Алар янында кычкырып көлү, кычкырып җырлау, ачык тәнеңне күрсәтү, үзеңне дорфа, ачу чыгарырлык итеп тоту – аларга карата әдәпсезлек күрсәтү булып тора. Әгәр дә балалар, аларны яратып, әти-әниләренең кулларын үбәләр, аларны кочып алалар икән, бу – ихтирамсызлык күрсәтү булып саналмый.

10. Балалар үз әти-әниләренә ничек һәм ни белән булдыра алсалар, шулай ярдәм итәргә тиешләр. Әтисе авыр йөк күтәреп барган вакытта, аның улына ике кулын җилпеп, селкеп бару килешми. Өйдә тәртип салуны, өйдәге башка бар эшләрне дә әни кешегә йөкләргә ярамый, үз киемеңне үзеңә тәртиптә тотарга, савыт-сабаларны юарга һ. б. өй эшләрен үзеңә

[1] Имам Әбү Давыд, Ибне Маҗәһ, Ибне Хәббан

[2] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

эшләргә кирәк. Өлкән яшьтәгерәк балалар үзләреннән кечерәкләрне карарга ярдәм итәргә, алар турында хәстәрлек күрергә, кайгыртырга тиешләр. Мәктәптә, мәдрәсәдә яхшы уку да үз әти-әниләреңә хөрмәт күрсәтү булып тора. Хәдистә шулай дип әйтелә: «Аллаһның ризалыгы – ата-аналарның ризалыгында»[1].

11. Балалар ата-аналарының намусын һәм яхшы исемен сакларга тиешләр. Әти-әниләрең турында начар сүз әйттерерлек, аларны нәрсәдә дә булса гаепләрлек эш эшләмәскә кирәк.

Хәдистә шулай дип әйтелә: Пәйгамбәр ﷺ әйткән: «Иң авыр гөнаһларның берсе – үз әти-әниләрең турында начар сүз әйтү». Сәхабәләр аннан сораганнар: «Ий Аллаһының Расүле, үз әти-әниләрен яманлаган кешеләр буламы соң ул?» Ә ул: «Була; бер кеше икенче кешенең әти-әнисен сүгә, яманлый, ә тегесе, үз чиратында, аның әти-әнисен сүгә һәм яманлый», – дигән»[2].

12. Әгәр дә кеше барган вакытта әти-әнисеннән алдарак барса, утырган вакытта алар утырганчы утырса, аларга аларның исеме белән мөрәҗәгать итсә, шәригать буенча, мондый очраклар да ата-аналарга ихтирам күрсәтмәү булып саналалар. Әти-әниләргә ихтирам белән мөрәҗәгать итәргә, аларга «әтием», «әнием», «әткәй», «әнкәй» һ. б. сүзләр белән дәшәргә кирәк.

13. Әгәр дә балалар кая да булса барырга җыенсалар, бу турыда алар башта үз әти-әниләре белән киңәшләшергә һәм аларның рөхсәтләрен алгач кына юлга чыгарга тиешләр.

Бервакыт Пәйгамбәргә ﷺ ниндидер бер яшь кеше йөгереп килгән дә, шулай дигән: «Мин Һиҗрәт (Мәккәдән Мәдинәгә күченү) уңаеннан сиңа ант итәргә килдем, тик минем әти-әниләрем мине аңламыйлар, елыйлар».

1 Имам Әт-Тирмизи; Хәким; Табарини

2 Имам Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Пәйгамбәр ﷺ аңа: «Син кире кайт һәм үз әти-әниләреңне, аларны еларга мәҗбүр иткән кебек үк, киредән көләргә дә мәҗбүр ит»[1], – дигән.

14. Сәдака тараткан вакытта аның савабын үз әти-әниләреңә багышлау – сөннәт гамәл булып исәпләнә. Хәдистә шулай диелә: «Әгәр дә сез сәдака таратып, аның савабын үз әти-әниләрегезгә багышласагыз, сезгә начар булырмыни?»[2]

15. Җомга көнне әти-әниләреңнең каберләрен зиярәт кылу – сөннәт гамәл булып исәпләнә. Хәдистә шулай дип әйтелә: «Һәр җомга саен үз әти-әниләренең каберләрен, яки аларның берсенең каберен зиярәт кылган кешенең Аллаһ бар гөнаһларын да кичерер һәм аны әти-әниләрен хөрмәт иткән һәм аларга итагать иткән кешеләр исемлегенә язар»[3].

16. Әгәр дә әти-әниләрең чакырса, алар кушканны шунда ук эшләргә кирәк.

17. Абый һәм апаларыңны да әти-әниләреңне хөрмәт иткән кебек үк хөрмәт итәргә кирәк. Хәдистә шулай диелә: «Абый кешеләрнең энеләре каршындагы бурычы – әти кешенең балалары алдындагы бурычы кебектер»[4].

Алда сөйләнгәннәрне бер сүз белән генә әйткәндә, ата-анасын җәберсеткән, интектергән кеше бәхетсезлек һәм кайгыларга дучар була; ә кем үз әти-әнисен хөрмәт итә, аларның ризалыгын, хәер-фатихасын ала, дөньяларның икесендә дә олуг бәхеткә ирешә. Хәдисләрдән аңлашылганча, әти-әниләренә игелек эшләгән кешеләр хаҗ һәм гомрә кылган яки газаватта катнашкан кешеләр алган кадәр савап алалар. Ата-аналарга карата игелекле булу – кешенең иң яхшы һәм Аллаһның иң яраткан сыйфатларының берсе.

---

1 Имам Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан

2 Хафиз Әт-Табарани хәдисләр җыентыгыннан

3 Хафиз Әт-Табарини хәдисләр җыентыгыннан

4 Хафиз Бәйхакый

Ата-аналар турында кайгырту, аларның ризалыгын алу – җәннәт капкаларының, гомерне озайтуның, тормыш бәрәкәтләренә ирешүнең ачкычы. Үз әти-әниләре турында кайгырткан балалар бар урында да Аллаһның ярдәмен һәм шәфәгатен алалар, хакыйкать юлына ирешәләр, алар өчен тормыш җиңеләя, алар котылуга ирешәләр. Ата-аналарның ризалыгын алу – Аллаһының ризалыгы белән нык бәйле. Хәдистә: «Җәннәт – аналарның аяк астында», – диелә. Без монда санап чыгылганнарның барысы да хәдисләрдән алынган.

Аллаһ безгә ата-аналарыбызның ризалыгын алырлык итеп яшәргә насыйп әйләсә иде! Әмин!

*Нияз хәзрәт Сабирҗанов,*

*Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге*

*Казан югары мөселман мәдрәсәсе мөгаллиме*

*29 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Гашурә көне

Мөхәррам ае һиҗри календарь – тәкъвим – буенча беренче ай булып килә. Хәрам булган, сугыш кылу тыелган дүрт айның берсе булып санала (зөлкагдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм раҗәб айлары). Бу айның фазыйләтен күрсәтеп, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә һәм дә Пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтендә искә алды. Шул сәбәпле, һәрбер мәселман бу айны лаеклы итеп үткәрергә тырышырга тиешле. Аллаһы Тәгаләне олылап, Пәйгамбәребезне ﷺ искә алып, салаватлар әйтеп үткәрсә, ин шә Аллаһ, зур әҗерләргә ирешер.

Бу айны кеше ничек итеп үткәрсә, аның калган бөтен айлары да шул рәвешле үтәр. Имам Газали хәзрәтләре үзенең «Ихъя гулумуд-дин» («Иман турында фәннең яңадан торгызылуы») китабында искә алып үтә: «Әгәр берәү мөхәррам аен гыйбадәттә үткәрсә, аның хәер-бәрәкәте елның калган айларына һичшиксез җитәр», – ди.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтә: «Рамазан аеннан соң ураза тотар өчен иң күркәм ай – ул мөхәррәм ае».

Шулай ук Пәйгамбәребез ﷺ хәбәр итә: «Әгәр берәү мөхәррам аеның бер көнен уразада үткәрсә, Аллаһы Тәгалә аңа утыз көн тоткан ураза әҗерен бирер». Бу айның дәрәҗәсен күрсәткән башка бик күп хәдисләр һәм риваятьләр бар.

Бу ай ни өчен соң шул дәрәҗәгә күтәрелде? Ни өчен бу айга шулай игътибар кылырга кирәк? Моның төп сәбәбе булып бу айда булган кайбер мөһим вакыйгалар тора. Шуларның берсе – Гашурә көне. Мөхәррам

аеның унынчы көнен «Гашурә көне» дип атап йөртәләр («ун» сүзе гәрәпчә – «гашара»).

Алдан әйтелгәнчә, мөхәррам ае айларның иң өлкәне, ә аның 10 нчы көне – бу айның кыйммәтлесе булып санала.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Мөхәммәд ﷺ Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, анда яшәүче яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотуларын күрә. Мөхәммәд ﷺ : «Сез бу көндә ни өчен ураза тотасыз?» – дип сорагач, алар бу көн – Муса عليه السلام Фиргавен гаскәреннән котылган көн, шул вакыйганы олылап тотуларын әйтә.

Мөхәммәд ﷺ : «Нәхнү әхакку биһә – без ул көнне ураза тотарга хаклырак», – дип, ураза тота башлый. Ләкин яһүдиләрдән аермалы буларак, ул көннән алдан бер көн һәм соңыннан бер көн өсти (димәк, 9, 10, 11 нче көннәр) .

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ хәдисендә: «Кем дә булса берәү Гашурә көнен олылап ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аның үткән елгы гөнаһларын кичерер», – дип хәбәр итеlә. Башка риваятьтә әйтелә: «Әгәр кеше Гашурә көнендә бер кечкенә орлык кадәр генә булса да сәдака бирсә, Аллаһы Тәгалә аңа Өхед тавы кадәр әҗер бирер». Шул рәвешле, мөселманнар бу көндә төрле изгелекләр кылалар, бер-берсен сөендерәләр, Аллаһы Тәгалә дә шул рәвешле аларны сөендерә.

Ни өчен соң бу көн мөселманнарның игътибарына лаек? Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бу көнне Аллаһы Тәгалә җир һәм күкләрне яратты, беренче кеше Адәм عليه السلام яратылды. Бу – аның җәннәткә кертелгән, аннан чыгарылган һәм дә тәүбәсе кабул ителгән көн.

Шулай ук бу көнне күп кенә пәйгамбәрләр төрле бәла-казалардан котылып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешкән. Мәсәлән:

– Нухның عليه السلام көймәсе коры җиргә җитеп, Джуди тавы итәгенә туктаган;

– Ибраһим пәйгамбәр عليه السلام туган;

– Гайсә ﵇ һәм Идрис ﵇ күккә ашкан;

– Ибраһимны ﵇ дошманнары утка ыргытканнан соң, ул уттан котылган;

– Муса ﵇ Фиргавен гаскәреннән котылган;

– Юныс ﵇ кит карынынннан котылган;

– Әюб ﵇ чиреннән дәва тапкан;

– Сөләйман ﵇ патша булган;

– Йосыф ﵇ төрмәдән азат булган һ.б.

Димәк, бу көннең дәрәҗәсе, һичшиксез, зур. Гашурә көнендә түбәндәге догаларны укырга киңәш ителә:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

حَسْبُنَا الله وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ

سُبْحَانَ اللهِ مِلْءَ الْمِيزَانِ وَمُنْتَهَى الْعِلْمِ وَمَبْلَغَ الرِّضَى وَزِنَةَ الْعَرْشِ لاَ مَلْجَاءَ وَلاَ مَنْجَأَ مِنَ اللهِ إِلاَ إِلَيْهِ سُبْحَانَ الله عَدَدَ الشَّفْعِ وَالْوَتْرِ وَعَدَدَ كَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّاتِ كُلِّهَا، أَسْئَلُكَ (نَسْئَلُكَ) السَّلاَمَةَ بِرَحْمَتِكَ يَآ اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ العَلِيِّ الْعَظِيمِ وَهُوَ حَسْبِى (حَسْبُنَا) وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ وَصَلَّى الله عَلَى سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ خَيْرِ خَلْقِهِ وَعَلَى آلِهِ وَصَحْبِهِ أَجْمَعِينَ.

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим**

**Хәсбүнәл-лаһи үәнигъмәл-мәүлә үәнигъмән-нәсыйр**

**Субхәәнәл-лаһи мил’әл-мизәни үә мүнтәһәл-гыйлми үә мәбләгар рида үә зинәтәл-гәршә лә мәлҗә’ә үә лә мәнҗәә минәл-лаһи иллә иләйһи.**

**Субхәәнәл-лаһи гадәдәш-шәфигый үәл-үитри үә гадәдә кәлимәтит-лаһи тәәммәәти күллүһә. Әс’әлүкә (нәс’әлүкә) әс-сәләәмәтә бирахмәтикә йә әрхәмәр раахимин. Вә ләә хәүлә үә лә куввәтә иллә бил-ләһил-галийййил-газыйм.**

**Үә һүә хәсби үә нигъмәл-үәкилү үә нигъмәл-мәүлә үә нигъмән-нәсыйру.**

**Үә салләллаһү галә сәйййидинә Мухәммәдин хайри халькыйһи үә галә әәлиһи үә сахбиһи әҗмәгыйн**

Мәгънәсе: Бу дөньяда барча мәхлүкләргә дә, Кыямәт көнендә мөэминнәргә генә рәхимле булган Аллаһ исеме белән. Безгә бары Аллаһ җитә. Иң яхшы ярдәмче, иң яхшы Мәүла һәм яклаучылар арасыннан иң яхшы Зат. Аллаһка Мизән тулганчы, Аның гыйлеме кадәр, Аның ризалыгын алганчы, Гәрш авырлыгы кадәр мактаулар булсын. Аллаһтан башка коткаручы юк. Аллаһка так вә җөп саннар, Аллаһның камил сүзләре саны кадәр мактаулар булсын.

Синең рәхмәтең илә тынычлык сорыйбыз, ий Рәхимле вә Шәфкатьле.

Аллаһта булган көч һәм куәт һичбер затта юк.

Ул миңа (безгә) җитә, Ул таянырлык иң яхшы Зат, ярдәм бирүче иң яхшы Зат. Иң күркәм кеше – Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның әһле бәйтенә вә сәхабәләренә Аллаһның салаваты вә сәламе булса иде.

Әс-Сухравәрди хәзрәтләре: «Гашура көнне бу доганы 10 мәртәбә укырга хәленнән килгән кешенең янына ул елны Газраил фәрештә килмәс.

Әгәр ул елны кешегә дөньядан китәргә тәкъдирендә булса, Аллаһы Тәгалә аңа бу доганы укырга мөмкинлек бирмәс!» – дигән.

Шулай ук тагын бер нәрсә хакында әйтмичә узып булмый, чөнки мәгълүмат чыганакларында бу вакыйганы киң яктырталар һәм аны Ислам дине белән бәйлиләр. Ул Мөхәммәднең ﷺ оныгы Хөсәен вафат булган көн (626-680). Без ул көндә аларга дога кылабыз. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорыйбыз. Ләкин башка фиркаләр кебек шуннан артык гамәлләр кылмыйбыз.

*Дамир хәзрәт Гаффаров,*

*Лаеш мөхтәсибәте*

*6 октябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1439 ел*

# Исламда вәгъдә төшенчәсе

Вәгъдә дигән төшенчә – адәм баласына бирелгән бик зур, җаваплы бер нигъмәт. Вәгъдә дигәч, күз алдына кемгәдер бирелгән сүз килә. Әлбәттә, бу шулай. Тормышыбызда без төрледән-төрле гәмәлләргә бәйле бит. Әйтик, бизнес, я булмаса гади дуслык, гади кибеткә барып сатып-алу булсын, без һәрдаим вәгъдә дигән төшенчә белән кисешәбез. Бизнеста берсе «шушының кадәр акчага сиңа шушы товарны бирәм» ди, ә дуслар «сиңа серемне сөйлим, бүтәннәргә чишмә» дип вәгъдә итә, вәгъдә ала. Хәтта әти-әни дә баласына «яхшы укысаң, сиңа фәлән әйбер алабыз», дип балага стимул бирә.

Ә дин күзлегеннән караганда, пәйгамбәрләр тормышында вәгъдә нинди чагылыш тапкан соң? Аны үтәү я булмаса үтәмәү нинди нәтиҗәләргә китерә? Вәгъдә хакында Аллаһы Тәгалә күп таркырлар Коръән Кәрим китабында, ә сөекле Расүл Әкрам ﷺ үз хәдисләрендә әйтә. Ислам динендә вәгъдә бик зур әһәмияткә ия. Вәгъдәне үтәмәүне Ислам шәригате монафикълык билгесе дип әйтә. Аллаһының сөеклесе Расүл Әкрам Мөхәммәд ﷺ бер хәдисендә әйтә: (мәгьнәсе) «Монафикъның 4 билгесе бар: 1) аңа ышанылган амәнәтне үтәмәс; 2) төзегән килешүне бозар, ягъни вәгъдәсен үтәмәс; 3) берәр вакыйга турында сөйләсә, ялганлап сөйләр; 4) сугыш кырында золымлык кылыр (монда сүз бүгенге көнге бер сәбәпсез кан кою турында бармый, ә үз илен, җирен саклагандагы сугыш хакында әйтелә) .

Корьәндә Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَا تَقْرَبُوا مَالَ الْيَتِيمِ إِلَّا بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ حَتَّىٰ يَبْلُغَ أَشُدَّهُ ۚ ﴿٣٤﴾

**«Үз вәгъдәләрегезне үтәгез, хакыйкатьтә, сез алар өчен соралырсыз».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:34

Тагын бер хәдистә әйтелә: «Кыямәт көнендә, кешеләр аларның тугры түгел икәнен белсеннәр өчен, һәрбер сатлык җанның, вәгъдәсен үтәмәүченең кулында байрак булыр». Ислам тугрысызлыкны катгый тыя. Шулай ук тагы бер хәдистә мондый сүзләр китерелә: «Гаделсезнең иманы юк, вәгъдәсендә тормаучының дине юк».

Расүл Әкрам ﷺ Әбү Бәкергә ؓ: «Гадел бул, ялганлама. Вәгъдәңдә тор, сиңа амәнәт итеп бирелгәнне сакла, бу пәйгамбәрләр васыятедер», – дигән. Әгәр дә кеше нәрсә дә булса вәгъдә итеп, шуны үтәми икән, ул үз-үзенә чокыр казый, минемчә, башкаларның үзенә карата ышанычын югалта. Бу китерелгән аять вә хәдисләр Исламда вәгъдәне үтәүгә никадәр зур игътибар бирелгәнен җитәрлек дәрәҗәдә күрсәтә. Ислам дине безне гадел, тугры һәм ышанычлы булырга өйрәтә бит.

Бүгенге көндәлек тормышыбызда кешенең берәр әйбере белән ант итү очракларын күзәтергә мөмкин. Кайбер халыкларда ипи яки ризык белән ант итәләр. Исламда бу тыелган. Расүл Әкрам ﷺ бу очрак турында үз хәдисендә болай дип әйтә:

إن الله ينهاكم أن تحلفوا بآبائكم فمن كان حالفًا فليحلف بالله وإلا فليصمت

Ягъни: «Аллаһы Тәгалә сезгә ата-анагыз белән ант итүне тыя. Кем дә булса вәгъдә бирсә, вәгъдәне бөек Аллаһ исеме белән әйтсен, яки дәшмәсен», – дигән.

Аллаһ исеменнән яки Аның сыйфатыннан башка бүтән әйбер белән бирелсә, бернинди дә вәгъдә дөрес булмый.

Расүлебез сөннәтендә шулай ук сүздә тору бик әһәмиятле урын ала. Сүзендә тормаган кешеләр хәтта монафикъ дәрәҗәсенә төшәргә мөмкин.

Газиз дин кардәшләрем, мин кешедә барыннан да бигрәк сүзендә тору һәм гаделлек кебек сыйфатларны хөрмәт итәм. Болар, минемчә, иң төп сыйфатлар һәм кеше шул сыйфатларга ия булу-булмау белән бәяләнә. Мин үземдә шул сыйфатларны булдыру өчен тырышам: ялганламаска тырышам, вәгъдәмне үтим.

Ялганчы, намуссыз кеше дә тормышта югарылыкка ирешергә мөмкин, әлбәттә, тик аның якын дуслары, чын хисләре булырмы икән?! Юктыр, мөгаен.

Юлларыбызда тугры, гадел кешеләр күбрәк очрап торсын өчен, без үзебездә чын кеше сыйфатларын булдырырга тиешбез.

Аллаһ Тәгалә барчабызга да бары тик чын мөэминнәрдә була торган сыйфатларга ия булырга насыйп итеп, золым кылучы, ялганчы, монафикъ булудан сакласа иде. Һәммәбезгә ике дөнья бәхетен биреп, ахыргы урыннарыбыз җәннәттә булса иде. Әмин!

*Руфат хәзрәт Мөслимов,*

*Питрәч районы Көек авылы имам-хатыйбы*

# Редакция хаты

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһ!

Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз! Журналыбыз редакциясе сезне хезмәттәшлек итәргә чакыра.

Пәйгамбәребез ﷺ хәдисләрендә мөселманнарга булган гыйлемнәре белән уртаклашуның зарурлыгын әйтеп калдыра. Шулай ук имам Әхмәд: «Белем байлыкка охшаган: байлык күбрәк булган саен, аннан күбрәк зәкәт түләнә», – дип әйткән. Имам Гали ؓ әйткән: «Белүче үз гыйлемнәре белән бүлешә барган саен, аңа яңа гыйлем чыганаклары ачыла бара, алар үсә, ныгый һәм аныклана. Башкаларны укытканда ул элек алган белемен ныгыта һәм яңасын ала».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырырга теләсәгез, «Сорау-җавап» рубрикасында кызыксындырган сорауларыгызга җавап аласыгыз килсә, «Әңгәмә» сәхифәсе өчен интервью бирергә, редакция хезмәткәрләренә киңәшләрегезне җиткерергә теләгегез булса, **shura@huzur.ru** электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый, +7 (843) 202-07-74 номерына шалтырата аласыз.

Редакциягә килгән язмалар үзгәртелә ала, бастырылмаска мөмкин һәм кире кайтарылмый.



# Сорау – җавап

## 1. Үлем түшәгендәге кеше янында үзеңне ничек тотарга?

Мохтазар – үлем алды газабын кичерүче кеше. Сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә, кемнең хозурына кем дә булса килсә, шул мохтазар була. «Китаб-әл-җәнаиз» текстында – үлем алды газабында торган кеше аның янында фәрештәләр пәйда булганнан соң мохтазарга әйләнә. Үлем түшәгендә яткан кешене соңгы мизгелләрендә генә, тормышның ахыры ап-ачык булып күренеп торганда гына, аны мохтазарга саный алалар.

Үлем билгеләренә түбәндәгеләр керә:

– кешенең аяклары суына, хәлсезләнә;

– сулышы авырая, тизләшә, өзек-өзек була башлый;

– борыны җиңелчә бөгелә.

Мохтазар янында булучылар аңа рухи яктан ярдәм итәргә тиешләр.

1. Үлем хәлендәге кешенең янында госелле булу хәерле. Мохтазарның колагына акрын тавыш белән тәлкыйн кылалар: тәһлил яисә шәһадәт сүзе әйтелә, үзенә көчләп әйттерергә ярамый.

Тәһлил – «Ләә иләһә илләллаһ». Мәгънәсе: «Аллаһтан башка һичбер илаһ юк».

Шәһадәт сүзе – «Әшһәду ән ләә иләәһә илләллааһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһүү үә расүүлүһ». Мәгънәсе: «Мин шәһадәт кылам, Аллаһтан башка һичбер илаһ юк. Янә шәһадәт кылам, Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе».

Бу сүзләрне әйтүнең максаты – боларны үлем хәлендәге кешенең исенә төшерүдер.

Пәйгамбәребез ﷺ бер хәдисендә: «Соңгы сүзе «Ләә иләһә илләллаһ» булган кеше җәннәткә керер», – дип әйтә.

2. Аның янындагылар Коръәннең 36нчы сүрәсе «Йәсин» яки 67 нче «Әл-Мүлк» («Тәбарәк») сүрәсен укырлар. Динебез бу сүрәләрнең укылуын саваплы күрә. Үлем хәлендәге кеше янында «Йәсин» сүрәсен уку үлем газабын җиңеләйтә.

3. Үлем хәлендәге кешенең янында Коръән укый белмәгәннәр туган телләрендә хәер-дога кылырлар.

Пәйгамбәребез ﷺ: «Бер хастаның яисә бер мәетнең янында булсагыз, хәерле бер сүз әйтегез. Чөнки фәрештәләр ул сүзнең кабул ителүе өчен «Әмин» дип дога кылырлар», – дигән.

Якын иптәше Әбү Сәләм ؓ вафат булганда да, Пәйгамбәребез ﷺ аның өчен хәер-дога кылган, иптәше өчен Аллаһыдан рәхмәт һәм мәгъфирәт сораган, ахирәттә зур дәрәҗәләр, каберендә рәхәтлек теләгән.

Мохтазарны «Ләә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтергә мәҗбүр итү кирәкми. Кәлимә, мохтазар да аны кабатласын өчен, аның колагына ишетелергә тиеш. Мохтазар кәлимәне әйткәнче, янындагылар кәлимә әйтүне дәвам итәргә тиешләр. Мохтазар кәлимәне әйткәндә, аның янындагылар эндәшми торырга тиешләр. Мохтазарның һаман кәлимә әйтеп торуына басым ясарга кирәкми. Соңгы мизгелгә кадәр аны әйтеп тору мөһим түгел. Максат шунда ки, кәлимә үлем түшәгендә ятучының дөньяда әйтелгән соңгы сүзләре булырга тиеш.

Ә мохтазар кәлимәдән соң башка сүзләр сөйләсә, янындагылар, ул да кабатласын өчен, тагын кәлимә әйтә башларга тиешләр. Мохтазар яңадан кәлимәне әйткәннән соң тынлык сакланырга тиеш. Соңгы мизгелләр якынайганда, мохтазар авыр итеп, тиз-тиз сулаганда, янындагылар тагын, кычкырып, кәлимә әйтергә тиешләр.

Мохтазар янында дөнья сүзләре сөйләшергә ярамый, чөнки ул мохтазарны дөньялыкка тарта. Бу темага сөйләшү зыянлы. Үлүче Аллаһ турында фикер йөртсен өчен тырышырга кирәк. Дөньяга тартылучы йөрәк белән бакыйлыкка күчүнең ахыры начар була.

## 2. Вафат булган кеше алдындагы вазыйфаларыбыз

Мохтазарның улгәненә тәмам инангач, түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

1. Мәетнең авызы ачык калмасын дип, ияк астыннан баш өстенә бер чүпрәк яисә яулык бәйләнә.

2. Кайбер мәетләрнең күзләре ачык кала. Мондый вакытта мәетнең күзләрен ябарга һәм түбәндәге доганы укырга кирәк:

بِاسْمِ اللهِ وَعَلَى مِلَّةِ رَسُولِ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيهِ وَسَلَّمَ ، اللَّهُمَّ يَسِّرْ عَلَيهِ أَمْرَهُ وَسَهِّلْ عَلَيهِ مَا بَعْدَهُ وَأَسْعِدْهُ بِلِقَائِكَ ، وَاجْعَلْ مَا خَرَجَ إِلَيهِ خَيْراً مِمَّا خَرَجَ مِنْهُ.

«Бисмил-ләәһи үә галә милләти расуулил-ләәһ ﷺ. Әллааһуммә яссир галәйһи әмраһу вә сәһһил галәйһи мә бәгдәһу вә әсгидһу бәлика’икә вәджгәл мә харажә иләйһи хайран миммәә хараджә минһу».

«Аллаһ исеме белән башлыйм, бу кеше Аллаһ расүле ﷺ тарафдарларыннан. Аллаһ, аңа ярдәм ит, көткәннәрендә җиңеллек бир. Ул бәхетле булсын. Ул күрәчәк инде күргәннәреннән яхшырак булса иде».

3. Вафат булган кеше ятагыннан чыгарыла. Мөмкин булса, суык бер бүлмәгә урнаштырыла. Каты урынга җәймә җәеп, шунда яткырыла. Өстенә юка бер җәймә ябыла, бите яулык белән каплана.

4. Куллары гәүдә буйлап турылап сузыла.

5. Аякларын кыйблага каратып яткыралар. Аяклары туры ятмаса, сузып куеп яулык яки чүпрәк белән бәйлиләр.

6. Мәетне япкан җәймә өстенә, эче күпермәсен өчен, кайчы кебек бер тимер авыр әйбер куела.

7. Мәет янына, исе чыкмасын өчен, ылыс яки кычыткан; астына ләгән белән марганцовка салган су куярга мөмкин, кыш көне ләгәнгә кар яки боз салырга була. Төнгә ике тапкыр алыштырыла.

8. Мөмкинлек булганда, мәет юылганчы, Коръәнне күрше бүлмәдә уку хәерлерәк.
9. Кеше вафат булганны халыкка белгертү дин ягыннан мөстәхәбтер, саваплы эштер.

*«Мәет озату йолалары» китабыннан,*
*«Хозур» нәшрият йорты, 2016*

## 3. Кешегә зур күләмдә акча тиешле булсалар, ул зәкәт алырга хокуклымы?

**Сорау: бер кардәшебез сату эшләре белән шөгыльләнә иде. Ул кешеләргә бурычка нисаб күләменә кадәр җитә торган зур суммалар бирә иде. Әмма хәзер шул акчаларны кире кайтара алмый һәм мохтаҗлык кичерә. Без, аның авыр хәлдә булуын белеп, аңа зәкәт түләргә булдык. Тик кайбер кардәшләр, зур акчалар тиешле булгач, аның зәкәт алырга хакы юк, диләр. Безгә нишләргә?**

Җавап: әгәр бурычка бирүче кеше бурычка нисабтан күбрәк сумма биргән, һәм аңа бу бурычны өлешләп булса да кайтарсалар, бу очракта аның зәкәт алырга хакы юк. Әмма аңа акчаларын кайтармасалар, һәм ул мохтаҗ булса, бу инде бөтенләй башка мәсьәлә.
Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә зәкәт алырга хокуклы кешеләрне саный:
**«Сәдакалар – фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкәт җыючыларга, вә зәкәт өчен Исламга күңелләре өлфәт хасыйл иткән кешеләргә, тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, Ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган**

**мосафирларгадыр. Шул Аллаһтан фарыз ителде. Аллаһ Белүче вә хөкем Итүче».**

«Тәүбә», 9:60

Зәкәт тиешле булган кешеләр саналган бу аятьтә юлда калган мосафир да искә алына. Хәтта туган җирендә бу кеше бай булса да, аңа зәкәтне алырга ярый. Һәм хәтта туган җиренә кайтып җиткәндә, аңа бирелгән зәкәт өлеше артса да, ул бу өлешне мохтаҗларга бирергә тиеш булмый. Әлбәттә, мондый хәлдә калган кешегә, өенә кайтып җитәргә кирәк акчадан артыгын алырга кирәкми. Әмма ул артыгын алса, әйтеп кителгән хөкем булыр.

Соравыгызда сүз барган кешенең хәле дә шундый ук. Ягъни ул, үз акчаларын башкаларга биреп торып, мохтаҗ булып калган. Ул мохтаҗ булганга күрә, аның зәкәт алырга хакы бар. Ә Аллаһка яхшырак билгеле.

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*Камил хәзрәт Сәмигуллин*

# Үрнәк затлар

# Сәгъд ибн Әбү Вәккас

**Исеме:** Сәгъд ибн Әбү Вәккас (Мәлик[1]) ибн Вүһәйб ибн Габдел-манаф ибн Зөһра ибн Киләб ﷺ.

Сәгъд ибн Әбү Вәккас ﷺ Әбү Вәккас һәм Хәминәт бинт Суфьян гаиләсендә дөньяга килә. Ул Пәйгамбәребез ﷺ белән бер кабиләдән – Корәеш кабиләсеннән. Аның шәҗәрәсе Мөхәммәд пәйгамбәрнеке ﷺ белән Пәйгамбәрнең әнисе Әминә бинт Вәһб ягыннан дүртенче буында кисешә. Сәгъдне күргәндә, Пәйгамбәр ﷺ еш кына: «Бу әнием ягыннан туганым», – дип әйтә торган булган[2].

**Тышкы кыяфәте:** Ибн Кәсир әйткән: «Сәгъд ибн Әбү Вәккас урта-ча буйлы, нык гәүдәле, кара кучкыл тәнле, бөдрә чәчле һәм каты куллы иде...»

**Яшәгән еллары:** ул 592 елда Мәккә шәһәрендә туа һәм 674 елда Мәдинәдә вафат була.

## Исламны кабул итүе

Ислам кабул иткәнчегә кадәр Сәгъд төрле һөнәрләр белән шөгыльләнә, күпчелек ул уклар эшли, хөрмә плантацияләрен эшкәртә, хөрмә үстерә, балта остасы да була. Сунарчылык белән кызыксына, һәрвакыт корәешлеләрнең башлыклары һәм аларның уллары белән була, бар вакытын яшь кабиләдәшләре белән дөнья хәлләре турында сөйләшеп,

1 Сәгъднең әтисенең исеме – Мәлик, ә куньясе Әбү Вәккас була, шул сәбәпле ул бу исем астында билгеле.

2 Имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан

дөньякүләм вакыйгалар белән кызыксынып, алар турында Мәккәне зиярәт итүчеләрдән сораштырып үткәрә торган була.

Сәгъд ибн Әбү Вәккас ﷺ Исламны бик иртә, нибары 17 яшь булганда кабул итә. Үзе турында ул: «7 көн дәвамында мин Исламның дүрттән бер өлеше булдым», – дип әйткән. Ул вакытта алар, Исламны кабул итүчеләр, дүртәү генә була.

Сәгъднең Исламга килү тарихы билгеле.

Берзаман ул төш күрә: ул караңгы бер җирдә бара икән, һәм ераграк барган саен, караңгылык көчәя. Кинәт ул яп-якты ай нурларын күрә һәм шул якка юнәлә. Анда ул Әбү Бәкер, Гали һәм Зәйд ибн Харисны очрата ﷺ. Сәгъд аларның монда ничек эләгүләрен сорый. Алар монда күптән түгел генә килүләрен әйтә. Икенче көнне аны Әбү Бәкер очрата һәм Исламга чакыра. Сәгъд төшендә күргәннәрне исенә төшереп, айның Расүлүллаһны ﷺ белдерүен, моны Аллаһы Тәгаләдән билге булуын аңлый һәм Ислам кабул итә. Шул рәвешле ул Исламны иң беренче кабул итүчеләрдән була.

Исламны кабул итү белән аның тормышы кыенлаша. Сәгъднең әнисе улының Ислам кабул итүен күпмедер вакыт белми тора. Әмма моны белгәч: «Ий улым! Син динебездән баш тарттыңмы?! Син Мөхәммәдтән ваз кичмичә, мин эчмәячәкмен, ашамаячакмын, күләгәдә ышыкланмаячакмын (кояш астында торачакмын)!» – дип белдерә.

Берничә сәгать үткән саен, Сәгъд ябыгып, суырылып беткән әнисенә су белән ризык алып килеп йөри, әмма әнисе аларны алудан баш тарта. Сәгъд аңа: «Әнием! Мин сине бик яратам, әмма Аллаһны һәм Аның Расүлен мин ныграк яратам. Аллаһ белән ант итәм, әгәр синең мең тормышың булып та, аның һәрберсе бер-бер артлы китеп торса, мин бары бу диннән баш тартмас идем», – ди.

Улының катгыйлыгын күреп, ана антыннан баш тарта, эчә һәм ашый башлый, ягъни гадәти тормышына кайта.

Сәгъд һәм аның әнисе турында Коръәннең түбәндәге аятьләре индерелә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ
أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ ﴿١٤﴾ وَإِن جَاهَدَاكَ عَلَىٰ أَن تُشْرِكَ
بِي مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا ۖ وَصَاحِبْهُمَا فِي الدُّنْيَا مَعْرُوفًا ۖ وَاتَّبِعْ
سَبِيلَ مَنْ أَنَابَ إِلَيَّ ۚ ثُمَّ إِلَيَّ مَرْجِعُكُمْ فَأُنَبِّئُكُم بِمَا كُنتُمْ تَعْمَلُونَ ﴿١٥﴾

**«Кешегә без ата-анасына яхшылык итәргә әмер иттек, баланы анасы зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән күтәрде, ягъни корсагында авырлык белән күтәрде вә авырлык белән тудырды, вә ике яшендә баласын күкрәгеннән аерды. Миңа вә ата-анаңа шөкер ит, дип боердык, ахырда бит Миңа кайтасыз. Әгәр ата-анаң сине Миңа ширек итүеңә көчләсәләр, ул вакытта аларга итагать итмә, аларга дөнья эшләрендә яхшылык белән эш кыл, диндә Мине берләү вә итагать итү белән Миңа инабәт иткән мөэминнәр юлына ияр, соңыннан Миңа кайтырсыз, кылган эшләрегездән үзегезгә хәбәр бирермен».**

«Локман», 31:14-15

## Сәгъд ибн Әбү Вәккасның сыйфатлары

Сәгъд ибн Әбү Вәккасның горурланырлык күркәм сыйфатлары күп була. Ул һәрвакыт гөнаһтан һәм хәрамнан ерак торган.

Әмма ул беркайчан да үз яхшы сыйфатлары һәм хезмәтләре белән мактанмаган, бары ике өстенлеген таныган. Беренчесе – ул Ислам өчен ук аткан беренче кеше була. Бу вакыйга Гөбәйдә ибн Харис җитәкләгән яу

вакытында була. Бу гаскәрне Пәйгамбәр ﷺ Рабигъ дип аталган җирлеккә җибәргән була[1].

Икенчесе – ул Пәйгамбәр ﷺ үз әти-әниләре аның өчен йолым булачак, дип әйткән бердәнбер кеше була. Бу Өхед сугышы вакытында була. Гали ибн Әбү Талиб ﷺ: «Минем беркайчан да Пәйгамбәребезнең үз әти-әнисен Сәгъдтән кала кем өчендер йолым булуына өметләневен әйткәнен ишеткәнем булмады. Өхед көнендә мин Пәйгамбәрнең ﷺ: «Ат, Сәгъд. Минем әти-әнием синең өчен йолым булсын», – дигәнен ишеттем», – дип әйткән.

Сәгъд иң кыю гарәп һәм мөселман җайдакларыннан булган. Аның ике төрле коралы була – сөңге һәм дога. Ул, дошманга төзәгәндә, беркайчан да ялгышмаган, һәм Аллаһка мөрәҗәгать иткәндә һәрвакыт җавап алган.

Ул да, башка сәхабәләр дә Пәйгамбәрнең ﷺ аның өчен дога кылып торуын беләләр иде. Бервакыт Пәйгамбәрнең Сәгъд өчен мондый дога кылуы билгеле: «Йә Аллаһ, аның сөңгесен үткен ит һәм догаларына җавап бирче».

Бик тәкъва кеше буларак, Сәгъд еш елаган. Ул Пәйгамбәребезнең сүзләрен, нәсыйхәтләрен тыңлаганда бик елый торган булган, аның күз яшьләре шулкадәр күп булган, алардан хәтта тезләре юешләнгән.

## Җәннәт турында хәбәр

Берзаман Пәйгамбәр ﷺ сәхабәләре белән утырганда офыкка карап, ни ишеткәненә дикъкать итеп утырган. Аннан соң ул янәшәдәгеләренә карап: «Тиздән монда Җәннәт әһелләренең берсе киләчәк», – дип әйткән. Сәхабәләр, бу бәхетле кешенең кем икәнен белергә тырышып, тирә-якка карый башлый. Ниһаять Сәгъд килә.

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

Соңрак Габдуллаһ ибн Гамр ибн Гас аның мондый бүләккә нинди гамәле белән лаек булуын белергә тырыша. Сәгъд: «Минем гамәлләрем һәм гыйбадәтем сезнекеннән артыграк түгел, бары миндә бер генә мөселманга карата да нәфрәт хисе юк», – дип җавап кайтара.

## Сәгъд ибн Әбү Вәккасның кыюлыгы

Ул Бәдер, Өхед, Хандәкъ, Хөдәйбия, Хайбәр сугышларында, Мәккәне яулап алганда һәм башка бар яуларда катнашкан. Ул мөселманнарга зур хәрби ярдәм дә, тугры хәлифәләр вакытында сәяси булышлык та күрсәтә.

Бәдер сугышында аның абыйсы вафат була. Өхед сугышында ул Мөхәммәдне ﷺ саклаган 10 сәхабәләрнең берсе була. Бу көнне аның җәясеннән меңләгән уклар җибәрелә, аннан соң Пәйгамбәр аңа үз укларын бирә.

Ул Әбү Бәкер, Гомәр һәм Госман ﷽ вакытында җаваплы вазифаларда була. Гомәр ибн Хаттаб хакимлеге вакытында Сәгъд Сасанидлар империясенә каршы Әл-Кадисий сугышында мөселман гаскәрен җитәкли. Госман хакимлеге чорында Куфаның әмире була.

Гомәр ﷽ үлеме алдыннан Сәгъдне Госман ибн Гаффанны хәлифә итеп сайлаячак алты сайлаучы рәтенә кертә. Шул ук вакытта ул Гали ибн Әбү Талиб, Зөбәер ибн Гаввәм, Габдрахман ибн Гауф, Талхә ибн Гөбәйдуллаһ ﷽ белән беррәттән, хәлифә вазифасына дәгъва белдерүче 6 сәхабә арасында була.

## Сәгъд ибн Әбү Вәккасның юмартлыгы

Вакытлар үтү белән, Сәгъд иң бай мөселманнарның берсе була. Аның вафатыннан соң зур байлык кала.

Ул мул иганәләре, керем чыганакларының хәләл булуын җентекле тикшерүе белән билгеле булган. Аның хәләл акча табу сәләте Аллаһ ризалыгы өчен малын кызганмавыннан ким булмаган.

Соңгы хаҗ елында, Пәйгамбәрне ﷺ озата барып, Сәгъд ибн Әбү Вәккас бик каты авырый. Пәйгамбәр аның хәлләрен белешергә килгәч, ул: «Ий Пәйгамбәребез, бердәнбер кызымнан кала балаларым юк, ә байлыгым бик күп. Шул байлыкны тулысы белән Аллаһ юлына тотарга рөхсәт ит!» – дип үтенә. Әмма Пәйгамбәр рөхсәт итми. Сәгъд байлыгының яртысын тотарга рөхсәт сорый. Пәйгамбәр янә: «Юк», – дип җавап кайтара. «Ә өчтән берен?» – ди Сәгъд. Пәйгамбәр: «Мөмкин. Әмма бу да күп була. Чөнки бай варислар калдырсаң, бу син аларны мохтаҗ итеп калдыруыңнан яхшырак. Аллаһ юлында нидер сарыф итсәң, хәтта бу хатыныңа биргән (ризык) кисәге булсын, моның өчен син, һичшиксез, саваплар алырсың».

Әмма Сәгъд бер генә кыз әтисе булып калмый, соңрак Аллаһ аңа башка балалар да насыйп итә.

## Сәгъд ибн Әбү Вәккасның вафаты

Гали رضي الله عنه хакимлегенең соңгы елларында мөселманнар арасында фетнә күбәя һәм Сәгъд бар эштән дә читкә китеп, гаиләсе һәм балалары белән Мәдинә янындагы Әл-Акик җирлегенә күченә. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул шунда яши. Ә вафатыннан соң аның гәүдәсен Мәдинәгә күчерәләр һәм бар сәхабәләр белән «Әл-Бакый» зиратында җирлиләр.

Бу бөек сәхабә 79 яшендә, Һиҗрәтнең 66 елында вафат була. Аннан 270 хәдис тапшырылган.

Сәгъд озын һәм бәхетле тормыш күрә, Аллаһ аңа җитәрлек нигъмәтләр бирә. Әмма үлеме алдыннан ул тузып беткән йон җөббәсен алып килүләрен сорый һәм: «Киемем минем кәфенем булсын. Бәдер сугышында мин бу киемдә мәҗүсиләр белән көрәштем һәм Аллаһ Тәгалә хозурына нәкъ анда киләсем килә», – ди.

# Мөслимә

# Бала һәм дин

Балага дин кирәкме? Җавап: «Әлбәттә! Кешенең күңеленә «дин» дигән орлыкны салу өчен иң кулай вакыт – балачак. Чөнки әле бу вакытта балада фәрештә сыйфатлары өстенлек итә. 7 яшькә кадәр Аллаһка мәхәббәт формалашкан булырга тиеш. Бүген еш кына: «Дингә кайчан килдең?» – дип сорау бирәләр. Әгәр без кечкенәдән дөрес тәрбия бирә алсак, бала үзенең динсез вакытын хәтерләмәячәк. Дин аның өчен үзе белән бергә дөньяга килгән һәм үлгәнче алып барасы хакыйкать булып торачак, һәм инде ул динсез яшәүне күз алдына да китерә алмый. Дөнья яратылганда Аллаһ Раббыбыз барча җаннарны яратты һәм Үзен аларга танытты. Шул сәбәптән, бу дөньяда яшәүче һәркемнең ашау-эчүгә ихтыяҗы булган кебек, дингә дә ихытяҗы бар. Әгәр без үз вакытында бу мәсьәләгә игътибар бирә алмасак, бала очраклы секталарга эләгеп, ясалма диннәрдә яки аракы эчеп, наркотик кулланып, җанына тынычлык табарга омтылачак. Шуңа күрә дә без, соңга калмыйча, Ислам дине кыйммәтләрен балабызга төшендерергә тиеш булабыз.

Бүген илебездә, шулай ук Ислам динендә булмаган башка илләрдә дә күпме реабилитация үзәкләре бар. Кешеләрне алкоголизмнан һәм наркомния афәтләреннән арындыру максатыннан күпме чыгымнар тотыла. Ләкин кешелек дөньясында бу афәтләр белән тормышларын җимерүчеләрнең саны гына кимеми. Үз вакытында Ислам дине кыйммәтләре аңлатылса, бала хәрамнан чирканып, аның зур гөнаһ икәнен аңлап үссә, бу афәтләр күпкә кимрәк булыр иде. Динсез кеше башаягы белән дөнья мәшәкатьләренә чумган, аның күңел күзе тоныкланган, фәрештә сыйфатларын хайвани һәм шайтани сыйфатлар күмеп киткән була. Ул үз тормышында нәрсәнеңдер җитмәвен тоя, җаны тыныч түгел, бәргәләнә, әйтерсең лә, судан яр кырыена чыгарып ташланган балык. Үз

вакытында аның дине аңлатылмаган, шул сәбәпле хакыйкатькә килә алмый азаплана.

Бүген нинди күркәм мәчетләр төзелеп тә, 60–70 яшьлекләрнең мәчет ишеген ачып керергә ихтыяр көчләре булмау – ул да шушы ук сәбәптән. Бу очракта муллаларны гына гаепләү дөрес түгел. Үз вакытында күңелләренә Аллаһка мәхәббәт салынганлыктан, тыеп, кисәтеп, хурлап торуга да карамастан, безнең бабайлар кача-поса булса да, салам җәелгән суык лапасларда да гает укырга бардылар, җомгаларын калдырмадылар, өйдә биш вакыт намазларын да укыдылар, урыннары оҗмахта булсын.

Бүген кешелек җәмгыятенең рухи кризис кичерүе, эчүчелек, җинаятьчелекнең үсүе, кешеләрнең үз-үзләренә кул салулары үз вакытында аларга дин турында тиешле мәгълүмат бирелмәүдән килә. Әмма балага Ислам диненә мәхәббәт тәрбияләү белән бергә, башка диндәгеләрне дә хөрмәт итәргә өйрәтү зарур. Аллаһ Раббыбыз да: «Өйләрдән куып чыгармасалар, көчләп хәрам ризык ашатмасалар, динең өчен сине кыерсытмасалар, алар белән тыныч яшәгез», – ди.

Диннең төп бурычы – баланың югары рухи үсешен тәэмин итү. Рухи үсешнең ачкычы булып Аллаһны тану тора. Әгәр бу ачкыч югалса, тормышта туры юлны табу балага бик кыен булачак һәм ул туры юлга зур ялгышлар, фаҗигаләр аша, авырлык белән килергә мәҗбүр булачак, бәлки, моңа гомере дә җитмәс. Һәр эшне: «Әгүүзү билләәһи минәшшәйтаанирраҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим»не әйтеп башлатырга гадәтләндерү, иман кәлимәсен: «Ләәә иләәһә илләллаааһ Мүхәммәдүр Расүүлүллааһ»ны өйрәтү дә аеруча мөһим. Бала көн саен кимендә 100 мәртәбә: «Ләә иләәһә илләллааһ», дип әйтергә гадәтләнсен.

Әмма кечкенә вакытта балага артык күп гыйбадәтләр йөкләү урынлы түгел. Кирәгеннән артык су сипсәң, гөл дә корый. Мәҗбүри фарызлар балигъ булгач кына үтәлә. «Балигъ булгач, укыр әле», – дип яшәү дә дөрес түгел. Балага дөньяны таныту, табигатьне өйрәтү, фикерләү сәләтен үстерү

юлы белән Аллаһка мәхәббәтне көчәйтергә һәм шуның нәтиҗәсендә әкрен генә фарызларны үтәргә гадәтләндерергә, хәрамнан тыелырга өйрәтергә кирәк. Балигъ булгач кына өйрәтә башласак, соңга калган булабыз.

Баланың ышануы белән шаярырга ярамый, ул ышанса, чын күңелдән ышана, өлкәннәрдәге кебек ясалмалык, икейөзлелек әле анда формалашып җитмәгән. Шул самими ышанычны җимерү – бөтен кешелек дөньясы алдында иң зур җинаять. Балага Аллаһ турында, фәрештәләр турында сөйләү, аңлату зарур булса да, өрәкләр, җеннәр турында сөйләмәскә, куркытмаска кирәк.

Әгәр балага кечкенәдән: «Минем турыда уйлаучы һәм һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торучы, догаларымны ишетүче, кайгыларымны аңлаучы Зат – Аллаһ бар», – дигән хакыйкатьне аңлата алсак, иң зур тәрбия биргән булырбыз. Моны әти-әни генә түгел, ясле-бакча тәрбиячеләре дә, укытучылар да аңласа иде.

Аллаһ 12 яшьтән үсмерләр алдына төрле юллар куя. Психолог галимнәр аны кеше тормышының бер циклы тәмамланып, икенче циклга күчүе, дип аңлаталар. Шуның өчен дә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа ﷺ: «Балаларыгызга 7 яшьләрендә намаз өйрәтегез, 10 яшьтә намаз укымаса, тәрбия камчысы өстен булсын», – диде. Әгәр бала намаз укырга гадәтләнмәсә, 12 яшендә ялгыш юлга кереп китүе бик мөмкин. Бер ялгыш юлга кергән кешене кире чыгару җиңел түгел.

Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

اتْلُ مَا أُوحِيَ إِلَيْكَ مِنَ الْكِتَابِ وَأَقِمِ الصَّلَاةَ ۖ إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ وَلَذِكْرُ اللَّهِ أَكْبَرُ ۗ وَاللَّهُ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ﴿٤٥﴾

**«Намаз укучыны намаз бозык, фәхеш, ярамаган эшләрдән саклый»,** – диде.

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Димәк, балабыз бозык-фәхеш эшләрдән ерак булсын дисәк, намазга өйрәтү кирәк икән, хәтта көч кулланып булса да.

Казан ГИДУВының профессор-психиатры, медицина фәннәре докторы Анатолий Михайлович Карпов «Самозащита от наркомании» дигән китабында: «Гыйбадәт вакытында кешенең организмы сәламәтлеккә һәм психикага уңай йогынты ясый торган шулкадәр көчле шифалы матдәләр бүлеп чыгара, аны бернинди дару да алыштыра алмый», – дип яза.

Шул китаптан өзек китерәм: «Молитва является сложной конструкцией их психических и биологических процессов, оказывающей комплексное фармако- и психотерапевтическое воздействие на молящегося, точно дозированное, дифференцированное, не оказывающее побочных действий, всегда доступное и бесплатное.

Это набор характеристик идеальной терапии, о которой врачи могут только мечтать, а религия пользуется ею уже тысячи лет. Среди верующих нет наркоманов».

Без балабызны намаз укырга гадәтләндереп, аны бозык эшләрдән саклаучы чара белән тәэмин итеп кенә калмыйбыз, ә сәламәтлеген саклаучы механизмны да кулына тоттырабыз булып чыга.

Мин бер мәктәптә узган ата-аналар җыелышында шундый мәгълүмат алдым: биредә укучы 269 бала медицина тикшерүе үткән һәм шулардан 26сы гына сәламәт дип табылган. 90 процент баланың авыру булуын аларга үз-үзләрен дәвалау өчен бирелгән «намаз» дигән олуг гыйбадәтне үтәмәүнең дә нәтиҗәсе дип карау кирәктер.

Кайберәүләр иртәнге намазга, сәхәргә уятырга, ураза тоттырырга балаларын җәллиләр һәм инде бала фарызларны үтәргә гадәтләнми кала. Ашап, эчеп, күңел ачып кына яшәү балада хайвани хисләрен арттыра һәм аның үз-үзен генә яратуына китерә. Аның фикеренчә, башкалар фәкать аны көйләп, аңа хезмәт итеп кенә яшәргә тиеш булалар.

Кечкенә чактан ук хәтта уенчык бирсәң дә: «Кая, кире бир әле, әнә теге бала да уйнап карасын», – дип, алудан гына түгел, ә бирүдән дә балада тәм табарга өйрәтү кирәк. Әлбәттә инде, бала рәхмәт әйтергә дә гадәтләнсен. Ул нинди генә эшкә тотынса да, ахырына кадәр җиткерүен игътибарда тотарга, күпмедер дәрәҗәдә аңа булышырга да кирәк. Бу, үз чиратында, баланы максатка ирешүдә сабыр булырга һәм һәртөрле хезмәттән тәм табарга өйрәтә. «Әйдә, азапланма, ташла, кемгә кирәк ул», – дип кәефен төшерү, шөгыленнән туктату һич кенә дә ярамый, чөнки ул ихтыярсыз булып үсәчәк. Ихтыяр көче тәрбияләүдә фарыз гамәлләрнең йогынтысы да искиткеч зур. Намаз – балага игътибарын тупларга, ураза – нәфесен тыярга, садәка бирергә өйрәтү киң күңелле булырга ярдәм итә. Кешеләргә фарыз гамәлләр – Аллаһ Тәгалә тарафыннан гүзәл, күркәм сыйфатларга ия булсын өчен бүләк итеп бирелгән корал (инструмент). Бүген кешеләр арасындагы әхлакый сыйфатларның түбәнәюе – Аллаһ бүләк итеп биргән коралларны тормышта кулланмау, ягъни фарыз гамәлләрне бөтенләй үтәмәү, яисә үтәүгә җитди карамау нәтиҗәсе. Әгәр без балаларыбызны фарызларны үтәргә гадәтләндермәсәк, аларны бик күп гүзәл сыйфатлардан мәхрүм итәбез.

Хайваннардан аермалы буларак, кешегә җитлегү яшенә җитү өчен 17–18 ел гомер кирәк. Баланы тәрбияләү өчен Аллаһ безгә күпме гомер биргән. Әгәр шуны заяга үткәрсәк, көфран нигъмәткә юл куючылар булырбыз, Аллаһ сакласын.

Авызына тәмәке кабып, кызмача хәлдә өйгә кайтып кергәч кенә тәрбияләргә тотыну тиешле нәтиҗә бирми. Чөнки ул вакытта фәрештә сыйфатлары шайтани сыйфатка алышынган була.

Аллаһ Раббыбыз Коръәндә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالْأَنصَابُ وَالْأَزْلَامُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٩٠﴾

**«Ий, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт кылу, багучылык эшләре хәрамдыр, шайтан эшләреннән булган, пычрак эшләрдер, һәлак булудан котылыр өчен бу эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять котылырсыз – өстенлек табарсыз»,** – диде.

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:90

Бүген телевизордан көн-төн сыра рекламалау, төрле отыш уеннары күрсәтү, астрологларны зурлау барганда, бу эшләрнең никадәр начар икәнен аңлату, күпме кешеләрнең шулар аркасында харап булганнарын төшендерү аеруча мөһим.

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*

*Татарстанның баш казые*

# Фэн

# Хәнәфи мәзһәбенең барлыкка килүе һәм таралуы

Хәнәфи мәзһәбенең барлыкка килүе әле Әбү Хәнифә туганчыга кадәрге чорга ук барып тоташа. Инде Гомәр ﷺ хакимлеге чорыннан ук Куфа шәһәре бик тиз Ислам фәне һәм мәдәниятенең зур үзәгенә әйләнә. Шиксез, монда Габдуллаһ ибн Мәсгуд һәм хәзрәти Гали ﷺ җитәкчелегендә мең ярым сәхабәнең төпләнүе зур әһәмияткә ия була. Бу җирләрдә сәхабәләр кешеләргә Коръән һәм хәдисләр өйрәтә башлый. Алар тапшырган белемнәр, укытучылардан укучыларга тапшырыла-тапшырыла, киләсе буыннарга җиткерелә. Алар исә аны саклап кына калмый, ә иҗтиһад һәм яңа ысуллар белән шактый баета да. Куфа шәһәре һәм аның әйләнә-тирәсендә формалашкан фикһ өлкәсендәге гадәт вә карашлар, тәбигыйннәр чоры факиһы Ибраһим Нәхагидән (һиҗри буенча 96 елда вафат) башлап, «Гыйрак фикһы» дип атала башлый.

Әбү Хәнифә янында тупланган голәмә-мөҗтәһидләр шурасы Коръән һәм хәдисләр турында алдагы буыннар тапшырган бар мәгълүматны, бар фикер һәм аңлатмаларны игътибар белән өйрәнеп, тулысы белән үзләштерә һәм аларга яшәешнең һәр ягына бәйле үсеш вә таралу бирә. Алар бу гыйлемнәргә тулылык вә тирәнлек өсти һәм аерым шәхеснең дә, гомумән җәмгыятьнең дә теләсә нинди сорауларына җавап бирерлек хәлдә була. Әбү Хәнифә Ибраһим Нәхагидән калган мирасны баета һәм системалаштыра. Ул Госман Әл-Батти, Ибн Шубрума, Ибн Әби Ләйлә кебек замандашларын узып киткән мәшһүр шәхес була.

Фикһта күп кенә мәзһәбләрнең, шулай ук башка Ислам гыйлемнәрендә агым һәм мәктәпләрнең аларга нигез салган мөҗтәһид һәм галимнәрнең вафатыннан соң берничә гасыр узгач кына тулысынча формалашып бетүе яхшы билгеле. Аларның формалашуы күренекле галимнәр йогынтысы һәм вакыйгаларның табигый барышы нәтиҗәсендә бара. Хәнәфи

мәзһәбе дә Әбү Хәнифә һәм укучыларының беренче буыны вафатыннан соң гына үз атамасын ала һәм тулысынча мәзһәб буларак формалаша. Шул сәбәпле, Әбү Хәнифәгә һәм аның укучыларына мәзһәб булдыру вә шушы юнәлештә ниндидер гамәлләр кылу ниятен сылтау ярамаганлыгы ачык аңлашыла. Икенче яктан, Һиҗрәтнең 2 нче гасырында Әбү Хәнифә һәм аның укучылары җитәкчелегендә Гыйрак фикһының аерым мәктәп буларак аерылып чыгуына билгеле сәбәпләр булуын инкяр итәргә ярамый. Алдагы дәверләрдә бу мәктәп мөселман халкы, галимнәр һәм руханилар тарафыннан мәзһәб буларак кабул ителә һәм шушы рәвешле бар мөселман дөньясында таралыш таба.

Хәнәфи мәзһәбенең формалашу сәбәпләрен түбәндәге пунктлар буенча анализларга мөмкин.

## 1. Әбү Хәнифә укучыларының эшчәнлеге

Башта имамның гыйльми мәктәбендә укыган һәм аннан соң иҗтиһад буенча шура дип атарга мөмкин булган түгәрәккә кергән Әбү Хәнифәнең укучыларының эшчәнлеге хәнәфи мәзһәбенең формалашуының һәм киң таралыш алуының төп сәбәпләренең берсе була. Имам Әбү Хәнифәнең укучылары бик күп була, һәм алар аның карашларын таратуга, аның фикһы таянган нигезләрне аңлатуга күп көч куя. Остазлары белән кайбер мәсьәләләрдә килешмәсәләр дә, гомумән алганда, алар аның белән бертөрле фикердә була. Укытучыларының фикере белән килешү-килешмәүләренә карамастан, алар беркайчан да ул китергән дәлилләрне җентекләп өйрәнми калмый. Шул ук вакытта, Әбү Хәнифә карашларына нигезләнеп, алар күп кенә икенче дәрәҗәдәге мәсьәләләрне күтәрә, аларны җентекләп тикшерә, бу мәсьәләләр хәл ителә торган кыясларны (охшашлык буенча хөкем итү) ачыклый.

Остазы Хәммәд вафатыннан соң якынча утыз ел дәвамында Әбү Хәнифә дәресләр бирә һәм гыйльми мәҗлесне җитәкли. Шуңа күрә анда

фикһ өйрәнгән һәм аның фәнни моназараларын тыңлаган шәкертләрнең саны берничә меңнән артык булуын тапшырган риваятьләр дөрес кебек тоела. Әбү Хәнифә һәм тарафдарларының беренче буыны (ә бу буынга Әбү Йосыф, имам Мөхәммәд, Зөфәр, Хәсән ибн Зияд кебек мөҗтәһидләр карый) тарафыннан тәрбияләнгән шәкертләр әле яңа гына Ислам динен кабул иткән төрле өлкәләргә тарала. Алар Хәрәзем, Төркестан, Хорасан һәм Мәвәраннәһердә остазларының карашлары билгеле булуына һәм шушы өлкәләрнең халкы тарафыннан уңай кабул ителүенә зур өлеш кертә.

### 2. Кануннар җыентыгын төзү буенча эш

Әбү Хәнифә һәм аның укучылары яшәгән дәвердә үк алар тарафыннан фикһ буенча тупланган материаллар җыентыкларын булдыру эше башлана. Ул башка чорларда да зур көч куеп дәвам иттерелә.

Имам Әбү Хәнифәнең шәкертләренә ияргән һәм шушы мәзһәбне тоткан факиһләр теге яки бу шәригать кануннарының кабул ителүе нигезләнгән сәбәпләрне ачыклауга зур әһәмият биргән. Шулай ук бу нигезләрне киләчәк гасырларда барлыкка килгән яңа мәсьәләләргә карата куллануга да зур әһәмият биргән. Мәзһәб фикһ мәсьәләләре кагыйдәләрен раслаганда таянган нигезләрне ачыклап, алар бар охшаш мәсьәләләрне уртак кагыйдәләр астында берләштерә. Шул рәвешле, уртак кагыйдәләр билгеләп һәм фикһның бар бүлекләренең мәсьәләләрен колачлаган бердәм тәгълимат булдырып, алар мәзһәбне бердәм системага китерә.

### 3. Казыйны (кадый) билгеләү һәм мәзһәбкә рәсми рәвештә иярү

Габбәсиләр нәселеннән Харун Әр-Рашид хәлиф Әбү Йосыфны кадый әл-кудат, ягъни баш казый итеп билгели һәм аңа барлык казыйларны

билгеләү хокукын бирә. Бу бар дәүләт күләмендә хокукый тотрыклылык һәм куркынычсыз имин мөхит тудыру юнәлешендә җитди адым була. Шул ук вакытта бу хәнәфи мәзһәбен тану һәм аның таралышына ярдәм итә. Хәтта һиҗри буенча дүртенче гасырга кадәр Ислам җәмгыятендә фикһ өлкәсендә бүгенге көнгә хас мәзһәб төшенчәсе һәм мәзһәбкә иярү булмаганлыгын игътибарга алганда да, Әбү Йосыфның казый вазифасына Гыйрак фикһына ияргүчеләрне (аның белән Әбү Хәнифә карашлары вә ысуллары арасында берникадәр аермалыклар булса да) билгеләвен тәгаен әйтергә мөмкин. Бу имам Әбү Йосыфның беренче чиратта бердәмлек һәм тотрыклылыкны сакларга омтылуын күрсәтә. Ул һич тә хәнәфи мәзһәбен мәҗбүри рәвештә таратырга яки дини фанатизм булдырырга ниятләмәгән. Бөек шәхес турында мондый сүзләрнең берниндиди нигезе юк, алар фәкать яла һәм дәлилсез гаепләүләр булып тора.

Шул ук вакытта, габбәси хәлифләренең Әбү Йосыфтан башланган баш казыйларны билгеләве, хәнәфи мәзһәбен ныгытуны максат итеп куймаса да, нәтиҗәдә аның таралуын һәм халкы әле генә Ислам кабул иткән яңа яулап алынган өлкәләрдә танылуын шактый җиңеләйтә. Хәнәфи мәзһәбенең үсеше һәм көчәюендә казыйларның ролен аларның үзләре эшләгән җирләрдә үз мәзһәбләрен тарату һәм халыкны хәнәфиләргә әйләндерүендә күрергә кирәкми. Ә аларның Гыйрак фикһының эчтәлеге һәм ысулларын яхшы үзләштереп, мөстәкыйль рәвештә хөкем чыгару һәм иҗтиһад мөмкинлеген алуында. Һәм шул уңайдан алар бу өлкәләрдә хокукый карашларны ныгыта яки булдыра башлыйлар.

Икенче яктан, киләсе чорларда өлкәләргә казыйлар җибәргәндә, бу өлкәнең халкы нинди мәзһәбкә ияргүе истә тотылган, чөнки төрле мәзһәбләрнең карашларын (аеруча гаилә һәм гражданлык хокукы мәсьәләләрен) игътибарга алган күпвариантлы хокукый система иңдерелә. Бу бар да казыйларны билгеләүнең нәтиҗәсе һәрвакытта да ниндидер бер мәзһәбнең көчәюе булмыйча, кайвакыт, киресенчә, мәзһәбнең таралган-

лыгы казыйны билгеләү сәбәбе булуын күрсәтә. Нәкъ шул сәбәпле, дәүләт башлыгының ниндидер мәзһәбкә иярүен бу мәзһәбнең таралуының төп сәбәбе итеп күрсәткәнче, моны билгеле дәрәҗәдә генә кабул итү һәм мондый йогынтының чикле булуын аңлау урынлы булыр иде.

## Хәнәфи мәзһәбенең таралу өлкәләре

Хәнәфи мәзһәбе Габбәсиләр дәүләте җитәкләгән барлык өлкәләрдә таралыш таба. Мәзһәбнең абруе дәүләтнең абруена туры килә торган булган. Дәүләтнең абруе кимегән вакытта мәзһәбнең дә абруе кимегән. Әмма кайсыдыр өлкәләрдә ул бар халык тарафыннан танылса, кайберләрендә бары рәсми мәзһәб кенә була. Ә халык хәнәфи дә, башка мәзһәб тарафдары булырга да мөмкин булган. Гыйракта, Мәвәраннәһердә һәм яулап алынган шәрык өлкәләрендә һәм рәсми, һәм халык тарафыннан танылган мәзһәб хәнәфи мәзһәбе була. Башка Ислам дәүләтләрен карасак, Сүриядә дә хәнәфи мәзһәбенең халык һәм дәүләт мәзһәбе булуын күрербез. Мисыр ягына юнәлсәк, халык арасында мәлики һәм шәфигый мәзһәбләренең өстенлек итүен күрербез, чөнки Мисырда, бер яктан, имам Мәлик укучылары күп булган, ә икенче яктан, имам Шәфигый гомеренең соңгы елларын шушында уздыра һәм монда күмелгән. Шуңа күрә Мисырда һәм беренче мәзһәбкә, һәм икенче мәзһәбкә иярүче мәшһүр галимнәр күп булган.

Соңрак рәсми мәзһәб буларак Мисырга хәнәфи мәзһәбе кертелә, әмма барысы да хәнәфиләр булмый. Фатыймилар дәүләте Мисырны басып алгач, хәнәфи мәзһәбенең рәсми статусы бетерелә һәм шигый имами мәзһәбе урнаштырыла. Фатыймиларны алыштырган Әйүбиләр шәфигый мәзһәбен яклый, һәм бары Нуреддин Әш-Шәһид (Һиҗрәтнең 569 елында вафат) укыту хәнәфи мәзһәбе буенча алып барылган мәдрәсә ача. Һәм бу хәнәфи мәзһәбенең табигый рәвештә саклану һәм таралуына китерә.

Мисырда Мәмлүкләр нәселе хакимлек иткән чорда хөкемнәр дүрт мәзһәб буенча да чыгарылган.

Кавәләли Мәхмәт Гали-паша (1849 елда вафат) Мисыр хакиме булгач, үз карары буенча хәнәфи мәзһәбен рәсми мәзһәб итеп игълан итә.

Хәнәфи мәзһәбе Мисырдан көнбатыш өлкәләргә (Мәгриб) күчә алмый. Әсәд ибн Әл-Фурат ибн Синән (Һиҗрәтнең 213 елында вафат) дәверендә хәнәфи мәзһәбе Мәгрибкә кертелгән булса да, Әгъләбиләр нәселе вәкилләре мәлики мәзһәбендә булганга күрә, ул монда ныгый алмый. Шул сәбәпле Мәгрибтә һәм Андалуста мәлики мәзһәбе бердәнбер мәзһәб булу мөмкинлегенә ия була.

*Камил хәзрәт Сәмигуллинның*
*«Введение в ханафитский фикх»*
*китабыннан тәрҗемә ителде*

*Рәмзилә Шафикова тәрҗемәсе*

# Җәһәннәм мәңгелекме?

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَلْحَمْدُ للهِ الَّذِي هَدَينَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْلَا أَنْ هَدينَا اللهُ لَقَدْ جَاءَتْ رُسُلُ رَبِّنَا بِالْحَقِّ

صَلُّوا عَلَي رَسُولِنَا مُحَمَّدٍ: أَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

صَلُّوا عَلَى شَفِيعِ ذُنُوبِنَا مُحَمَّدٍ: أَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

صَلُّوا عَلَى طَبِيبِ قُلُوبِنَا مُحَمَّدٍ: أَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى سَيِّدِنَا وَنَبِيِّنَا مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ سَيِّدِنَا مُحَمَّدٍ

Соңгы вакытта сөннәт юлын саклаучыларны шиккә кертергә теләп, юлдан тайпылдырырга омтылучылар пәйда булды. «Ак халат» кигән бу «табиблар», үзләрен көчле санап, масайдылар. Алар, Ислам дигән киң мәйданга теләсә нинди туп тибүчене кертеп, мәгънәсез фәтвалар чыгара башладылар һәм, сөннәт юлының бөеклегенә тап төшерү ниятеннән, төрле мәкаләләр яза башладылар. Мәзһәбләргә иярүне тыеп, хәдисләрнең хаклыгында шик белдереп, аларны кире кагарга өнди башладылар. Диннән яздыралар, янәсе!

Күптән түгел, киң җәмәгатьчелекне уйга калдырып, Җәһәннәмнең мәңгелек булуы яисә булмавы хакында фикерләр барлыкка килде. Бу фикер тарафдарлары уенча, Җәһәннәм юкка чыгачак һәм һәммә кеше

Җәннәткә керер көн җитәчәк. Имеш, маньяк һәм аның корбаны да, фиргавен һәм аның корбаннары – барысы да Җәннәтле булачак. Күпләр шиккә төште: барыбер Җәннәткә керәсе булгач, дин нигә кирәк, ни өчен без гөнаһтан тыелабыз? Әмма аек фикер йөртүче һәркемгә бу карашларның сафсата булуы аңлашыла.

Дин эшлеклесе буларак, мин өммәтнең көчен бердәмлектә күрәм һәм фетнә таратуны гөнаһлы гамәл дип саныйм. Шул сәбәпле, әлеге фикерләргә аңлатма бирүне кирәк табам. Иң элек Җәһәннәм һәм Җәннәт бүгенге көндә дә бармы, дигән сорауны ачыклап китик.

Җәннәт – гомерләрен изге гамәл-гыйбадәттә уздырган мөэминнәр өчен әзерләнгән зур бүләк. Җәннәт сигез өлештән тора. Шуларның иң күркәме һәм бөеге – Фирдәвес җәннәте, һәм ул Аллаһы Тәгаләнең Гарше астында урнашкан (Җәүһәрат әт-тәүхид).

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَلِمَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ جَنَّتَانِ ﴿٤٦﴾

**«Раббысы алдына басып хөкем ителүдән курыккан мөэмингә (һәм шул сәбәпле бар төр гыйбадәтләрне кылып, гөнаһ кылудан сакланганга) ике бакча булыр».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:46

Җәһәннәм – динсезләр һәм иман китерүчеләр арасыннан гөнаһлылары кертеләчәк урын. Җиде өлештән торган Җәһәннәм төрле газап һәм җәза урыны. Ышанмаучылар тәмуг утында мәңге янарга дучар ителгән.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

إِنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ وَالْمُشْرِكِينَ فِي نَارِ جَهَنَّمَ خَالِدِينَ فِيهَا ۚ أُولَٰئِكَ هُمْ شَرُّ الْبَرِيَّةِ ﴿٦﴾

**«Китапка ышанып та кәфер булган кешеләр һәм китапка ышанмаучы кәферләр – җәһәннәм утында мәңге калучылардыр. Алар мәхлукатнең иң явызрагыдыр».**

«Бәйинә / Аңлатма», 98:6

Иман китерүчеләр арасында гөнаһлылары, Җәһәннәмдә үз җәзаларын алгач, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән Җәннәткә кертелер һәм башка мөэминнәр белән бергә мәңгегә Җәннәт әһелләре булыр.

Җәннәт һәм Җәһәннәмгә, шулай ук аларның хәзер дә барлыгына ышану Расүлүллаһ ﷺ сөннәтен тоткан мөэмин кешегә мәҗбүри.

Җәһәннәмнең мәңгелегенә килгәндә, бу сорау Җәһәннәм мәңгелек түгел дигән фикердә булган татар руханиебыз Муса Җәруллаһ Бигиевка җавап рәвешендә язылган шәйхүл-ислам Мостафа Сабриның «Исламның яңа мөҗтәһидләре белемнәре» хезмәтендә җентекләп каралган. Аның бу фикеренең дөрес түгеллеген исбат итеп күп мәкаләләр языла, хәтта бөек татар шагыйре Габдулла Тукай, бу фикернең нигезсез булуын ассызыклап, ирония белән түбәндәге шигырен язган:

Зур бәшарәт!
(Рәхмәте илаһия гомуми)
Бәшарәт сезгә, и әһле Петербург!
Шулай ук сезгә дә, әһле Нью-Йорк!
Бәшарәт сезгә дә, и Берлин әһле!
Шулай ук сезгә шатлык, Лондон әһле!
Бәшарәт сезгә дә, карсак японнар!
Бәшарәт сезгә, чиннар һәм финнәр!
Беләмсез, калмыйсыз сез утта мәңге, –
Алыр сезне йолып Муса әфәнде!



Габдуллаһ Бубыйның «Бубый мәдрәсәсенең кыскача тарихы»ннан

Ә бу исә (фотосурәт) мәшһүр рухани, беренче сайланган мөфти, шәех Галимҗан Барудиның Муса Бигиевне динсез дип санавына дәлил. Без шәех Галимҗан Барудиның сүзләрен шәрехләргә алынмыйбыз, фәкать М. Бигиев идеяләре, аерым алганда, Җәһәннәмнең мәңгелек булмавы турындагы фикере, руханилар тарафыннан хупланмаган һәм аңа карата шундый сүзләр әйтелүенең сәбәпчесе булуына фактлар китерәбез.

Бу сорау кысаларында шулай ук Такыюддин Гали бин Габделкәфи Әс-Субкинең «Әл-игътибар би бәкаил-җәннәти вән-нәр» хезмәтен һәм Мөхәммәд бин Исмәгыйль Әс-Санәтинең күбрәк «Әл-Әмир» дип билгеле «Рафгул-әстар ли ибтали әдилләтил-каилинә би фәнаин-нәр» әсәрен билгеләп үтәргә кирәк. Бу хезмәтләр – Ибн Тәймия һәм Ибн Кайимнең Җәһәннәм газапларының мәңгелек түгел дигән фикерләренең ялгыш булуына ачык мисал һәм Җәһәннәмнең мәңгелек булуына дәлил булып тора.

Ибн Кайимнең карашлары аның хезмәтендә чагылыш тапса да, Ислам галимнәре тарафыннан бу фикерләрне кире кага торган нигезле хезмәтләр язылуын онытмаска кирәк. Шуңа күрә, Җәһәннәмнең мәңгелегендә шикләнә алган кешеләр, Ибн Кайим һәм Муса Бигиевнең әлеге мәсьәләгә караган хезмәтләрен өйрәнгәндәге тырышлыкларын куеп, вакытларын шул нигезле хезмәтләрне өйрәнүгә багышласалар, күпкә яхшырак булыр иде.

Теманы яхшырак үзләштерү һәм хакыйкатьне ачыклау өчен, Ибн Кайим ялгышкан төп аспектларны карап китәрбез, һәм дөрес дип саналган карашларның асылын аңлатырбыз.

Руханиларның берсе дә җәһмиләр сектасына нигез салган Әл-Җәһем бин Сафван фикерен хуплап чыкмый. Ул Җәннәт һәм Җәһәннәм кайчан да булса юкка чыгачак, дип уйлаган. Әмма бар мөселман галәмәләре, хәтта Ибн Кайим белән Әл-Җәһем бин Сафван да, Җәһәннәм булганда, кәферләрнең шунда булачагында килеште.

Хәзер безнең соравыбызга караган һәм түбәндәгечә бүленгән төп мәсьәләләргә тукталып китик:

а) сөннәт әһелләре һәм күпчелек башка мәзһәб мөселманнары фикеренчә, Җәннәт белән Җәһәннәм, анда эләгүчеләр кебек үк, мәңгелек. Тузан бөртеге кадәр булса да иманы булган һәм гөнаһлары өчен Җәһәннәмгә эләккән кеше, алардан чистарынгач, Тәмугтан Җәннәткә күчереләчәк. Имансызлар исә мәңгелеккә Җәһәннәмдә калачак.

б) Ибн Кайим фикеренчә, Җәһәннәм яшәгән кадәр, имансызлар анда булачак. Әмма көннәрдән бер көнне Җәһәннәм юкка чыгачак, һәм анда булган бар кәферләр дә Җәннәткә кертеләчәк. Аның фикеренчә, Җәһәннәм генә юкка чыгачак, ә Җәннәт мәңге булачак.

Ә хәзер һәр якның да аятьләр һәм Пәйгамбәрнең ﷺ хәдисләре белән ныгытылган дәлилләрен карап китик.

Җәһәннәмнең мәңгелек булуына дәлил буларак, сөннәт әһелләре түбәндәге дәлилләр китерә.

Ибн Кайим фикеренчә, берзаман Җәһәннәм юкка чыгачак, ә бу имансыз кешеләрнең тиешенчә алган җәзалары туктатылачак, дигән сүз. Әмма бу Аллаһы Тәгалә имансызларның Җәһәннәмдә мәңге булачагын ачык рәвештә әйткән Изге Коръән аятьләренә каршы килә.

إِنَّ الْمُجْرِمِينَ فِي عَذَابِ جَهَنَّمَ خَالِدُونَ ﴿٧٤﴾ لَا يُفَتَّرُ عَنْهُمْ وَهُمْ فِيهِ مُبْلِسُونَ ﴿٧٥﴾

**«Дөреслектә, Коръән белән гамәл кылмаучылар Җәһәннәм газабында мәңге калырлар. Алардан газаб аз гына да җиңеләйтелмәс вә алар котылудан өметләрен өзеп тик торырлар».**

«Зүхърүф / Зиннәтләнү», 43:74-75

إِنَّ اللَّهَ لَعَنَ الْكَافِرِينَ وَأَعَدَّ لَهُمْ سَعِيرًا ﴿٦٤﴾ خَالِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ۖ لَّا يَجِدُونَ وَلِيًّا وَلَا نَصِيرًا ﴿٦٥﴾

**«Аллаһ Коръән белән гамәл кылмаучы имансызларны Үзенең рәхмәтеннән ерак кылды, вә аларга ут газабын хәзерләде. Утта мәңге калырлар вә үзләрен яклаучы дусны һәм уттан коткаручы ярдәмчене тапмаслар».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:64-65

وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَإِنَّ لَهُ نَارَ جَهَنَّمَ خَالِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ﴿٢٣﴾

**«Берәү Аллаһка вә Аның расүленә гасый булса, ул кешегә Җәһәннәм уты әзерләнгән, һәм алар анда мәңге калучылардыр».**

«Җиннун / Җен», 72:23

يُرِيدُونَ أَن يَخْرُجُوا مِنَ النَّارِ وَمَا هُم بِخَارِجِينَ مِنْهَا ۖ وَلَهُمْ عَذَابٌ مُّقِيمٌ ﴿٣٧﴾

**«Кәферләр уттан чыгуны теләрләр, әмма аннан чыга алмаслар. Аларга мәңгелек газаплар әзерләнгән».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:37

وَالَّذِينَ كَفَرُوا لَهُمْ نَارُ جَهَنَّمَ لَا يُقْضَىٰ عَلَيْهِمْ فَيَمُوتُوا وَلَا يُخَفَّفُ عَنْهُم مِّنْ عَذَابِهَا ۚ كَذَٰلِكَ نَجْزِي كُلَّ كَفُورٍ ﴿٣٦﴾

**«Коръән юлыннан бармыйча кәфер булган кешеләргә Җәһәннәм газабы әзерләнгән. Аларга анда үлем белән хөкем булмас, үлсәләр газаптан котылыр иделәр. Вә алардан Җәһәннәм газабы аз гына да җиңеләйтелмәс».**

«Мәләикә / Фәрештәләр», 35:36

وَأَمَّا الَّذِينَ فَسَقُوا فَمَأْوَاهُمُ النَّارُ ۖ كُلَّمَا أَرَادُوا أَن يَخْرُجُوا مِنْهَا أُعِيدُوا فِيهَا وَقِيلَ لَهُمْ ذُوقُوا عَذَابَ النَّارِ الَّذِي كُنتُم بِهِ تُكَذِّبُونَ ﴿٢٠﴾

**«Әмма имансыз фасикъларның торачак урыннары уттыр. Алар аннан чыгарга теләгән саен, аларны кире кайтарырлар вә аларга: «Үзегез ялганга тоткан ут газабын татыгыз», – дип әйтелер».**

«Сәҗдә», 32:20

Алда китерелгән аятьләрдән күренгәнчә, Аллаһы Тәгалә безгә имансызлар өчен әзерләнгән Җәһәннәм газаплары мәңге булачагын хәбәр итә.

Тагы берничә мисал китерик:

بَلَىٰ مَن كَسَبَ سَيِّئَةً وَأَحَاطَتْ بِهِ خَطِيئَتُهُ فَأُولَٰئِكَ أَصْحَابُ النَّارِ ۖ هُمْ
فِيهَا خَالِدُونَ ﴿٨١﴾

**«Бер кеше фәхеш вә хәрам эшләрне кәсеп итсә һәм ул кешене гөнаһлары чорнап алса, ул кешеләр, әлбәттә, ут әһелләре. Алар анда мәңге калырлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:81

إِنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا وَظَلَمُوا لَمْ يَكُنِ اللَّهُ لِيَغْفِرَ لَهُمْ وَلَا لِيَهْدِيَهُمْ طَرِيقًا
﴿١٦٨﴾ إِلَّا طَرِيقَ جَهَنَّمَ خَالِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ۚ وَكَانَ ذَٰلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرًا
﴿١٦٩﴾

**«Кәфер һәм залим булган кешеләрне Аллаһ ярлыкамаячак һәм туры юлга күндермәячәк. Мәгәр аларны Җәһәннәм юлына күндерер, алар анда мәңге калырлар. Бу эш Аллаһка бик җиңел».**

«Нисә / Хатыннар», 4:168-169

إِنَّكُمْ وَمَا تَعْبُدُونَ مِن دُونِ اللَّهِ حَصَبُ جَهَنَّمَ أَنتُمْ لَهَا وَارِدُونَ ﴿٩٨﴾ لَوْ
كَانَ هَٰؤُلَاءِ آلِهَةً مَّا وَرَدُوهَا ۖ وَكُلٌّ فِيهَا خَالِدُونَ ﴿٩٩﴾

**«Аллаһ әйтер: «Ий мөшрикләр, сез вә сез табынган әйберләр, әлбәттә, Җәһәннәм утыннарысыз, ул Җәһәннәмгә сез дә керерсез. Әгәр сезнең гыйбадәт сынымнарыгыз чыннан да Аллаһ булсалар, Җәһәннәмгә кермәс иделәр. Мөшрикләр вә сынымнар һәммәсе Җәһәннәмдә мәңге калырлар».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:98-99

Шулай ук бу турыда, Җәһәннәмнең мәңгелек булуын дәлилләп, күп тапкырлар Пәйгамбәрнең ﷺ хәдисләрендә дә әйтелә.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ، عَنِ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «مَنْ تَرَدَّى مِنْ جَبَلٍ فَقَتَلَ نَفْسَهُ، فَهُوَ فِي نَارِ جَهَنَّمَ يَتَرَدَّى فِيهِ خَالِدًا مُخَلَّدًا فِيهَا أَبَدًا، وَمَنْ تَحَسَّى سُمًّا فَقَتَلَ نَفْسَهُ، فَسُمُّهُ فِي يَدِهِ يَتَحَسَّاهُ فِي نَارِ جَهَنَّمَ خَالِدًا مُخَلَّدًا فِيهَا أَبَدًا، وَمَنْ قَتَلَ نَفْسَهُ بِحَدِيدَةٍ، فَحَدِيدَتُهُ فِي يَدِهِ يَجَأُ بِهَا فِي بَطْنِهِ فِي نَارِ جَهَنَّمَ خَالِدًا مُخَلَّدًا فِيهَا أَبَدًا»

Әбү Һөрәйра رضي الله عنه Расүлүллаһның ﷺ болай дип әйтүен тапшыра:

«Таудан ташланып, үз-үзен һәлак итүче мәңгелеккә Җәһәннәм утына ыргытылыр. Агу эчеп үз-үзен үтергән кеше мәңге Тәмуг утында булыр, анда эчеп торыр. Үз-үзен тимер кисәге белән юк иткән кеше мәңге Җәһәннәм утында булыр, кулында карынына кадалган тимерне тотып торыр».[1]

عَنْ أَبِي سَعِيدٍ، قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: « يُجَاءُ بِالْمَوْتِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ، كَأَنَّهُ كَبْشٌ أَمْلَحُ - فَيُوقَفُ بَيْنَ الْجَنَّةِ وَالنَّارِ، فَيُقَالُ: يَا أَهْلَ الْجَنَّةِ هَلْ تَعْرِفُونَ هَذَا؟ فَيَشْرَئِبُّونَ وَيَنْظُرُونَ وَيَقُولُونَ: نَعَمْ، هَذَا

[1] Бохари, Тыбб: 55, 5442, 5/2179; Мөслим, Иман: 47, №109, 1/103-104

الْمَوْتُ، قَالَ: وَيُقَالُ: يَا أَهْلَ النَّارِ هَلْ تَعْرِفُونَ هَذَا؟ قَالَ فَيَشْرَئِبُّونَ وَيَنْظُرُونَ وَيَقُولُونَ: نَعَمْ، هَذَا الْمَوْتُ، قَالَ فَيُؤْمَرُ بِهِ فَيُذْبَحُ، قَالَ: ثُمَّ يُقَالُ: يَا أَهْلَ الْجَنَّةِ خُلُودٌ فَلَا مَوْتَ، وَيَا أَهْلَ النَّارِ خُلُودٌ فَلَا مَوْتَ»

Әбү Сәгыйд Әл-Худри ﵁ Пәйгамбәрнең ﷺ түбәндәге сүзләрен риваять итә:

«Кыямәт көнендә (Җәннәт һәм Җәһәннәм әһелләре торачак җирләренә җибәрелгәч) ала-кола бәрән кыяфәтендә үлем китереләчәк. Сөрән салучы:

– Ий Җәннәт әһелләре, сез моның кем икәнен беләсезме? – дип сорар.

Җәннәт әһелләре башларын күтәреп бәрәнне күрер, аннан соң җавап бирер:

– Әйе, беләбез, бу – үлем.

Аннан соң сөрән салучы Җәһәннәмдәгеләргә мөрәҗәгать итеп:

– Ий Җәһәннәм әһелләре, сез моның кем икәнен беләсезме? – дип сорар.

Җәһәннәм әһелләре башларын күтәреп бәрәнне күрер, аннан соң җавап бирер:

– Әйе, беләбез, бу – үлем.

Шуннан соң бәрән Җәннәт белән Җәһәннәм арасында чалыныр, ә сөрәнче (Җәннәт әһелләренә) әйтер:

– Ий Җәннәт әһелләре, хәзер сез монда мәңгегә калырсыз, чөнки үлем башка юк.

Аннан соң (Җәһәннәм әһелләренә) әйтер:

– Ий Җәһәннәм әһелләре, хәзер сез монда мәңгегә калырсыз, чөнки үлем башка юк».[1]

[1] Мөслим, Китәбүл-җәннә: 13, №2849, 4/2188; Бохари, Тәфсир: 221, №4453, 4/1760; Тирмизи, Китәбүт-тәфсирүл-Коръән, № 3156 хәдис

Мөгаз бин Җәбәл ﷺ: «Аллаһ расүле ﷺ мине Йәмәнгә җибәрә. Һәм мин анда килгәч, халыкка болай ди: «Ий кешеләр! Минем сезгә Аллаһ Илчесе итеп җибәрелүем шиксез. Без барыбыз да Аллаһка кайтарылачакбыз, һәм бу кайту – йә Җәннәткә кайту, йә Җәһәннәмгә. Кайтарылгач, без анда мәңгегә калачабыз һәм мәңге яшәячәкбез», – дигән хәдис тапшыра.[1]

Шулай ук йөрәгендә кечкенә генә бөртек иман булган кешеләр Җәһәннәмнән чыгарылачак, ә имансызлар анда мәңгегә калачагын риваять итә торган күпсанлы билгеле хәдисләр бар. Моннан кала, гөнаһлы мөселманнарга шәфәгать кылынып, алар Җәһәннәмнән чыгарылып, Җәннәткә кертеләчәген хәбәр иткән хәдисләр дә аз түгел.

Гөнаһлы мөселманнар кебек үк, имансызларның да кайчан да булса Җәһәннәмнән чыгарылачагын күз алдына китерик. Әмма бу очракта Пәйгамбәрнең ﷺ гөнаһлы мөселманнарга шәфәгать кылуы турындагы хәдисләр мәгънәсен югалтачак. Ягъни, имансызлар гөнаһлы мөселманнарга тиң булачак, һәм гөнаһлы мөселманнарга карата гына хәбәр ителгән Пәйгамбәрнең ﷺ шәфәгате бар мәгънәсен югалтачак. Ә бу инде хакыйкатькә каршы килә.

Белгәнебезчә, сәхабәләр дә, табигыйннәр дә Җәһәннәмнең мәңгелек булуы мәсьәләсендә бердәм фикердә булганнар. Ибн Хазм үзенең «Мәратибүл-иҗмаг» хезмәтендә, моны ассызыклап, болай дигән: «Алар Җәһәннәмнең барлыгы һәм моңа лаек булганнар өчен газап урыны булуында бер фикердә булганнар. Ә аның әһелләре, Җәһәннәмнең үзе кебек үк, анда мәңге булырлар»[2]. Хәтта Ибн Тәймия тәнкыйть максатыннан җавап итеп язган «Нәкдүл мәратибүл-иҗмаг» әсәрендә моңа каршы килми.

Бу фикернең хак булуына тагын бер дәлил – Ибн Хазмның иҗмаг сорауларына мөнәсәбәте турында Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсәри әйткән

1 Суюты, Әл-җәмг әс-сәгыйр, №852

2 Ибн Хазм, «Мәратибүл-иҗмаг», 268 бит

сүзләр: «Ибн Хазм кебекләр (алар бу сорауда бик нәзәкатьле булганнар) тарафыннан теләсә кайсы иҗмаг кабул ителми иде, әмма кабул ителгән иҗмаглар иң яхшылары иде»[1].

Әһлес-сөннәт фикеренчә, Җәһәннәм дә, Җәннәт тә, аларда булачак кешеләр кебек үк, мәңгелек, һәм Тәмуг утында мәңге янарга дучар булганнарга җәзаларында җиңеллек булмаячак. Әһлес-сөннәт голәмәләре арасында бу сорауда беркайчан да фикер каршылыгы тумады.

Алга таба Ибн Кайим фикере карап кителәчәк.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*
*Татарстан Республикасы мөселманнарының*
*Диния нәзарәте рәисе, мөфти*

1 Мөхәммәд Заһид Әл-Кәүсәри, Мәкаләт; «Мәсьәләтүл-хулүд» 328

# Коръән турында гыйлем

*(Дәвамы. Башы журналның 13, 15, 16 нчы саннарында)*

## Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар

Коръән фәннәре арасында вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартларны өйрәнә торган фән – иң затлы фәннәрнең берсе булып санала. Гомумән алганда, бу фәнгә күбрәк тәфсирчеләр игътибар бирә, ә сирәк очрый торган юнәлештәге эзләнүләр өлкәсендә – Коръәннең серле якларын өйрәнүчеләр.

Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар ул – аятьләр иңүенә сәбәпче буларак, Пәйгамбәребезнең ﷺ һәм аның заманында яшәгән кешеләрнең билгеле бер көнендә (көннәрендә) булган тормыш-көнкүреш хәлләре (шартлары, вакыйгалар, вәзгыятьләр, очраклар, халәтләр).

Ошбу билгеләмәнең мәгънәсен чагылдыра торган төп күрсәткеч булып «билгеле бер көнендә (көннәрендә)» дигән сүзләр тора[1].

Аятьләрне болай итеп бүлеп карау галимнәрне Әл-Вәхидинең «Фил» сүрәсенә ясаган тәфсирен тәнкыйтьләүгә китерде. Әл-Вәхиди үзенең тәфсирендә «Фил» сүрәсе Мәккәгә эфиоп гаскәре һөҗүм ясавы сәбәпле иңде, ди. Әмма бу тарихи вакыйга ул сүрәнең иңүенә берничек тә сәбәп булмады. Сүрәнең иңүе Пәйгамбәр ﷺ заманында яшәгән мөселманнарның көнкүреше вә тормыш хәлләре белән берничек тә бәйле түгел – бу вакыйга аларга кагылышы булмаган борынгы чорда булган хәл бит. Шуңа күрә «Фил» сүрәсе икенче аятьләр төркеменә керә. Шулай ук бу аятьләр төркеменә Нух, Гад, Сәмүд турында хәбәр биргән риваятьләр дә, Кәгъбә

1 Тәрҗемәчедән: Бу билгеләмә күрсәткече аятьләрне ике төркемгә бүлеп карарга ярдәм итә: 1) Пәйгамбәребез ﷺ һәм аның вакытында яшәгән кешеләр белән билгеле бер көндә (көннәрдә) нindидер хәл булу сәбәпле иңгән аятьләр; 2) Пәйгамбәребез ﷺ вакытындагы шартлар белән берничек тә бәйле булмаган, ягъни, төрле вакытларга, вакыйгаларга һәм бөтенләй башка нәрсәләргә кагылышлы булып, сәбәпсез иңгән аятьләр.

төзелеше турындагы кыйсса да һәм бик күп төрле башка тарихи кыйссалар да керә.

Шуңа да игътибар итәргә кирәк – Коръән тулаем алганда һаман Пәйгамбәрнең ﷺ һәм аның сәхабәләренең көнкүреше вә тормыштагы вакыйгалары белән генә бәйле булып иңмәгән. Аның кайбер өлешләре мөселманнар тормышына бөтенләй кагылышлы булмаган рәвештә иңгәннәр, шул исәптән, ошбу хәбәрләр һәм мәгълүматлар: әүвәлге пәйгамбәрләрнең язмышлары һәм аларның үз халыклары белән мөнәсәбәтләре турында; тарихи вакыйгалар турында; Кыямәт көне, Җәннәт һәм Җәһәннәм турында – болар барысы да Пәйгамбәр ﷺ заманына кагылышсыз буларак иңгәннәр[1].

## Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турында белүнең файдасы

Билгеле ки, беренчел чыганак текстлар һәм документлар белән эшләүдә тәҗрибәсе булган гыйлем ияләре вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турында гыйлемле булуга зур әһәмият бирәләр.

Бу мәсьәләгә төрле яктан карап, без шундый нәтиҗәләргә киләбез:

1. Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартларны өйрәнә торган фән Коръән аятьләренең мәгънәләрен аңларга ярдәм итә, чөнки «сәбәп» белән «нәтиҗә» тыгыз бәйләнештә торалар. Әл-Вәхиди әйткән: «Аятьнең тари-

[1] Ә инде Ибне Габбасның «Аллаһ белән ант итәм – мин Аллаһның Китабындагы аятьләрнең ни сәбәпле иңүләрен беләм…» дигән сүзләренә килсәк (мондый сүзләрнең Гали رضي الله عنه тарафыннан да әйтелүе турында билгеле) – бу сүзләр берничек тә «Коръәндәге һәрбер аятьнең иңүе Пәйгамбәр ﷺ вакытына караган сәбәпчел шартлар белән бәйле» дигәнне аңлатмыйлар. Аның сүзләре фәкать Пәйгамбәр ﷺ вакытында теге яки бу сәбәп белән иңгән аятьләргә генә кагыла, ягъни ул фәкать шул аятьләрнең иңү сәбәпләрен генә белгән. «Ибне Мәсгуд бу сүзләре белән үзенең аятьләр иңүе турындагы белемен яисә хәбәр тапшыручылар турындагы белемен арттырып күрсәтә», – дип әйтүчеләр бик нык ялгышалар. Монда бик тә игътибарлы булырга кирәк.

хын (аның иңү сәбәпләрен, шартларын) белми торып, аны тәфсир кылып булмый».

Ибне Дәкыйк Әл-Гыйд: «Вәхиләрнең иңү шартларын белү – Коръәннең мәгънәләрен аңлауда иң ышанычлы юл», – дип әйткән.

2. Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турындагы белемнәр канунлаштырган кагыйдәләрнең хикмәтле нигезләрен аңларга, шул кагыйдәләрнең үзләрен дә яхшырак аңларга һәм кабул итәргә дә ярдәм итәләр. Исерткеч эчемлекләр эчүне тыйган аятьләрнең иңү шартлары белән таныш булган һәркем бу тыюның әһәмиятен дә ныграк аңлый.

3. Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турындагы белемнәр тәфсирчеләргә катлаулы текстларның мәгънәләрен аңларга да ярдәм итәләр. Бу бигрәк тә аять-сүрәләрнең иңү шартлары белән таныш булмаган тәфсирчеләргә кагыла.

Мисал итеп, Мәрвән ибне Әл-Хәкәм белән булган билгеле бер вакыйганы китерергә була – ул Аллаһы Тәгаләнең «Үзләренең кылган гамәлләре белән канәгать булып шатланучылар һәм эшләмәгән эшләре өчен мактарыга яратучылар Аллаһ газабыннан котылырлар дип һич тә уйлама! Аларга рәнҗетүче газаб әзерләнмеш» («Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:188) дигән сүзләре хакында аптырашта калып, Ибне Габбаска мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган. Ул сораган: «Чынлыкта, әгәр дә үзенең кылган һәр гамәленә шатланучы һәм үзе эшләмәгән һәр эше өчен мактау көтүче газаплы җәзага тартылса – димәк, без барыбыз да газаплы җәзага тартылачакбыз икән бит!?» Аның соравына Ибне Габбас болай дип җавап бирде: «Ә сезнең моңа нинди кагылышыгыз бар? Мәсьәлә шунда ки – Пәйгамбәребез ﷺ яһүдләрне үзе янына чакырып, алардан нәрсәдер хакында сораган булган, ләкин яһүдләр, аңа бу хакта кирәкле дөрес җавапны бирмичә, гел икенче нәрсә хакында хәбәр биргәннәр һәм

шул җавап биргәннәре өчен мактау көткәннәр, ә үзләренең яшертен башкарган эшләренә шатланганнар»[1].

3. Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турындагы белем Коръән теле матурлыгының серләрен һәм гармоник стилен дә ачарга ярдәм итә, шул исәптән укучыларга да (аларның мөмкинчелекләренә һәм үсеш дәрәҗәләренә карап). Мондый тәфсирләргә багышланган хезмәтләр дә аз түгел[2].

## Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турында ничек белеп була?

Вәхи иңүенең сәбәбе булган очракта (аять сәбәпле рәвештә иңгән булса) – аятьнең мондый рәвештә иңүе турында үзлектән чыгып бернинди дә фикер йөртүләр һәм нәтиҗә ясаулар була алмый, болай итү тыела. Бу мәсьәлә буенча Әл-Вәхиди үзенең «Вәхиләр иңүенең сәбәпләре» китабының кереш өлешендә болай дигән: «Вәхи иңүенә шаһит булучыларның һәм вәхи иңүенең сәбәпләрен иҗтиһад кылып эзләнүчеләрнең һәм белүчеләрнең хәбәрләренә таянмыйча, Коръән аятьләренең иңүе турында үзлектән карарлар (нәтиҗәләр) чыгару тыела».

Моннан соң безгә сәләфләрнең вәхиләр иңүенең сәбәпләре мәсьәләсенә карата булган таләпчәнлекләре дә ныграк аңлашыла. Имам Мөхәммәд ибне Сирин сөйләгән: «Мин Габидәт Әс-Сәлманидан Коръәндәге бер аять турында сораган идем, ул миңа: «Коръәндәге аятьләрнең ни сәбәпле иңгәнннәрен белгән кешеләр хәзер юк инде. Шуңа күрә дә ул: «Аллаһтан курык һәм дөресен сөйлә», – диде»[3].

[1] Бохариның «Коръән тәфсире китабы»нда (6/40-41). Мөслимнең дә монафикъларга багышланган бүлегендә шундый ук текст (8/122).

[2] Бу мәсьәләне җентекләп өйрәнер өчен «Коръән һәм әдәби эзләнүләр» дигән китапка мөрәҗәгать ит (85 нче биттә).

[3] Әш-Шәтыйбиның «Әл-Мовафәкате» (3/422-423) һәм «Әл-Иткан» (1/31).

Вәхи иңүе турындагы белем үзлектән чыгып фикерләүгә һәм нәтиҗә ясауга нигезләнмәгәнгә күрә, мөхәддисләр сәбәпле булып иңгән вәхи турында хәбәр бирүче сәхабәнең яисә табигыйнның сүзләрен хәтта «мәрфүгъ-хәдис»[1] дәрәҗәсендә кабул итәләр иде һәм ул хәбәр бирүче сәхабәне вә табигыйнны я шул вәхи иңүенең шаһиты дип, я шул заманның кешесе дип саныйлар иде, мәгәр бу хәбәр сәхабәнең яки табигыйнның фәкать үз сүзе генә булса да[2]. Мисал итеп, югарыда искә алган Ибне Габбасның Мәрванга биргән шул ук җавабын китерергә була – Мәрванның Ибне Габбастан җиткергән бу сүзләре галимнәрнең бердәм карары нигезендә «мәрфүгъ-хәдис» булып санала. Бохари, Мөслим кебек танылган хәдис белгечләренең җыентыкларында мондый хәбәрләр аз түгел.

Ә инде табигыйннар тарафыннан сәбәпле булып иңгән вәхиләр турындагы җиткерелгән хәбәрләргә килсәк – алар да шулай ук «мәрфүгъ-хәдис» дәрәҗәсендә саналалар, ләкин аларның хәбәр бирү чылбырында сәхабә булмау сәбәпле, «мөрсәл» дигән өстәмә сүз белән төгәллек кертелә.

Тик монда шуны гына исәптә тотарга кирәк – сәбәпле булып иңгән аятьләрне башка төрле аятьләр белән бутарга ярамый. Кайбер вакытта кайберәүләрдән, бер нигезсез, «Бу аять шул сәбәпле иңде» (яисә «Бу шул кешегә кагылышлы/ул кешенең менә шушы нәрсәне эшләгәндә») дигән сүзләр дә ишетергә була. Ә дөреслектә исә, аларның бу аять турындагы сүзләрендә фәкать аятьнең тематикасы (яисә аның берәр төрле нормага кагылышы булуы) гына күздә тотылган булып чыга.

Мәсәлән, Хөзәйфәнең Аллаһы Тәгаләнең «Аллаһ ризалыгы өчен Ул күрсәткән урыннарга малларыгыздан сәдака бирегез! Һәм үзегезне һәлакәткә дучар итмәгез» (2:195) дигән аятен: «Бу аять сәдака бирү

---

1 «Мәрфүгъ-хәдис» – сәхабәнең (яисә табигыйнның) Пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисенә тәңгәл килгән хәбәре.

2 Бу мәсьәләне Әл-Хәкимнең «Мәгърифәтү голүмил-хәдис» (20 нче биттә) һәм «Мәнһаҗ ән-нәкъди фи голүмил-хәдис» (328-329 нчы битләрдә) хезмәтләреннән җентекләп карарга була.

мәсьәләсенә кагылышлы булып иңгән» дип тәфсирләве, дөреслектә, ошбу аятьнең фәкать «Сәдака бирү» мәсьәләсенә кагылышлы булуын гына күрсәтә (Бохари җиткергән хәдистә)[1].

Имам Әз-Зәркәши әйткән[2]: «Билгеле булганча, сәхабәләр һәм табигыйннарның гадәти гамәлләреннән шул иде – әгәр дә аларның берәрсе «Бу аять менә шуның турында иде», – дип әйтсә, аның бу сүзләре аятьнең иңү сәбәбе турында түгел, ә аның нинди дә булса бер нормага (кагыйдәгә) кагылышлы булуы турында мәгълүмат бирүне аңлаткан... моны «аять иңүе турында мәгълүмат бирү» дип түгел, ә «норманы аять белән раслау (дәлилләү)» дип атарга була».

## Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турында каршылыклы хәбәрләр

Вәхиләр иңүенә сәбәп булган шартлар турындагы гыйлемнәрнең бердәнбер чыганагы – фәкать хәдисләр генә икән, димәк, безнең ошбу эшебез «Хәдисләр терминологиясе» дигән фәнни өлкә белән дә бәйле булып чыга. Ә ул өлкәдә исә, билгеле булганча, хәдисләр төрледән-төрле булалар: «сахыйх»ләр (дөреслеккә туры килгәннәр), «зәгыйфь»ләр (дөреслеккә туры килмәгәннәр), «тоташ»лар, «бүленгән»нәр һәм башкалар.

Бу мәсьәләне карауны бик артыкка сузмыйча, эзләнүчеләрне бер нәрсәгә генә игътибар иттерәсе килә – сәбәпле рәвештә иңгән аятьләр хакында килгән хәдисләр арасында төрле каршылыклар да булырга мөмкин һәм андый каршылыклы хәдисләрне бик күп очратырга да туры килә.

Бу хәлнең иң төп сәбәпләрен түбәндә китерәбез.

1. Хәбәр тапшыручыларның «зәгыйфьлеге».

«Зәгыйфь» хәбәр тапшыручы хаталы була яки аның сөйләве башка хәбәрләргә туры килми һәм, шул сәбәпле, аның хәбәре кире кагыла.

---

1 Бохари (6/57)

2 «Әл-Борһан» (1/31-32) – кыскача бирелде.

Мисал итеп, **«Кояш чыга торган һәм кояш бата торган тараф та, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләнекедер. Кайсы якка гына юнәлсәгез дә, Аллаһның Йөзен табарсыз. Чынлыкта, Аллаһ бар нәрсәне дә Үзенә колачлап алучы һәм Белүче»** («Әл-Бәкара / Сыер», 2:115) дигән аять турындагы хәдисне алыйк.

Бу аять хайванга атланып барган мосафирның нәфел намазлары укуы турында иңгән икәнлеген барыбыз да яхшы беләбез.

Мөхәддис Мөслим ибне Гомәрнең ошбу сүзләрен китерә: «Пәйгамбәребез ﷺ хайванга атланып Мәккәдән Мәдинәгә барган вакытта, йөзен шул барган юнәлешкә юнәлтеп, намазын укыган. Ул ﷺ: **«Кайсы якка гына юнәлсәгез дә, Аллаһның Йөзен табарсыз»,** – дигән сүзләр (аять) менә шуның турында иңде», – диде» [1].

Әт-Тирмизи дә шул ук аятьнең иңүе белән бәйле булган башка бер хәдис китерә[2]. Ул китергән хәдистә бу аять намаз укырга җыенган, әмма дә ләкин кыйбла ягын билгели алмаган кешегә карата иңгән диелә. Билгеле ки, мондый очракта ул кешенең намазының кабул булуы фәкать аның кыйбла ягын эзләүдә тырышуыннан гына торачак, хәтта ул бу тырышу нәтиҗәсендә ялгышса да. Хәдиснең үзен Әт-Тирмизи «зәгыйфь» дип бәяли.

Без исә бу аятьнең иңү сәбәбе турында, аның сахыйхлыгы турында шик булмау сәбәпле, беренче чыганакка – Мөслимнән килгән хәдискә таянабыз.

2. Бер үк вәхинең иңү сәбәпләре һәм шартлары төрлечә булуында, ягъни бер үк аятьнең төрле шартларга кагылышы булган очракта.

Мондый күренешне болай аңларга була – бер үк вакытта «параллель» рәвештә төрле тормыш хәлләре (вакыйгалар, вәзгыятьләр) килеп чыккалый һәм нәкъ шул хәлләрнең барысына да кагылышлы булып аять тә иңә.

[1] Мөслим (2/149), Бохари (2/44 һәм 45). Әс-Суйутыда җитешсезлек бар – хәдиснең Мөслимнән булуын әйтмәгән.

[2] Әт-Тирмизи (1/176), Ибне Маҗә (1/326) һәм Әд-Дәрәкутни (Һиндстан нәшрияты, 101 нче биттә).

Коръәндә мондый очракларның булганы күрсәтелә. Билгеле ки, мондый «параллель очракларны» ачыкларга фәкать сахыйх хәдисләр генә ярдәм итә алалар. Әгәр дә инде бу очракларны чагылдырган хәдисләрнең барысы да сахыйх булсалар, һәм, шул ук вакытта, алар бер-берсе белән әллә ни артык каршылыкка да килмәсәләр – болай булганда бу «параллель очраклар» барысы да ошбу аятьнең иңүенә сәбәп булган шартлар булып таныйлалар.

Моңа мисал итеп, лиганга кагылышлы, ягъни ир белән хатынның бер-берсенә ләгънәт әйтешүләренә кагылышлы аять хакындагы хәдисне китерергә була. Бохариның әйтүе буенча, бу аять Һиләл ибне Үмәйянең гамәлләре сәбәпле иңгән – ул Пәйгамбәребез ﷺ янында хатынын зина кылуда гаепли, һәм шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән **«Үз хатыннарын «зиначы» дип гаепләп сүгүче ирләр...»** («Нур», 24:6) дигән сүзләр иңә.

Ә «ике сахыйх җыентык»та исә бу аятьнең иңүе Говәймир ибне Гаҗлән исемле кешенең үз хатынын зиначылыкта гаепләве һәм аның бу мәсьәләдә Пәйгамбәребезгә ﷺ сорау белән мөрәҗәгать итүе белән бәйләнгән – Пәйгамбәребез ﷺ аңа: «Аллаһ синең һәм хатының турында Коръәндә (аять) иңдерде», – дигән.[1]

Бу хәдисләр, икесе ике төрле вәзгыятьне чагылдыру сәбәпле, бер-берсенә каршы булып торалар, әмма дә ләкин алар икесе дә – сахыйх булып саналалар.

Имам Ән-Нәвәви фикеренчә, бәлки Һиләл һәм Говәймир белән килеп чыккан бу ике охшаш вәзгыять бер үк вакытта булып, аяте дә аларның икесенә дә кагылышлы буларак иңгән булуы ихтимал. Имам Әл-Хатыйб та бу хакта: «Бәлки, аларның икесенең дә бер үк тормыш хәлләре бер үк вакытка туры килгәндер», – дип әйтә.[2]

---

1 Бохариның «Коръән тәфсире» дигән бүлегендә ( 6/ 99-100), Мөслимнең «Лиган турында» дигән бүлегендә (4: 205).

2 «Әл-Иткан» (1/33).

Имам Әз-Зәркәши әйткән: «Ә бәлки бу аять мәсьәләнең мөһимлеген күрсәтер өчен һәм аны гел истә тотсыннар өчен» ике мәрба (кабатлап кисәтеп әйтү буларак) иңдерелгәндер»[1].

Менә шуңа карата бер мисал:

Габдулла ибне Мәсгуднең «Ике сахыйх җыентык»та[2] **«Алар синнән рух (җан) турында сорарлар»** («Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:85), дигән Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен тәфсирләве китерелә – аның әйтүенчә, бу аять яһүдләр Мәдинәдә Пәйгамбәребездән ﷺ рух (җан) турында сорагач иңгән. Әмма дә ләкин, безгә мәгълүм ки, – галимнәрнең бердәм фикеренчә, әлеге искә алынган «Сөбхән» сүрәсендәге аять Мәккәдә дә иңгән. Ул вакытта Мәккә мөшрикләре Пәйгамбәребездән ﷺ Зөлкарнәйн һәм мәгарә әһелләре турында сорау алдылар, ә яһүдләр исә ул вакытта киңәшче вазыйфасын гына үтәүче булганнар, алар Пәйгамбәргә ﷺ бирәсе сорауларын мөшрикләргә тапшырып җибәргәннәр. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларның сорауларына җавап иңдерә (без бу турыда алда сөйләгән идек инде).[3] Шуңа күрә дә мондый очракларда «Ничек инде бер үк аять ике мәртәбә иңәргә мөмкин, монда нинди файда бар соң?» – дип сорау куюны урынсыз дип кенә санарга кирәк.

Монда бик зур файда бар. Әз-Зәркәши әйтүенчә[4], «Моның хикмәте шунда ки, кайвакыт, зарурияттән чыгып, Пәйгамбәребезгә ﷺ, килеп чыккан мәсьәләгә ныграк әһәмият бирсен дип, өстәмә итеп шундый ук мәгънәдәге тагын бер аять иңдерелгән булырга мөмкин».

*(Дәвамы бар)*

*Нуретдин Гыйтырның*

*«Коръән турындагы фәннәр» китабыннан*

1 «Әл-Борһан» (1/29).

2 Бохариның «Коръән тәфсире» дигән бүлегендә (6/108-109), Мөслимнең «Кыям тору турында» дигән бүлегендә (8:128).

3 31 нче биттә. Шулай ук «Әл-Мөснәд»не (2/255) һәм Әт-Тәбараниның хезмәтен (15/104) кара.

4 «Әл-Борһан» (1/31).

# «Рисәләи-нур» хәрәкәте

*2008 елның 10 апрелендә Россия Югары Суды карары белән «Нурчылар» Бөтендөнья дини оешмасы экстремистик дип игълан ителде һәм эшчәнлеге тыелды.*

«Рисәләи-нур» хәрәкәтенә нигез салучы – чыгышы белән көрди Сәид Нурси. Бу хәрәкәт хакында сүз алып барганда, Сәид Нурсиның шәхесе, «Рисәләи-нур» китабы һәм нурчыларга зур әһәмият бирелә.

Сәид Нурси (1873-1960) Көнчыгыш Төркиянең Нурса авылында мулла гаиләсендә туган. Гаилә башлыгы Мирзаны, суфи тарикатендә булганы өчен, суфи дип йөрткәннәр. Сәид Нурси Госманлы дәүләтенең «Ислам хикмәт йорты» исемле югары дини шурасында Шәйхел-Исламнан соң икенче урында булган.

Сәид Нурси Коръәнне үзенчә тәфсирләп, көндәлек тормышка кагылган мәсьәләләрне дә өстәп, «Рисәләи-нур» җыентыгын язган. Ул 14 томнан, төрле темаларга багышланган 134 хаттан гыйбарәт. Шушы җыентыкны һәм Сәид Нурсинең шәхесен өйрәнүчеләр нурчылык хәрәкәтенең оешуына сәбәп була. Нурчылар уйлавынча, бу китапта Коръәннең заманча аңлатмасы бирелгән, өстәвенә, бу шәрехләр – илаһи илһам килүнең нәтиҗәсе дә әле, шуңа күрә башка гадәти тәфсирләрдән дәрәҗәлерәк. «Рисәләи-нур» – Коръән Кәримнең көзгесе; ул – могҗиза, аны һичнәрсә белән чагыштырып булмый, шуңа ул хәтта бәла-казалардан саклый, аны укыган кеше Коръән Кәримне, динне яхшырак аңлый башлый, дип саныйлар.

Нурчылар Сәид Нурсины «Бәдигуз-заман» (заманның гаҗәбе) дип атап, аны «мүҗәддид», ягъни динне яңартучы, реформатор дип саныйлар. Моңа Әбү Һурайрадан ﵁ риваять ителгән хәдисне дәлил итеп китерәләр:

«Аллаһы Тәгалә һәр 100 елның азагында өммәтенә динне яңартучы кешене җибәрә». (Табарани, Әбү Дауд, Бәйһәкый, Хәким)[1].

Нурчылык хәрәкәте Беренче Бөтендөнья Сугышы вакытында тарала башлый. Госманлы дәүләте җимерелеп, Ататөрк җитәкчелегендәге яңа хөкүмәт килгәч, бу хәрәкәт туктатыла. Сәид Нурси, эшчәнлеге яңа кануннарга каршы килү сәбәпле, тыела һәм күп елларын төрмәләрдә, сөргеннәрдә үткәрә. Аның тарафдарлары китапларын кулдан күчереп язганнар, яшерен өйрәнгәннәр. 1950 нче елларда Төрек парламенты Сәид Нурсины, аның китапларын аклый һәм бастырып чыгарырга рөхсәт бирә. Нурчылар аның китапларын һәм шәхесен ачык рәвештә өйрәнә һәм өйрәтә башлыйлар.

Нурчылык хәрәкәтенең бер үзенчәлеге ул – актив иҗтимагый эшчәнлек. Алар тарафыннан Төркиядә генә түгел, башка илләрдә дә (Германия, Швейцария, Нидерланды, Якын Көнчыгыш, Африка, төрки телле дәүләтләрдә) күп лицей, мәктәп һәм колледжлар ачыла. Бу уку йортларының эшчәнлеге мактауга лаек, алар материаль җирлеккә дә күп игътибар бирәләр. Аларның мәктәпләрендә укыткан укытучылар, гадәттә – иң яхшы төрек университетларында белем алган кешеләр. Шуңа алар укытуда инглиз телен, педагогика фәненең заманча казанышларын һәм методикаларын файдаланалар. Моның барысы да нурчыларга җәмгыятьтә ышанычлы имидж булдыра.

Нурчыларның тагын бер үзенчәлеге – аларның масса-күләм мәгълүмат чараларына игътибарлары һәм бу өлкәдә көчле позицияләре. Аларның төрек һәм инглиз телләрендә нәшер ителүче 14 журналы, көн саен чыга торган «Заман» газетасы, «Саман юлы» телеканалы һәм ике радиостанцияләре бар.

---

[1] Аллаһы Тәгалә динне яңартучы кешене җибәрә, ә ул кешеләргә сөннәтнең һәм зарар китерүче бидгатьнең нәрсә икәнен аңлатып бирә. Андый кешенең гыйлеме бик күп була, аны еш искә алалар, ул – диннең ачык һәм яшерен гыйлемнәренә дә ия, гыйлеме белән бөтен мөселманнарга файда китерүче галим. Мондый галимнәрнең саны бер яки берничә булырга мөмкин. Алар яшәгән вакытта һиҗри белән 100 еллык тәмамлана.

Үзләрен бер җәмәгать дип атыйлар. Чынлыкта бу хәрәкәт якынча 10-лап оешма һәм фондлардан тора. Структура буларак иң алга киткәне – Фәтхулла Гүлен (фәтхуллачылар, гүленчылар) төркеме. Алар төп нурчылардан инде күптән аерылганнар, аларның җитәкчесе АКШ дәүләтендә яши. Төркиядә гүленчыларны илнең конституцион строен үзгәртү максатында законсыз төркем төзүдә гаепләгәннәр иде. 2014 елда Эрдоган хөкүмәте белән гүленчылар җәмәгате арасындагы мөнәсәбәтләр тагын да кискенләште.

**Кулланылган һәм өстәмә чыганаклар:**

1. Шагавиев Д. А. Аль-Фирак (религиозные течения и группы в исламе). Учебное пособие. Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ. Казань: РИИ, 2014. 142-153 битләр.

2. Ягъкуб В. Татарстанда рәсми булмаган ислам: хәрәкәтләр, агымнар, секталар. Казан: «Иман» нәшрияты, 2003/1424. 13-15 битләр.

*Камил хәзрәт Вәлиуллинның*

*«Исламдагы фирка һәм төркемнәр» китабыннан*

# Мирас

# Мәрҗанинең хаҗ сәфәре

*(Хәзерлек. Васыятьнамәсе. Сәфәр. Нижний. Истанбул. Измир. Мисыр. Мәдинә)*

Мәрҗани хәзрәтләре, хаҗ сәфәренә ният иткәннән соң, 1297 ел, рәҗәб 7сендә/1880 ел, июнь 3сендә Казан губернаторына гариза биреп, хаҗ сәфәренә рөхсәт сораган. Ике айдан соң рөхсәт язуы алган. Шул арада сәфәр хәзерлекләре күрә башлаган. Үзенең икътисади эшләрен карауны һәм үзенә васый (васыятьне кабул итүче) Садыйк бине Сафа Галикәй илә, үзенең карендәше Габделвәли бине Габделбасыйрга тапшырып васыятьнамә язган.

Васыятьнамә ошбу: Бисмилләһир-рәхманир-рәхим. Мин, Аллаһының зәгыйфь колы, мелла Шиһабеддин бине Баһаведдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани, бәдәнем сәламәт, гакылым камил вә сәламәт вакытында васыять кылып әйтәмен. Кайчан мин фәкыйрьгә әҗәл ирешсә, варисларым минем васыятьләремне тулаем үтәрләр вә моннан алда да язылган васыятьнамәләрем берлә һәм бу васыятьнамәм сыйдырган кадәренчә гамәл итеп үтәләдер. Вә тагын гадел шаһитлар хозурында икърар итәмен, минем исемемдә алтмыш ике мең җиде йөз сиксән дүртенче номерда Вольский банкысына салган бер мең ике йөз илле тәңкәлек билет ике углым вә бер кызым: Мөхәммәд, Мәхмүд вә Хаува милкедер. Бишкә бүленеп, ирләргә ике өлештән, кызга бер өлештер. Вә тагын алтмыш ике мең җиде йөз сиксән алтынчы номерда дүрт меңлек билет җәмәгатем Бибифатыйма бинте әл-Хөсәен милкедер. Вә тагын үз милкем булучы барлык китапларымны үз балаларыма вәкыф иттем, алар бер дә сатылмаслар. Кулланып файдаланудан башка урында тотылмас. Файдалана торган ышанычлы кешегә дөрес документ берлә аз вакытка алып торырга бирелеп торылыр. Аллаһ сакласын, үз нәселем киселсә, ту-

ганнарыма вә балаларына шул юл белән вәкыф булыр. Бу китапларның һәркайсына исемем белән бизәлгән, «балаларыма вәкыф» дип яздырган мөһерем басылыр вә җентекләп дәфтәрдә исемнәре илә язылып, саннар берлә билгеләнер.

Вә тагын шкафымда булган барлык шкаф әсбабым, касә вә чынаяк вә чәйнек һәм табаклар, күбесе үз бабаларымнан калган төсләре дип хөрмәтләп сакланган нәрсәләр булганы өчен, ул нәрсәләр беркайчан да сатылмасын, кешегә бирелмәсен. Балалар вәкыфы булып, балаларым вә хатыным үзләре тагын шулай калдырырлар. Бу нәрсәләр вә югарыда әйтелеп үтелгән акчалардан башка банкта вә башка урында булсын, акчалар һәммәсе үз хезмәтем берлә тапкан милкемдер. Акчадан ике углыма икешәр мең, ике кызыма берәр мең тәңкә, тагын хатыныма тиешле мирас өлеше бирелеп, әйберләрдән гайре, Аллаһ хөкеме һәм Мөхәммәд шәригатенә муафыйк булганча бүленеп, шәригатькә каршы бер эш кылынмас. Бу васыятьләремне үз кулым илә язып, шәригатьчә үтәү һәм башкаруга йөкләдем газизләрем Казан сәүдәгәре Мөхәммәдсадыйк бине Сафа вә Казан өязе Ашыт авылының Габделвәли бине Габделбасыйрны. Дәлил итеп исемем язылган мөһеремне бастым (түгәрәк мөһердә язу: «Шиһабеддин бине Баһаведдин әл- Мәрҗани»). Шәгъбанның 5 нче көне, 1297 / 13 июль, 1880 ел. Мин, фәкыйрь Шиһабеддин бине Баһаведдин әл-Мәрҗани. Шаһит булып кулым куйдым: Борһанеддин бине Габдеррәхим. Казан сәүдәгәре Зәйнулла бине Госман. Чуаш Иле авылында имам Габделвәли бине Мөхәммәдрәхим».

Мәхәллә эшләрен карауны үзенең шәкерте вә Печән базары мәхәлләсендә имам булган мелла Хуҗа Әхмәд бине Мозаффарга тапшырган. Биш вакыт намазда имамлыкны шәкерте мелла Борһанеддин бине Габдеррәхим әш-Шәбкәвигә тапшырган. Үзенә юлда кирәк булган киемнәрне вә даруларны хәзерләткән.

Үзе илә бергә Коръән, «Бабирийә», «Тарихе Әбел-газый», «Сөбател-гаҗизин», «Мәҗмәгыль-әдәб», «Фәзаилеш-шөһур», «Мөхтәсар» китаплары һәм үзенең басылган әсәрләреннән «Нәзурә», «Хаккыль-мәгърифәти», «Фәуаиде мөһиммә», «Мөнтәхәбел-вафийә» китапларыннан нөсхәләр алган.

1297 елның рамазан 17 дә / 1880 елның август 11 дә иртәнге намаздан соң хаҗ нияте илә сәфәргә чыкканнар. Сәфәргә чыкканда Мәрҗанинең янында бер мең дүрт йөз сум акчасы булган. Әүвәл «Вольский» пароходы илә Нижнийгә барганнар. Нижнийдә зур базар (ярминкә) вакыты булып, анда Мәрҗани ике көн торган. Андагы сәүдәгәрләр Мәрҗанине ихтирам иткәннәр. Үзенә өч йөз сум кадәр акча бүләк иткәннәр.

Нижнийдән тимер юл берлә Одессага сәфәр иткәннәр. Мәрҗани юлда Мәскәү, Курск, Киев шәһәрләрендә булганын, алар арасындагы чакрым микъдарларын вә ничә сәгать барганнарын яза, башка хатирәләрен теркәмәгән.

Одессада ике көн торып, паспортларын теркәтеп, Истанбулга сәфәр иткәннәр. Анда унике көн торган (Истанбул газеталары Мәрҗани хәзрәтләре хакында язганнар). Ошбу вакытта Истанбулның могтәбәр җамигъ мәчетләреннән булган «Солтан Сөләйман», «Солтан Фатих», «Солтан Сәлим», «Әййа Суфыййә», «Нуры Госмани», «Солтан Баязид», «Әбү Әйү Әл-Әнсари» җамигъларын зийарәт иткән. «Хиркатис-сәгадә» дип мәшһүр булган мәчеттә Расүлуллаһедан калып, бу көнгә кадәр сакланган изге хиркане (өс киемен) зийарәт кылган. «Нуре Госмани» янында казанлылар өчен алыначак тәкийәне (дини бина) барып караган. Истанбулның танылган китапханәләреннән берничәсенә барып вә китаплар укып, үзенә әһәмиятле булган кайбер нәрсәләрне күчереп алган. «Баязид («Хәмидия») китапханәсенә үзенең янында булган әсәрләреннән нөсхәләр бүләк иткән.

Мәрҗани Истанбулда вакытында гыйльми вә сәяси булган байтак кешеләр илә күрешкән. Ул вакытта шәйхел-ислам (мөфти) булган Әхмәд Әсгадь әфәнде, юстиция министры, тарихчы Җәүдәт паша, тышкы эшләр

министры Гасыйм пашалар илә күрешеп, болар илә гүзәл әңгәмәләр корып утырганын яза. Ләкин ошбу олуг затлар иләниләр сөйләшкән, ниләр ишеткән, ниләр сөйләшергә уйлап барган? Бу мөнәсәбәтләрдә һичнәрсә язмый. Фәкать Җәүдәт пашага үзенең китапларын бүләк иткәнен, Җәүдәт паша үзе дә китаплар биргәнен яза. Шәйхел-ислам исә Мәрҗанине тәкъдир итеп, әгәр дә Мәрҗани берничә көн Истанбулда калса, Солтан Габделхәмид хәзрәтләренә сөйләп, хөкүмәт пароходы илә Җиддәгә озаттырмакчы булганын яза.

Мәрҗани болардан башка мәшһүр кешеләр илә булган кара-каршы сөйләшеп утырулары хакында ошбу сүзләрне яза: «Нәкыйбел-әшраф сәйед Сөләйман әл-Бәгъдади янына кердем. Яшь кеше, ачык йөзле, ягымлы вә әдәпле кеше икән. Гарәп, төрки, фарсы телләре илә матур һәм килешле итеп сөйли. Сүзгә оста зат икән. Моның янында дәрвиш бине Ибраһим әл-Кәрди әл-Бәгъдади илә күрешеп таныштык».

«Сәйед Фазыл бине Голуви бине Мөхәммәд бине Сәһел әл-Хәзәри әш-Шафигый йортына бардым. Үзе солтан Габделхәмид янында булганлыктан, безне углы кабул итте. Бу мәҗлестә сәйед Габделкадыйр әл-Җәзаиринең углы да бар иде. Бераз вакыт үткәч, сәйед Фазыл хәзрәтләре дә кайтып килде. Күркәм мәҗлес, гүзәл сөйләшеп утыру булды».

«Сәед Гаун бине Мөхәммәд бине Гаун хәзрәтләре илә очраштым. Бераз сөйләшкәннән соң, янына чакырып утыртып, минем илә гарәпчә сөйләште. Арабызда күп сүзләр булды. Файдалы вә ләззәтле мәҗлес булды. Сәйед Гаун хәзрәтләре тарих, география вә һәртөрле фәннәрдән хәбәрдар галим, инсафлы бер зат икән. «Нәзурәтел-хак» исемле әсәребез барлыгын ишетеп, укырга теләге туганын сөйләде. Вилайәтебездә көн, төн, кояш чыгу, кояш бату, ураза вә намазлар хакында сорашты. Мәмләкәтебезнең шәкертләре, галимнәре, вә гомумән мөселманнары хакында сорашты. Мин дә арабызда булган гыйлемнең югары дәрәҗәсе, дәрес рәвешләре

хакында мәгълүмат бирдем. Һөнәр гыйлемнәренең азлыгын, булганнары да кагыйдәсез вә тәртипсез булганына хәсрәтләнеп аңлаттым.

«Соңыннан сүзне минем китапларга күчереп: «Сез үзегез төрки, халкыгыз да төрки, алар өчен язылган китапларның да төрки телендә булуы тиеш иде. Сезләр әсәрләрегезне ни өчен гарәпчә язасыз?» – диде. Җавабымда: «Гарәп телен галимнәребез вә шәкертләребез беләләр. Китапларыбыз башка өлкәләргә китсә дә, бәлки укучылар булыр. Төркичә язылса, башка җирләрдә файдаланмаслар», – дидем. Бу сүзебезне урынлы күреп: «Дөрес, гарәп теле уртак телдер», – диде. Чыгарга рөхсәт сораганыма: «Бу сөйләшеп утырудан туймадым. Әңгәмәбез аз булды. Хиҗаздан кайтуыгызда кабат күрешербез, килегез», – диде. Соңыннан мин: «Гасре сәгадәттән ерак калган булсак та, әлхәмдүлилләһи, пәйгамбәр нәселен күреп мәҗлестәш булу безгә дә насыйп булды», – дигәнемә шатланды. Чыкканда урыныннан торып, бераз озатты. Аерылганда кулын тотып үптем, ул да минем кулымны үпте. Бу заттан тәэсирләнеп аерылдым. Әсәрләремнән берәр нөсхә бүләк иттем».

Мәрҗани Истанбулда вакытында сугыш зирәһлеләрен (хәрби корабльләрне) барып күрүе хакында ошбу сүзләрне яза: «Солтан Сәлим» мәчетенең хатыйбе илә диңгез гаскәрләрен барып карадык. Диңгез гаскәрендә булган меңбашы Гариф бәк һәр кат, һәр бүлмә вә һәр җиһазларын вә нинди кыяфәттә кулгануларын күрсәтеп, җентекләп аңлатты. Аннан соң кофе илә сыйлады. Шаһларча озатты. Гариф бәк безне озатканда гаскәрләргә «Сәлям тор!» дип әйтте. Алар мылтыкларын күтәреп, саф булып безне хөрмәт итеп озатып калдылар».

«Ошбу броненосец Англиядә эшләнеп, бәясе, корал вә җиһазларыннан башка дүрт миллион биш йөз мең сум хакында, имеш.

Моның сыйфатын гакыл аңлаудан, тел аңлатудан гаҗиз. Озынлыгы 444 адым, киңлеге 59 адым, тирәнлеге 40 адым булып, 12 данә зур туп-

лары бар. Үзе 1200 ат куәтендә булып, меңнән артыграк кешене күтәрә икән».

Мәрҗани хәзрәтләре моннан тыш Истанбулның акча хисапларын, анда вакытында ишеткән китапларны, вафаты турында хәбәр алган мәшһүр затларны, кайберләренең кыскача тәрҗемәи хәлләрен, Истанбулның мәшһүр мөдәррисләре исемнәрен, олуг мәчетләрдән «Әййа Суфыййә», «Солтан Фатих», «Солтан Сөләйман» мәчетләренең аркылы вә буйларының үлчәмнәрен, мәчет диварларына язылган кайбер аятьләрен, шигырьләрне дә язып алган. Истанбулда яшәүче татарлардан байтак кешеләрдә кунак булган.

Мәрҗани, гомумән, Истанбулда вакытларыннан шат булган. Анда баргач күңеле күтәрелеп, яңа рух кереп, байтак тәэсирләр алган. Шатлыгыннан күңеле тулган вакытлары да байтак булган. Үзе дә: «Иминлектәге мөселман гаскәренең көче, солтанның бөеклек илә чыгуы, ислам бөеклеген күрү, хәрби корабны карау, «Хиркаи сәгадәт» һәм Әбү Әйүб әл-Әнсари зийарәтләре миңа зур тәэсир иттеләр. Күңелем тулып еладым», – дигән.

Истанбул галимнәре дә Мәрҗанине ихтирам итеп, аны яратып калганнар. Истанбулда вакытыбызда берничә китап язулары илә мәшһүр мөдәррисләрдән Исмәгыйль Хаккый хәзрәтләре: «Мәрҗани миңа зур хатирә калдырды. Ул зур галим вә чын зат иде. Аның китапларыннан һәрвакыт файдаланабыз. Яңа сүзләр, яңа фикерләр күрәбез», – дип сөйләде. Мәшһүр мөдәррис вә әдипләрдән шәйех Халис хәзрәтләре: «Мәрҗани гаять туры сүзле, зур галимдер. Мәрҗанинең теленнән вә каләменнән ялкын чыга. Мәрҗани борынгылардан Ибне Хәзем кебидер. Әгәр дә Мәрҗани сәламәт булса, махсус аны күреп, сөйләшеп кайтыр өчен Русиягә сәяхәт итәр идем», – дип сөйләде.

Мәрҗани, Истанбулда 12 көн торганнан соң, туры Искәндәриягә билет алып пароходка утырган. Пароходта икенче класска утырып барган-

нар, ашау-эчү дә пароход идарәсе тарафыннан бирелгән. Мәрҗанинең юлдашы Зәйнулла хаҗи һәр нәрсәне белергә, тикшерергә сөючән бер кеше булганлыктан, ашханәгә төшеп карап йөргән. Мәрҗани янына килгәч: «Тавык бугазлый торган урыннарны карап йөрдем. Анда тавыкны бугазламыйлар, бәлки муеныннан чабып кына өзәләр дә ташлыйлар. Шулай җаны чыга икән», – дигән. Аңарга каршы Мәрҗанинең азрак кәефе киткән төсле булып: «Аларны тикшереп йөрергә сиңа чурт кушканмы?» – дигән дә шуннан соң тавык ите ашаудан сакланган.

Юлда Кәлибули, Чынак Кальга, Мәдәллидән үтеп, Измир шәһәрендә бер көн туктаганнар. Мәрҗани иптәшләре илә пароходтан чыгып Измирне караганнар. Җомга көн булу мөнәсәбәте илә бер мәчеткә барып җомга укыганнар. Мәрҗани Измир хакында ошбу сүзләрне яза: «Измир шәһәренә чыгып йөрдек. Юынган таш җәелгән гүзәл пристане, бик яхшы мөсафирханәләре, гүзәл кибетләре, зиннәтле сәүдәханәләре, машиналы фабрик вә заводлары бар. Урамнарда трамвай йөри, урамнарга таш түшәлгән булса да, күбрәк урамнары тар икән. Һәртөрле халык күп булып, урам вә базарлары кайнап тора. Мәчет-мәдрәсә вә яхшы биналары да күптер. Монда безнең татар карендәшләребез дә бар икән. Кайберләре илә сөйләштек. Безгә Измирне күрсәттеләр. Җомга алдыннан мәчеткә бардык. Шунда бер Коръән күреп, бер өлешен укыдым. Бу Коръән гүзәл язулы булса да, укыганда тын алу өчен туктаулар вә язулар игътибарсыз язылган. Ике җирдә ялгышы бар иде, аларны төзәттем. Аннан соң бер адәм «Кәһәф» сүрәсен укыды. Тын алу өчен туктауларга игътибарсыз, хәрефне сузып укулар да чамадан тыш булса да, тавышы яхшы иде. Соңыннан азан укылды. Манара азаны илә минбәр азаны арасында ун минут булды. Вәгазь сөйләүче кулына һич нәрсә тотмыйча вәгазь укыды. Вәгазендә шөкер итүне кабатламаса да, «Тәшәһһөд» дип бабалардан мирас итеп алганга каршы рәвештә укыды. Җомгадан соң Коръән укылмады».

Мәрҗани бик дикъкатьле кеше. Ул һәр нәрсәгә дикъкать вә тигез үлчәүлелек күзе илә карый. Аның иҗтимагый җәһәтен дини гыйлемнәре җиңгәнлектән, сөннәт вә яңа гадәтләргә зур әһәмият бирә, халыкларның гыйбадәт рәвешләрен язып китә. Бигрәк тә безнең халыктагыга каршы бер нәрсә күрсә, аңа игътибар итә. Измир мәчетендә җомгада ике азан арасында ун минутка кадәр торуларын яхшы дип санап, бездә манара азаны илә минбәр азаны арасындагы вакытны бик аз вә кыска калдыруларын яратмый. Җомгадан вә башка намазлардан соң Коръән укылмаганны берничә урыннарда игътибар итә. Моны үзе кабат яза. Бездә исә икенде вә ахшамнан башка намазлардан соң Коръән уку гадәт булган.

Мәрҗани «Тәшәһһөд» укуларын берничә урыннарда язып китә. Моны язуның сәбәбе шулдыр ки, Мәрҗани вакытында татар галимнәре арасында ошбу мәсьәләләрдә байтак үзара килешмәүчелек бар иде: һәр җирдә «әлхәмдүлиллаһ», «әлхәмдүлиллаһ» диеп шөкер итүне кабатлап керешәләр. Мәрҗани исә, болар борынгы кешеләрнең гадәтенә каршы дип аңлатып, дәлилләр вә риваятьләр яза. «Әл-бәркыль вамиз» китабының берничә сәхифәсен дә бу мәсьәләгә багышлаган.

Мәрҗани Измирдән Искәндәриягә барып, анда өч көн торып, шәһәрнең төрле урыннарын күреп йөргән. Искәндәрия шәһәре Мәрҗанигә бик ошаган. Аның урамнарының киңлеге вә турылыгы, дүрт почмаклы матур таш җәелгәнлеге, яшәү вә тормыш өчен кирәк нәрсәләренең җитешлеге, халыкның һәр җирдә рухлы булып кайнап торуы Мәрҗанинең игътибарын җәлеп иткән.

Мәрҗани зиратлар хакында яза: «Искәндәриядә имам Бусайри («Касыйдәи бәрдә» авторы) илә Ибне Хаҗиб (нәхүдән «Кафийә» авторы) зиратында булдык. Бу шәһәрдә Данийал, Локман Хәким, Искәндәр, Сәгыйдь бине Әбү Вакъкас, вә Җабир каберләре дип гади халык күрергә барып йөриләр. Ләкин болар һәркайсы дөреслеккә хилаф. Алар икенче урыннарда вафат булганнар».

Искәндәриядән тимер юл илә Мисырга барып, анда үзенең шәкерте Кәмал карый бүлмәсенә төшеп, өч көн торган. Кәмал карый Мисырның күрергә тиешле булган танылган урыннарын күрсәтеп йөргән. Аның илә бер көн Мисырның иң иске тарихи истәлекләреннән – фиргавеннәрдән калган пирамидаларны карарга барганнар. Кайберләренең эчләренә кереп караганнар. Пирамидалардан кайтканда гаскәрләргә булган махсус зур йорт вә бакчаларны караганнар. Мисырның зур галимнәреннән булган Мәхмүд бәк Фәләкигә кереп кунак булганнар. Мәхмүд Фәләки Мәрҗанинең кайбер әсәрләрен укыганлыктан, аңа ихлас вә ихтирам белән кунак иткән, вә берничә көн үзенең йортында калып кунак булуны сораган. Мәрҗани исә рәхмәт белдереп вә гафу үтенеп аерылган. Аннан соң Мисырның мәшһүр мәчетләрен, кайбер мәдрәсәләрен вә китапханәләрен күреп йөргән. Үзе өчен кирәк китапларны сатып алган.

Мәрҗани Мисыр вә Искәндәриядә Мөхәммәд Гали паша, Ибраһим пашаларның урамга куелган зур сурәт вә һәйкәлләренә игътибар итеп язып алган.

Мисырда вакытында бер көн исламга күп хезмәт иткән мәшһүр галимнәрнең зиратларына барганнар. Мәрҗани яза: «Мөхәммәд Гали паша, Ибраһим паша, Әхмәд Фарикъ вә Турсун пашаларның каберләрен барып күрдем. Бөек сәйедләрдән кайбер затларның, изге вә сәйедзадәләрдән кайберләренең, хатыннардан сәйидә Сәкинә, сәйидә Нәфисәнең каберләрен барып күрдем. Галимнәрдән имам Шафигый хәзрәтләрен, Шәйхе Шатыйбый хәзрәтләрен, аннан соң Ибне Дәкыйкъ вә Ибне Гата әл-Искәндәрани, вә аннан бер якта Кәмаледдин ибне әл-Нөммам әл-Мөхаккакъ (рәхмәтуллаһи галәйһи) хәзрәтләрен барып күрдек. Мөхаккакъ ибне әл-һөммамның язулы ташы, кечерәк иске кабер өстендәге төрбәсе булса да, як-яклары җимеректер. Аннан китеп имам Кәбир Ләйс бине Сәгыйдь әл-Мисрыйны барып күрдек. Ошбу кабер Ләйс бине Сәгыйдьнеке булуы дөрестер. Әмма кайбер Бохара вә Казан якларыннан килгән надан-

нар факыйһ Әбелләйс әс-Сәмәрканди дип кайталар. Болар, шиксез, хата әйтәләр. Ул факыйһ Әбелләйс 370 елда Бәлхтә вафат булды».

Бу язганнарыннан күренәдер ки, каберләрен барып күргән кешеләрдән Мәрҗанинең иң күп игътибар итеп кабер ташларын язып алганы Ибне әл-Һөммам хәзрәтләренең кабере. Бу зат хәнәфия мәзһәбендәге галимнәренең иң зур факыйһ вә мөхәддисләреннән. Ислам фикһендә булган «Фәтхел-кадыйр» исемле китабы иң яхшы дип табылган әсәрләрдән булып, Мәрҗани карашынча да иң ышанычлы китап. Үзенең шәкертләрен бу китапны укырга кызыктыра, гомеремдә «Һидайә» вә «Фәтхел-кадыйр» китапларын дүрт мәртәбә укып чыктым, дип сөйли икән. Ибне әл-Нөммам кабере янында озак торып караганнан соң: «Бу зат безнең остазыбыз. Бу кешенең китапларыннан бик күп файдаланабыз», – дип әйткән. Кәмал карый монда өстәп ошбу сүзләрне сөйләде: «Кайбер урыннарны караганда Мисыр галимнәреннән дә бер-ике кеше бар иде. Мәрҗани аларга Мисырның төрле урыннары вә галимнәре хакында тарихи мәгълүматлар сөйләп йөрде. Берничә кешенең каберләрен күрсәтүләренә бәйләп Мәрҗани: «Алар янында фәлән вә фәлән галимнәрнең дә кабере булырга, шул тарафта фәлән исемле урын яки тау булырга кирәк иде. Алар кайда?» – дип сорашып йөрде. Янында йөргән кешеләр соңыннан: «Без Мисырда торып та белмәгән күп нәрсәләрне Мәрҗанидән ишетеп белдек», – дип сөйләделәр.

Мисырдан Сүәйескә тимер юл илә сәфәр иткәннәр. Мәрҗани юлда булган һәрбер станцияләр араларындагы ераклыкны, машинаның сәгатенә күпме йөргәннәрен яза барган. Гарәпчә язылып вагон эченә ябыштырылган, юлчылар өчен булган кагыйдәләрне тулысынча күчереп алган. Мисыр тимер юлындагы машиналарны Русиядәгедән тизрәк йөри, вагоннары да иркенрәк дип мактый.

Сүәйестән пароход илә Йәнбәгъкә барып, анда биш көн торганнар. Йәнбәгъкә ирешү беренче мәртәбә Гарәбстанга аяк басу булганлыктан, Мәрҗанинең тагын да игътибары артып, гарәпләрнең һәр сүз вә

гадәтләренә игътибар итеп, алар сөйләшкән кайбер сүзләрне, алардан ишеткән җимеш, җиһаз вә башка нәрсәләр хакындагы байтак сүзләрне һәм пароходта аш исемнәре язылган кәгазьне (прейскурантны) язып алган. Болар эчендә сүзлек китапларында күренми торган яңа сүзләр дә байтак бар. Мәрҗани Йәнбәгъ хакында ошбу сүзләрне яза: «Йәнбәгътә төрле җирләрдән килгән байтак мосафирлар илә күрешеп таныштык. Казаннан китеп Йәнбәгътә вафат булган хәйриячеләрдән хаҗи Хөсәен бине Йосыфның (бу зат Казанда, Мәрҗани мәхәлләсенең тырыш байларыннан булып, хаҗ сәфәрендә дә үз акчасы илә ике кешене хаҗга алып барган вә шул сәфәреннән кайтуда 1281/1864 елны вафат булган. Аның Мәрҗанигә дә зур ярдәмнәре булып, башлап Казанда йорт алырга киңәш биреп, шул вакыт Мәрҗанигә берьюлы мең бер йөз сум акча бүләк иткәнен «Мөстәфадел-әхбар»да яза (2 җилд, 350 б.). Бу да аз акча түгел.) каберен сорашып барып күрдек. Коръән укып багышладык. Аллаһы Тәгалә кабул итеп, рухын шат кылсын. Йәнбәгътә чиркәү шәкертләре очрап сөйләштеләр һәм бер төркем иранлыларга очрадык. Иранлылар намаз укыганда кулларын колакларына кадәр күтәреп, кычкырып тәкбир илә кул баглап намазларда «Фатиха»дан һәм сүрәдән әүвәл кычкырып бисмилла әйтәләр. Мактау (сәна) укымыйлар, һәр ике рәкәгатьтә «Ихлас» сүрәсе укыйлар. Иелеп торганда «Сөбхан Аллаһ» дип өч мәртәбә, сәҗдәдә «Сөбханә Рабилл-әгъля вә бихәмдиһи, Аллаһүммә салли галә Мүхәммәди вә әлиһи» дип әйтәләр. Сәҗдәдән торганда кулларын бераз күтәрәләр. Азан вә тәкбир әйтүләрен, сөннәт вә витер укыганнарын күрмәдем. Укулары сарт (үзбәк) укуы төреннән зәгыйфь булып, һәр аять башында укыганда тын алу өчен туктап торалар иде».

Мәрҗани ошбу сәфәрендә, байтак җирләрдә иранлыларга очрап, алар илә сөйләшкәнен яза, аларның да хәлләренә әһәмият бирә. Моннан башка урыннарда да аларны яклый, байтак татар галимнәре аларны кяфер дип атарга тырышуларын да, аларның да безнең кеби мөселманнар

икәнен исбат итәргә тырыша, гыйбадәтләре дә безнең гыйбадәт кеби булганын сәяхәтнамәсенә дә язып куя. Китапларыннан бер нөсхә «Нәзурәтелхак»ны шигый имамына бүләк иткәнен яза.

Йәнбәгътән Мәдинәгә дөя берлә барганнар. Мәрҗани яза: «Йәнбәгътә Рәшид, Гаид исемле кешеләрне дөяләре берлә яллап Мәдинәгә киттек. Боларның дөяләре бер сәгатьтә мең өч йөз кырык адым атлый икән. Димәшкъ (Шам) кәрваны илә баруыбызда Димәшкъ дөяләренең мең өч йөз адым атлаганнарын санадым. Гарәплләрдән юлдагы кайбер агачларның вә авылларының исемнәрен сорап бардым. Юлда «Бәир Сәгыйдь» исемле урынга җиткәч авырдым. Дөя өстендә барганга кайбер намазларыбызны ишарә берлә укыдык. Йәнбәгъ берлә Мәдинә арасы бик тигез, тимер юл яки трамвай эшләтергә бик уңай икән. Юлда кәефсез булганлыктан, Мәдинәгә баргач, дүрт кеше ятак илә күтәреп кенә керделәр. Хәрәме шәрифкә дә ике көннән соң гына чыгып, «Рәүда-и моттаһара»да ике рәкәгать намаз укып, Расүлуллаһы вә хәзрәти Әбүбәкер вә Гомәр вә хәзрәти Фатыйманы зийарәт кылдым. Бер җиргә утырып хәл җыйдым. Мәчеттә намаз укыганда сөннәтләрне утырып укыдым. Шуннан соң кәефем бераз яхшы булып, Мәдинәнең төрле урыннарын барып күрдек. Хәзрәти Расүл Мәдинәгә килгәндә иңгән Әбү Әйүб Әл-Әнсари йортына кереп, намаз укып дога кылдык. Аннан соң хәзрәти Габбас, хәзрәти Хәмзә, хәзрәти Госман Габдеррәхман бине Гауф, Сәгыйдь бине Әбү Вәкъкас, мөэминнәр анасы хәзрәти Гайшә вә башкаларның каберенә бардык. Янә имам Малик зираты янында имам Нафигъ зираты дип күрсәттеләр. Ләкин бу халык ышануы. Ву кабер Нафигъ Мәүла Ибне Гомәрнеңдер. Шәйхе Шамилнең зиратын да күрсәттеләр. Мәдинәдә бер атна торганнан соң, мин фәкыйрь, ак җөббә, ак күлмәк-ыштан киеп, билемә яулык бәйләп «Хәҗәрәтес-сәгадәт»кә кереп, Расүлуллаһка ﷺ сәлам биреп дога кылып чыктым. Аның өстендә калын ефәктән бер чаршау, як-ягында шәмнәр бар иде. Бер көн «Куба» мәчете зиратына бардык. Мәдинәдә шафигый, малики, хәнәфиләр җыелып

укыйлар. Мин намазларымны төрле мәзһәб имамнары артында укыдым. Мәдинәдә хәрәме шәрифкә хатыннар да катнашалар. Мәчетнең бер ягында аларга махсус бер урын бар». Мәрҗани, Истанбул, Мисыр, Мәдинә, Мәккә кеби исламның иң зур шәһәрләрендә хатыннарның мәчеткә керүләренә игътибар итеп, сәяхәтнамәсендә берничә урыннарда язып китә. Аларның мәчеттә җәмәгать намазларына, вәгазьләргә керүләре, Расүлүллаһ вә изге сәхабәләр вакытыннан башланып килгән гадәт булганнан, Мәрҗани бу эшне бер дә гаҗәпләнмичә генә карый.

Мәдинә һәм анда күрешкән кешеләре хакында Мәрҗани ошбу сүзләрне яза: «Мәдинәи Мөнәүвәрә тигез урында, һәм таулары ташлы түгел, һавасы хуш, мөлаем. Мәдинәдә бик муллык, ашау-эчү нәрсәләре арзан, гранат (анар җимеше) вә хөрмәләре бик әйбәт. Бодай, арпа, ясмык кеби нәрсәләрне чәчеп үстерәләр. Мәдинәдә байтак гыйлем кешеләре һәм мәдрәсәләр бар. Мәдрәсәләрдән берничәсен без дә барып күрдек. Мәдинәдә булган хөрмәтле урыннарны, мөбарәк шәһидләр каберләрен йөреп карадык. Догалар кылдык. Мәдинәнең олуг шәхесләре илә күрешеп, сөйләшеп утырдык. Гыйлем алмашып файдаландык. Мәдинәдә шәйхел-ислам Хәсән Фәһими, шәйхе Мөхәммәд Мозаһһар бине Әхмәд Сәгыйдь Әл-Һинди, шәех Ахунҗан бине Габделһади әл-Бохари, шәйх Габделҗәлил Әл-Мәдини, сәйед Габделкадыйр бине Әхмәд Әт-Тарабөлиси, мөфти Мөхәммәд Әр-Рубали, Кизляр мәдрәсәсе әмине шәех Хәлил бине Ибраһим, мулла Зыяэддин Әт-Тархани вә башкалар илә сөйләшеп утырдым. Шәех Мозаһһар хәзрәтләре җомгадан соң, изге кабергә каршы торып, минем өчен дога кылды».

*(Ахыры киләсе санда)*

*Шәһәр Шәрәф*

*1332 ел, 23 зөлкагъдә/1914 ел, 13 октябрь*

*«Мәрҗани» фәнни- популяр җыентыгыннан*

# Пәйгамбәрләр тарихы

## Адәм عليه السلام

Аллаһы Тәгалә күкләрне-җирләрне яраткач, беренче атабыз Адәмне عليه السلام коры балчыктан яратты, аңа җан бирде. Фәрештәләргә хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылырга кушты. Фәрештәләр хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылдылар, Иблис сәҗдә кылмады. Сәҗдә кылмаган өчен Аллаһның хозурыннан сөрелде. Аннан соң хәзрәти Адәмнең сул кабыргасыннан беренче анабыз Хаваны яратты. Тередән яратылган өчен «Хава» дип әйтелде.




Соңыннан Аллаһы Тәгалә хәзрәти Адәм илә Җәннәткә куйды. «Ашагыз-эчегез, богдай агачыннан ашамагыз», – диде. Шайтан бервакыт Җәннәткә кереп Адәм илә Хаваны алдады: «Бу агачтан ашасагыз, мәңге Җәннәттә калырсыз», – диде. Адәм илә Хава ашадылар. Аллаһы Тәгалә аларны Җәннәттән чыгарды, җиргә төшерде. Адәм عليه السلام Һинд кырларында Сәрнәдиб исемле атауга төште. Хава Мәккә янында булган Җиддә тавына төште. Хәзрәти Адәм Җәннәттән чыкканына бик кайгырды, кылган гөнаһларына тәүбә итте. Аллаһы Тәгалә тәүбәсен кабул итте, Мәккә тарафына китәргә боерды. Хәзрәти Адәм Мәккәгә барып хәзрәти Хава илә күреште. Аннан соң Адәм илә Хава икесе бергә яшәделәр. Хәзрәти Хава һәр корсактан берсе ир, берсе кыз икешәр бала тудырды. Бары егерме корсак күтәрде. Шис عليه السلام ялгыз дөньяга килде.

Аллаһы Тәгалә бер корсактан туган ир балага икенче корсактан туган кыз баланы алырга боерды.

## Кабил вә Һәбил

Хәзрәти Адәмнең Кабил, Һәбил исемендә ике углы бар иде. Кабил үзе белән бер корсактан туган Әкълимә исемле кызны алмакчы булды. Хәзрәти Адәмнең шәригатендә Әкълимә Һәбилгә тиеш иде. Хәзрәти Адәм Кабил илә Һәбилгә әйтте: «Аллаһыга корбан суегыз, кайсыгызның корбаны кабул булса, Әкълимәне ул алыр», – диде. Корбан суйдылар. Һәбилнең корбаны кабул булды, Кабил көнләште. Һәбилне таш белән атып үтерде, җиргә күмде. Аллаһыга һәм атасына гөнаһлы булды, җир йөзендә әүвәл кан түккән, кеше үтергән – Кабил булды. Хәзрәти Адәм үзенең балаларына һәм балаларының балаларына пәйгамбәр булып, Аллаһ тарафыннан ун кәгазь китап килде. Үзенең балаларыннан балаларының балаларыннан йөз мең кадәр кешене күрде. Мең яшь яшәде. Хәзрәти Адәмнән бер ел соң хәзрәти Хавва вафат булды. Хәзрәти Адәм Сәрнәдиб атауларында, хәзрәти Хавва Җиддәдә күмелде, Аллаһу әгъләм.

## Хәзрәти Шис ﵇

Хәзрәти Адәмнән ﵇ соң углы Шис ﵇ пәйгамбәр булды. Хәзрәти Шис кардәшләре арасында бик гакыллы иде. Хәзрәти Адәм Шисне барча угылларыннан артык сөяр иде. Хәзрәти Адәм үлгән вакытта хәзрәти Шисне барча балаларына падишаһ итте. Хәзрәти Адәмнән соң Аллаһы Тәгалә хәзрәти Шискә пәйгамбәрлек бирде вә илле кәгазь китап җибәрде. Шис ﵇ Кәгъбә мөкәррамәине таш вә балчыктан ясады. Аллаһы Тәгаләгә гөнаһлы булган Кабилнең балаларына үзәренә кылыч күтәрде, алар белән сугышты. Адәм балаларыннан әүвәл кылыч ясаган вә кылыч белән сугышкан хәзрәти Шис булды. Хәзрәти Шиснең балала-

ры бик күп булды, барча кешеләр шуның балаларыннан яралды. Хәзрәти Шис тугыз йөз унике яшендә вафат булды. Кабер шәрифе Мәккә янында Әбү Кубәйс тавындадыр.

## Хәзрәти Идрис عليه السلام

Хәзрәти Адәмнең балалары арасында тугры юлдан чыгып, потларга табыну кеби начар эшләр күбәйде. Аллаһы Тәгалә аларны тугры юлга күндерер өчен Идрисне عليه السلام җибәрде. Хәзрәти Идрискә утыз кәгазь китап җибәрде. Хәзрәти Идрис хакны голәмәгә, падишаһларга, әмирләргә, гавамләргә бүлде. Җир йөзендә иң элек кием тегеп кигән, каләм белән язу язган Идрис عليه السلام иде. Аңа кадәр Адәм балалары хайван тиресе капланып йөргәннәр. Идрисне عليه السلام тере хәлендә Аллаһы Тәгалә күккә күтәрде. Күккә күтәрелгәндә өч йөз алтмыш биш яшьләрендә иде.

## Хәзрәти Нух عليه السلام

Хәзрәти Нух عليه السلام килмәстән әүвәл адәм балалары арасында бозык эшләр күбәйде. Аллаһы Тәгалә аларның арасын төзәтер өчен Нухка عليه السلام пәйгамбәрлек бирде. Хәзрәти Нух кавемне күп еллар хак дингә өндәде. Үзенең өч углы, алардан башка сиксән кеше иман иттеләр, башкалары хәзрәти Нухка бик иза вә җәфа кылалар иде. Соңыннан хәзрәти Нух аларның иманга килүеннән өмет кисте, аларга явыз дога кылды. Аллаһы Тәгалә хәзрәти Нухка көймә ясарга кушты. Көймә тәмам булгач, хәзрәти Нух иман китергән кешеләрне һәм хайваннардан берәр пар, ягъни бер иркәк, бер тешене алып, көймәгә менде. Үзенең Йәм исемле углы мин тауга менеп котылырмын диде. Көймәгә кермәде. Хәзрәти Нух нәсыйхәт кылып торганда дулкын килеп бугды. Соңыннан туфан заһир булды. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре бөтен җир йөзен су белән тутырды. Су биек тауларны ашты, җир йөзендә калган кешеләр һәм хайваннар барчасы

һәлак булдылар. Туфан алты ай кадәр торды, соңыннан сулар кимеде, хәзрәти Нухның көймәсе Җуди исемле тауга туктады. Көймәдә хәзрәти Нухның өч углыннан башкасы барчасы һәлак булдылар. Соңыннан бөтен дөньядагы халык хәзрәти Нухның бу өч углыннан таралды. Шуның өчен хәзрәти Нухка «икенче Адәм» дип әйтелде. Хәзрәти Нухның Хәм исемле углының нәселеннән – каралар, ягъни хәбәшиләр-зинҗиләр, Сәм исемле углының нәселеннән – гарәпләр, фарсылар, рум халыклары, Йәфис исемле углының нәселеннән төрекләр, татарлар, магул халыклары киләдер. Хәзрәти Нух тугыз йөз илле яшендә вафат булгандыр.

*(Дәвамы бар)*

*Галимҗан Баруди, 1899 ел*

# Некролог, яки кыскача сийр[1]

*(Некролог) Юнан сүзедер, үлгән кеше хакында берничә җөмлә мәгънәсендә. Ягъни бәгъзе изгелекләрен бәян кыйладыр. Гарәпчәсе кабусин мәгънәсендә.*

**Мелла Габденнасыйр әл-Курсави.** Мелла Габденнасыйр әл-Курсави – Казан губернасы вә өязе Курса илендә имам вә мөдәррис, вә һәм зиядә мөхәкъкыйк вә мөдәкъкыйк[2] голямаи заман, хәтта мөҗтәһид дәрәҗәсендә, «Курса Габденнасыйр мелла» дип мәшһүр адәм иде. һәр хөкемне Кәламуллаһдан иҗтиһад кыйлыр иде. Вә әйтер иде: «Замане иҗтиһад мөнкарыйз түгел, һәркем мөбтәля биһ үзе иҗтиһад кыйлсын. Тәкълид белән генә чикләнү хурлык», – дияр иде. Вә һәм: «Голямаи Тафтазанидан соң миндәен адәм дөньяга килгәне юк, дияр иде», – диләр. Мөсәннафат вә тәхрирләре күптер. Җөмләдән берсе – «Гакаид ән-Нәсәфи»гә шәрех иткәндер. Башка гакаид китапларына караганда аермасы бардыр. Ягъни Габденнасыйр мелла «сыйфатуллаһ важибел вөҗүд биззат» дип язадыр. Бу хосуста Бохарада күп голяма белән моназара кыйлышып, күп адәмнәре әзах кыйлганнан соң, әмиргә мәгълүм булып, әмир Габденнасыйр мелланы сәясәт мәйданына китереп кател кыйлырга хөкем иткәч, дуслары вә шәрикләре: «Бу сүзеңнән кайт, вә илля башың китәдер», – дип димләгәннәрдер. Як-ягында ничә җәлладлар ялангач кылыч белән торганда, Габденнасыйр мелла: «Бу сүземнән кайттым», – дигәч, әмир кателдән хәляс кыйлгандыр. Әмиргә вә Бохараның башка голямасына хилаф төшкән гыйбарәт ошбудыр. «Хакыйкатьне эзләү һәм табу – борын заман ышануларын [потка] киң куллануда, аларга табынуларда түгел, бәлки аларның кирәксезләрен читләтү ул. Бу – Аллаһы Тәгаләнең кешенең үзенә биргән сыйфаты һәм хокукы элеккечә гамәл кыйлу дөрес түгел», – дигән

[1] Оригиналда шулай килә. «Тәгъзия яки кыскача сияр» дип аңларга кирәк – ред.

[2] Мөхәкъкыйк вә мөдәкъкыйк – төбенәчә һәм җентекләп тикшерүче.

сүзләрдер. Вә дәхи аның мөсәннафатыннан Һәфтияк Шәрифкә ясаган тәфсире бар, халык арасында мөстәгъмәл вә мөгътәбәр тәфсирдер. 1863 елда басылган иде.

Бу тәфсирдән башка янә берничә рисаләсе бар. Шәфәкъ хосусында бер рисаләсе бар. Ошбу рәвешчә ибтида кыйлынадыр: «Аллаһы Тәгаләне Коръәндә күп телгә алу, барысы бергә, аңа мактаулы дога гына янә әүкат әс-салат вә шәфәкъ хосусында күп тәхрирләре күренәдер. Тәхрирләреннән мәзмуны фәһемләнә: мөбтәля биһ үзе ижтиһад кыйлырга тиеш. Заман ижтиһад монкарый түгелдер. Габденнасыйр мелла Курсавиның виладәте тәкърибән[1] 1765 еллардадыр. Хаҗ сәфәрендә Истамбулда тагун белән вафат булгандыр 1813 елда. Казаннан бергә киткән кешеләр бер көнне ун кеше вафат булганнар. Күбесе Габденнасыйр мелланың шәкертләре иде, диләр. Хаҗ сәфәренә китмәс борын, Курсада ничә еллар дәрес әйткәндер.

**Каргалы Габдрахман бин... (Мөхәммәдшәриф).** Русиянең мәшһүр голямасыннандыр. Мелла Ишнияз әфәндедән соң Каргалыда мөдәррис булып дәрес әйткән адәмдер. Мелла Ишнияз мелла Габдрахман заманасында Каргалы мәхзән әл фөнүн булмак белән гаять олуг булгандыр. Ничә мәдрәсәләр вә ничә голямалар шаулатып, дәрес әйтеп, иншар гыйлем кыйлганнардыр.

**Юртыш Хәмид хәзрәт бин Габдессәлам.** Мәмдәл кешесе. Казан өязе Юртыш илендә имам вә мөдәррис вә һәм тарикать юлында пишкадәм. Ишанлык белән мәшһүр адәм иде. Зиядә мөтәшәрригъ вә мөтәдәйин вә һәм сахибе кәрамәт[2] адәм иде. Күп адәм аның дәресе белән мөшәрәф булганнардыр. Олуг мәдрәсәсе бар иде. Һәр заман голяма һәм динле,

---

[1] Тәкърибән – якынча.

[2] Мөтәшәригъ вә мөтәдәйин вә һәм сахибе кәрамәт – шәригатьле һәм динле һәм могҗиза күрсәтүче.

вә таләбә[1] туп-тулы иде, диләр. Хәяты вакытында күп кәрамәтләрен сөйлиләр. Җөмләдән берсе: үзенең шәкертләреннән берәү кунак итеп алып барганда, Зөягә җиткәч аты арыган һәм баралмас булган. Акъегет авылына баралар икән. Хәмид хәзрәт арбадан төшеп, атка бераз калач чеметеп каптырган. «Инде Акъегеткә җитәрсең», – дигән, ягъни атка әйткән, һәм дәрвакыйг ат һичбер арыган кәйфиятьтә булмыйча, атлы кешеләр артыннан бер дә калмыйча, Акъегет авылына барып җиткән.

Мәзкүр Хәмид хәзрәтнең вафаты 1845 еллардадыр. Хәзер бу заманда да аның шәкертләре күптер. Бу һәм мөҗәддид[2] замананың берсе булгандыр.

**Каргалы Вәлид ишан бин...** Оренбург якынында Каргалы карьясеннән бер дианәт вә тәкъва вә ишанлык белән мәшһүр булган адәмдер. Кабулда, барып, Фәезхан ишан хәзрәтләренең хезмәтендә тәгълим алып вә хәтме көтеб кыйлып кайткач[3], үзенең шәриге – Арыслан авылының мулла Җәгъфәр дигән адәм белән сәфәр кыйлырга ахуталары булып, әүвәл Кабулга, аннан Истамбулга барганнар. Вә һәм Русиядән килгән адәмнәр дип, солтанга мәгълүм булганнар.

Беркөн боларны солтан чакырткан. Ләкин ул солтан чакыртылган көндә болар вакытына барып җитә алмаганнар. Соңрак калып, боларга солтанханәгә керергә рөхсәт бирмәгәннәр. Болар әйткән: «Без солтанның дәгъвәте белән килдек, керергә рөхсәт биреңез», – дигәннәр. Юк, бирмәгәннәр. Вә һәм болар солтан ишегеннән нәүмиз булып, бу шәһәргә бәла иңсен, дип киткәннәр. Аннан соң берничә көннән ком бураны чыгып, судагы кораблар һәммәсе комда, корыда калган. Халык бик кайгырышканнар. «Кемгә җәберемез җитте?» диешкәннәр. Солтанның сакчылары әйткән: «Беркөн ике мосафир солтанханәгә килделәр. Соңга калдыгыз,

---

[1] Таләбә – гыйлем эстәүчеләр.

[2] Мөҗәддид – яңа.

[3] Хәтме көтеб кыйлып – укуын тәмамлап.

дип, керергә рөхсәт булмады», – дигәннәр. Солтан белгән: бу мосафирлар буш кешеләр түгел икән дип, боларны янә чакырырга җибәргән. Болар бармаганнар. Аннан соң солтан, янә гафу теләп, расписка язып җибәргән, Вәүлид ишан солтанның бу распискасын алып, галә вәҗһ әт-тәкрим[1] башына вә күзенә куеп: «Билгаен вә ррәэс»[2] дип, солтанга барганнар. Солтан болардан гозер теләгән вә һәм болар солтанның гозерен кабул итеп: «Иншаллаһ, элгәрегечә булыр: бу кич урамда һичбер эш булмасын», – дигәннәр.

Ул кич узгач, карасалар, комда утырып, корыда калган кораблар тәмам диңгез эчендә калганнар. Аннан соң Каргалыга кайтып, дәрес әйтеп, күп таләбә җыелган. Утызлап мәдрәсәсе бар иде, диләр. Сәгыйд хәзрәт Бәрәскәдә дәрес әйткән заманда, Каргалы Вәлид ишан Вәлид хәзрәткә кунак булып килгән булса кирәк. Сәгыйд хәзрәтнең шәкертләре сөйләшкәннәр, Истамбулда кораб комда калдырган ишан килгән. Шырданның Мәнкә мулла ул вакытта Бәрәскәдә Сәгыйд хәзрәттә укыйдыр икән, ул сөйли торган иде. Янә моннан башка һәм кәрамәтләре бар иде, диләр. Үзеннән садыр булган бәгъзе кәрамәтләре һәм булгандыр. Мулла Иленең Вәлид ишан риваять кыйлыр икән: Каргалы Вәлид хәзрәтләре… Каргалы Вәлид ишан хаҗ китеп, юлда күп кәрамәтләре күренгәч, үзенең гасырдаш адәмнәрдән монда гафел булып яки хафалану тойгысы белән калган кешеләр бу бәетне инша кыйлганнар.

Мескин бәгъзеләр егълаштылар,
Бу егълашмакта ни мәгънә бар?!
Күр улдык дип үкенешерләр.

Мәзкүр Вәлид ишан шул сәфәрендә Мәккәдә вафат булып, Янбагтта дәфен кыйлганнар.

---

1 Галә вәҗһ әт-тәкрим – хөрмәт йөзеннән.

2 Билгаен вә ррәэс – баш өсте.

**Шәмсетдин бин Шәмсуар әл-Кастромави.** Мәрхүм мулла Шәмсетдин Сәгыйд хәзрәтнең пишкадәм шәкерте булып, Әхмәд хәзрәт заманасында да мәдрәсәдән чыкмыйча мөкәррәр булып дәрес әйтеп гомер итте. Әхмәд хәзрәт мәрхүмнең пишкадәм шәкертләреннән һич Шәмсетдин муллага шәкерт булмаганы юк иде. Гаять мөхәкъкыйк вә мөдәкъкыйк адәм иде. Язуга бик оста иде. Эче-тышы әхлак хәмидә белән тулган иде. Зиядә мөтәшәрригъ вә мөтәдәйин адәм иде. Дәресе вә сүзе бик әсәрле иде. Тып-томал габи булмаган шәкерт аның дәресеннән һичбер истифадә кылмый калмас иде. Хосусән фикъһе гыйльмендә сабак үгрәткәндә шәкертләре күп мөнтәфигъ[1] булыр иде. Аннан дәрес үгрәнгән адәмнәрдән (Габбас хәзрәт) һич кайсы адәмлектән чыгып, җуялып йөргәне юктыр. Хәтта кечкенә балалар, төрки китап укучы балаларга чаклы, ихлас белән вә игътибар белән укытыр иде. Вә әйтәдер иде: «Мин төркичә китаплардан дәрес укыткан кешене мулла дип әйтәм», – ди иде. һәм бик хак сүздер. Мәдрәсә күршесе ишегалдына салган бер кечерәк йорты бар иде. Актык гомеренә чаклы кич саен мәдрәсәгә кереп, төн уртасына чаклы сабак үгрәтер иде вә шөгыльләнер иде. Вә һәм зиядә купшы адәм иде, киемнең нәфисен кияр иде. Вә күп вакытны сары читек кияр иде. [...] Бу адәм – һәм мөҗәддид каимнең берседер. Вәладәте[2] 1790 елларда булып, вафаты 1848 елда иде. Ваба зәхмәте белән вафат булды.

**Күшәр Габбас хәзрәт бин (Габдерәшид).** Голямаи гасырның мәшһүрләреннәндер. Шөһрәтенә сәбәп гәрчә тәгълиме гыйлем вә дәрес булмаса да, әманәт вә тәшригъта риясыз вә прастуйлык белән мәшһүрдер. Аслан дөньяга катышмас. Вә илтифат иткән иң якын вә дус кешесе Кышкар Муса бай булгандыр. Вә ул Муса бай һәр хосуста Габбас хәзрәтнең ярдәмчесе икән, һәр эшен Муса бай карар икән. Бөтен гомеренчә яшел чәй эчәр икән, һәрзаман яшел чәйне Муса бай җибәрер икән. Яки Габбас

[1] Мөнтәфигъ – файда күрүче.

[2] Вәладәте – тууы.

хәзрәтнең үзе бер табак кәгазьнең дүрт почмагына сүз язып, чәй сорар икән. Мәсәлән, бер почмагына «Муса бай», икенче почмагына «сәлам», өченче почмагына «бер кадак», дүртенче почмагына «яшел чәй» дип язар икән. Гомерендә ыштан кимәгән, сач кистермәгән, тырнак кисмәгән вә самаварын гомер дә агартмаган. Самавары чуен кебек булып беткән, диләр иде. Кунак килсә, кунакның кулыннан тотып, самаварга ишарәт кыйлыр икән. Күмергә, суга вә һәм гайре әсбабына ишарәт кыйлыр икән, тел белән әйтмәс икән. Вә һәм чәен кунакның үз кулына бирер икән. Вә һәм ярты пот бал бармы, бер пот бал бармы, кисмәк белән китереп куяр икән. Бер-бер җиргә ат белән барганда күпер очраса, аттан төшеп, күпердән чыгар икән. «Ник алай?» – дигәч, «Бәндә ясаган нәрсә», – ди икән. 1850 елда вафат.

**Мелла Фәтхулла бин Хөсәен Оруви.** Бу Фәтхулла хәзрәт Орыда имам булып дәрес әйтеп торгандыр. Русиядә голямаи исламдан бер мөхәкъкыйк галим, кямил адәм булгандыр. Әшрабә бабында берничә рисаләсе бар. Бер рисаләсе бар төркичә. Ибтидасы ошбудыр: «Бу мәсьәләдә өммәэ ханәфиядәнмен вә җәһин сурылыр Али ахир». Янә бер рисаләсе бардыр әшрабә хосусында. Гарәпчә. [...] Янә моннан башка бер рисаләсе бар, төркичә, «Тәварихе хисабия» дигән. Рисаләдә: «Хәзрәти Расүл Болгарга өч сәхабә җибәрде» дигән сүзне рәд вә могарәзә[1] кыйлып язгандыр. Вафат 1843 елда, майдадыр. Вә дәхи «Фи мәгърифәтел кальбия» дигән бер рисаләсе бар. Вә дәхи гошер хосусында бер рисаләсе бардыр. [...] Төрек телендә, бик дәлилле бер хуб рисаләдер. Вә һәм шәкәрнең хәлялияте вә хәрамияте хосусында бер рисаләсе бар.

**Мулла Габденнасыйр Хөсәен углы.** Казан губернасында үткән голямаларның берседер. Зөя өязендә Шырдан авылында тугандыр. 1790

1 Могарәзә кыйлып – каршы чыгып.

елда. Вафаты һәм Шырдандадыр. 1872 елда вафат булмыштыр. Мәчкәрәдә тәгълим алгандыр. Вә һәм Казанда Сәгыйд хәзрәттә дәрес укыган адәмдер. Зөядә мөтәшәрригь вә мөтәдәйин адәм иде. Курса Габденнасыйр мулла мәзһәбендә иде. Ягъни иҗтиһад заманы (мөнкариз) дигән адәмнәргә күп рәгым кыйлыр[1] иде. һәм бу хосуста кечерәк-кечерәк берничә рисаләләре бар. Вә моннан гайре хосусларда һәм күп тәхрирләре бардыр. Җөмләдән берсе – гавам халкы арасында сабантуй ясап, ат чаптыру хосусында. [...]

Вә дәхи мулла Габденнасыйрның тәхрире. [...] Вә янә Сәнаинең «Тәбакат әл-хаҗәт» дигән рисаләсенә каршы язган бер кечерәк рисаләсе бар. Моннан башка берничә кечерәк рисаләләре бар. Гыйша хосусында, тәравих хосусында вә гайреләре. Мәзкүр Габденнасыйр мулла үзенең заманасында гайяр вә үткен адәм иде. Рус халкыннан олугларга күп якынлыгы бар иде. Вә һәм аларның телен яхшы белгәндер. Татар телендә тәрҗемә кыйлынмыш «Казан тәварихы» бардыр.

**Габделкәрим хәзрәт бин Мөхәммәдрәхим.** Казанның байлар мәсҗете димәкләр, мәгърур сәмҗедендә имам һәм мөдәррис иде. Гаҗаиб дианәтле вә мөтәшәрригъ адәм иде. Заманасында Казан шәһәрендә аның мәдрәсәсеннән олуг мәдрәсә юк иде. Ягъни шәкерт күплеге вә һәм дәресенең кувәтлелеге җәһәтеннән. Дәрескә вә шәкертләргә бик строга адәм иде. Аның заманасында шәкертләр аслан шалит итәргә вә мутлашырга базмаслар иде. Әгәр бер-бер шәкертнең мутлыгын вә шаярганын сизсә, хөкеме бик каты иде. Әүвәл ул шәкертне туйганчы вә таяк тетелеп беткәнче кыйнар иде. Аннан соң мәдрәсәсеннән куып чыгарыр иде.

*Каюм Насыйри,*

*«Сайланма әсәрләр» китабыннан*

*ТКН, 2006*

---

1 Рәгым кыйлыр – үртәнә, ярсый.

# Алуши-Ибраһимов Ризван

## (1883-1938)

Сарытау губернасы Кузнецк өязе (хәзерге Пенза өлкәсенең Неверкин районы) Биги авылында туа. Башлангыч белемне үз авылында ала. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте (1896-1903), шәкертләрнең «Иттихад» яшерен җәмгыяте әгъзасы, кулъязма «Әл-Мәгариф» газетасы сәркатибе, «Әл-ислах» комитеты әгъзасы. Казан губернасы Ташбилге авылында (Татарстанның хәзерге Әлки районы) (1903), Себердә Ачинск (1903-1905), Чита (1907-1912), Хабаровск (1912-1914), Чиләбе (1915-1917) мәдрәсәләрендә укытучы. Эстерлетамакта «Мәгариф эшләре» журналын оештыручы (1920), «Башкортстан кооператоры» журналы мөхәррире (1922-1924). Мәгариф халык комиссариатының әдәбият-нәшрият бүлеге мөдире, Свердловск педагогия институты каршындагы Татар-башкорт рабфагы (1932-1934), Уфа театр техникумы укытучысы (1934-1938).

Фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре: уку-укыту, тәрбия, сәнгать, әдәбият мәсьәләләре; Себер мәктәпләренең тарихы.

Төп хезмәтләре: Мөгаллимләрә дәгъва // Казан мөхбире. – 1906. – № 103; Мәктәпләрдә тәрбия бәдәния илә тәрбия рухия // Шура. – 1911. – № 8. – Б. 246-247; Намаз башка, гимнастика башка (җавап) // Шура. – 1911. – № 15. – Б. 464-465; Себердә ир вә кыз балалар бергә укый торган мәктәп // Сибирия. – 1912. – 27 май. – № 14. – Б. 1; Җәйге экскурсияләрдә мөгаллим вә мөгаллимәләргә юлбашчы. – Эстәрлетамак, 1921. – 30 б.

Аның турында: Әмирхан Ф. Әсәрләр. – Т. 4. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 221-240, 249, 255-256, 261-266, 272, 274, 276, 283, 289; Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 217; Татарская

энциклопедия. Т. 1. – Казань: ИТЭ, 2002. – С. 120; Ибраһимова Ф. Ризван Алуши / Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. – Казан, 2005. – Б. 14-17.

## Мәктәпләрдә тәрбия бәдәния илә тәрбия рухия

[…] Башка милләтләрнең мәктәпләрендә тәрбия бәдәния әсас тотылдыгыннан, балалары сәламәтлек тазалык алып чыкдыклары хәлдә, бездә тәрбиясезлектән шәкертләр саргаеп, бөкрәеп чыгалар. Башкаларда тәрбия рухия васитасы илә балаларның калебендә яшьтән миллият орлыклары чәчеп урнаштырып калдырдыклары хәлдә, безнең шәкертләр мәктәптән бизеп, ялкып чыгалар. Мөгаллим өстендәге вазифаларның иң әүвәлгесе – балаларның тәрбия бәдәниясе илә тәрбия рухияларына дикъкать итүдер.

Тәрбия бәдәниядән берсе: мәктәпнең һавасы балаларга җитәрлек булу, тузан вә һаваны боза торган ислардән пакъ булуы, эссесе вә суыклыгы, якты вә караңгылыгы тыйб кушуына муафикъ булуы өстенә, балаларның хәленә, тәхмиленә *(йөкләмәсенә – Авт.)* муафикъ булу илә зарури эшләрдәндер […]

Икенчесе: риязыят, бәдәният исемендә булып, баланың нәшү вә нәмасенә (үсеше һәм җитлегүенә) сәбәп улыначак уен вә гимнастик иҗраэ итмәктер *(үтәү – Авт.)* […] Гимнастик әгъзаларны куәтләндерә һәм берләштерә, канның һәр катына сәбәп булып, җиңеләйтә вә сәламәтләндерә. Әгъзаларның сәламәт булуы гакылның куәтләнүенә вә зиһеннең артуына хезмәт итдекеннән, гимнастик хәзерендә фән вә һөнәр сөррәсенә *(үзәгенә – Авт.)* кереп гомумиләшмештер. […]

Гимнастик безнең мәктәпләр өчен дә лязем, ләкин аны яхшы белү кирәк буладыр. Кәвагыйд илә иҗраэ ителдектә, хисапсыз файдалары улдыкы хәлдә, белер-белмәс кылындыкта зарары да бардыр. Мәсәлән, гимнастикны ач карынга кылу, яки аш артыннан ук кылу, арган вә хәлсез көе

иҗраэ итү, урынсыз акрынлык, урынсыз сөргәт *(тизлек – Авт.)* барда зарарга саналалар.

Балаларга гимнастик өйрәтергә теләгән мөгаллим, русча яки төрекчә язылган рәсемле рисаләләрдән өйрәнә булыр. Иске төрек педагоглары вә аларга җөзафан *(артык – Авт.)* тәкълид итүче *(ияргүче – Авт.)* Русия мәдрәсәләре «гимнастик кирәк түгел, аның урнына бездә намаз бар, биш вакыт намаз, көндә биш мәртәбә гимнастик урынына тора» диләр, бу дөрес түгел. Чөнки гимнастик, махсус кагыйдәләре илә иҗраэ ителсә генә, файдалыдыр. Намазда аның кагыйдәләрен җиренә китерү мөмкин түгел. Икенчедән, намаз Ходайга махсус гыйбадәт улдыгыннан, аны бер уен урынында күстәрү баланың күңелендә мөкаддәс булган гыйбадәткә кечкенә карау хисне оегатым ихласны киметәдер.

Тәрбия рухия баланың күңелендә милли рух җирләштерә, рух вә гакыл куәтләндерә торган таразда булырга тиешледер. Бу исә зиһенне ача вә күңелне күтәрә торган аңлынчалар өстенә милли тарих вә милли хикәятләр, милли җырулар вә милли көйләргә салып тернем-тагны иттерү (әйттерү) илә хасыйл буладыр [...]

Җыр, аңлатырлык булып, аваз-хиварга салынып укытылса, баланың күңелен нечкәртә, зиһенне раушанландыру *(сафландыру – Авт.)* өстенә милли хис уяндырырга сәбәп буладыр.

Хивар илә шигырьләр әйттерү башкаларда дәрес программына кереп, шуңа махсус мөгаллимләр бар. Бу борын заманда бездә дә бар иде, ләкин тәрәкъкый итмәде. «Мөхәммәдия», «Йосыф китабы», «Бакырган»нан узмады. Ысулы җәдид мәктәпләре аны да бетереп, аңлар урнына һәфтәдә бер мәртәбә «әс-Сабах бәдән», «Вәйс әл-Карани» мөнәҗәтләре иттерү илә кифаяләнер булдылар *(канәгатьләнделәр – Авт.)*. Ләкин болар ни мәгънә җәһәтеннән вә нә дә көй җәһәтеннән балага үз түгел, һәм күңеленә ятышсыз булып бер төрле дә әсәр бирми.

Җырларны, балаларның аңлавына карап, шигырь мәҗмугаларыннан интихаб итәргә (сайлап алырга – Авт.) вә аларны алай һәфтәгә *(атнага – Авт.)* бер генә түгел, бәлки программага кертеп, ике-өч дәфга *(тапкыр – Авт.)* ясарга тиешле.

Шигырьдә күңелгә тәэсир иттерә торган нәрсә – көе илә мәгънәседер. Көй дигәч тә, «Персидский марш» яки «Габделхәмид маршлары» түгел, бәлки баланың мәнсуб *(караш – Авт.)* булдыгы, милләтнең рухында булып тарихирак булуы лязем. Бездә искедән шигырь укыту гадәт улдыгыннан, аны гавамда чит күрәчәк түгел. Эштә әллә нинди русча катыш көйләргә караганда, үзебезнең иске һәм тарихи көйләребездән булган «Сакмар», «Ашказар»... кебиләрне кабул итү артыграк булса кирәк.

Һәр мөгаллим сахибе саут *(тавыш иясе – Авт.)* булмый һәм аңар аерым мөгаллим тәгаен итү ихтималы да бездә әле ерак. Моны исә авылларда аны белүчеләрдән вә шәһәрләрдә граммофонлар васитасы *(ярдәме – Авт.*) илә өйрәнергә мөмкин. (Б. 246-247)

## Себердә ир вә кыз балалар бергә укый торган мәктәп

Эчке Себернең шәһәр вә авылларында тора торган мөселманнарның бик азы гына үз ихтыярлары илә Себергә килгән булып, калган күбрәк кыйсымы берәр җинаять сәбәбле сөрелгән поселенецлардыр. Бу соңгы сыйныф Себернең бик күп шәһәр вә авылларына таралмышдыр.

Бу мөселманнарның шәһәрләрдә торып калганнары, бер дәрәҗә ару яшәсәләр дә, авыллардагылары бик кызганыч хәлдәдерләр. Балалары, уку вә әдәб исламия өйрәнүдән мәхрүм булып, чат рус арасында үсә иделәр.

Кирәк авылдагы, кирәк шәһәрдәгеләре булсын: үзләренең тормышларыннан риза түгелләр иде. Бу кызганыч хәлгә җәһаләт (наданлык – Авт.) сәбәбле дучар улдыкларын беләләр. Балаларның да үзләре кеби булып калуларыннан куркып, анларның укып мәгарифле булуларын телиләр иде. Уку вә гыйлемгә сусадыкларыннан ярый-ярамый, кадим, җәдид дию кар-

шы низаг чыгару асыл сибириялеләрдә аз булды. Том һәм Томга ияргән бәгъзе бер җирлеләрне истисна кылганда *(аерганда – Авт.)*, Себердә укытуга каршы тору юк диярлекдер.

Әүвәлләре бу бичаралар, гыйлемгә бигрәк интеккәннәр, бер аять өйрәнергә, бер кечкенә генә мәсьәлә сорарга да укыган кеше таба алмаганнар. Бөек Себер тимер юлы салыну бу мөселманнарның хәлен җиңеләйтте. Укыган кешеләр, шәкерт вә мөгаллимнәр Себергә килә башладылар. Хәзер күп җирдә рәсми вә гайре рәсми мәктәпләр бар. Бу мәктәпләрдә ир вә кыз балалар бәрабәр укыйлар. Мин, Себер мөгаллим вә мөгаллимәләрнең тәрҗемәи хәлләрен язарга керешү сәбәбле, аны тикшердем, Себердәге кырык кадәр ысулы җәдидә мәктәпнең бары 4-5 кадәрендә генә кыз балалар аерым укып, калганнарының ир вә кыз балалар катыш укыйлар. Бу ир вә кыз балаларны бәрабәр укыту Русиядә булса, әллә никадәр низам вә гаугаларга, сүгеш вә язынуларга сәбәб булыр иде. Себердә бу ысулның бер дә тавыш-тынсыз гына кабул ителеп иҗраэ кылыну сибириялеләрнең гаять гыйлемгә сусадыкларына ачык дәлилләр.

Гыйлем иргә, хатынга фарыз, моны һәркем белә. Һәм дә дөньяда яшәр өчен иргә, хатынга гыйлем өйрәнү тиеш идекен һәркем икърар итә *(таный – Ред)*. Бу хәзер үтәлә, һәр җирдә мәктәпләр бар, мөгаллимнәр бар, ир балалар шау итеп килеп укып торалар. Ә кызларны ни эшләргә, аларны укытыр өчен Русиядә дарелмөгаллимат ачылып, шуннан укып чыккан мөгаллимәләрне көтәргәме? Бу, әлбәттә, тиеш түгел. Бәлки, каян булса да укырга кирәк, өйрәнергә кирәк. Сибириялеләр гыйлемгә ихласлары саясендә *(нәтиҗәсендә – Авт.)*, бу мәсьәләне җиңел хәл итеп, кыз балаларын да ир балалары кеби күреп, ирләр мәктәбенә җибәреп, ир мөгаллимнән укытыр булдылар. Бу ысул 1905 нче сәнәдә Енисей губернасы Ачинск шәһәрендә башланып, тиз арада гомумиләште. Башкаларга гүзәл нәмунә *(үрнәк – Авт.)* булды.

Себер мөселманнары бу ысул аркасында өсләренә фарыз булган бала укыту бурычын әда итәләр *(үтиләр – Авт.)*. Аның өстенә һәр ел 3-5 йөз сум экономия ясыйлар. Чөнки Себердә мөгаллим вә мөгаллимә татар өчен һәр каюсына әкалль *(азрак – Авт.)* 4 йөз сум еллык вазыйфа бирергә кирәк була. Бу ибтидаи дәрәҗәсендәге ир вә кыз балаларны бәрабәр укыту ысулы, Төркиядә һәм Русиядә күп җирләрдә күптән кабул ителгән. Моның саясендә, балалар бер-берләреннән көнләшеп укып, алга китәләр. Моның саясендә кызлар ирләргә, ирләр кызларга адәм диеп кенә карарга өйрәнәләр. Шуның өчен бу балалар да теге кызны күрсә идек, я теге егет илә сөйләшсә идек арзусы *(теләге – Авт.)* бетә. Исе китми. Бу ысул балаларның күркәм холыклы булуларына да зур сәбәб була. Шуның өчен сибириялеләрнең уку юлындагы бу тәрәкъкыйләре шаян тәхсин *(мактауга лаек – Авт.)* вә башка җирләргә гүзәл нәмунәдер.

*Резедә Сәфиуллина–Әл-Әнси ,*
*КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр,*
*тарих һәм шәрыкне өйрәнү институтының*
*«Язма мирас һәм археография» фәнни-мәгариф үзәге җитәкчесе,*
*Россия ислам институты доценты, филология фәннәре кандидаты*

# Тарих

# Дүрт ягым кыйбла: Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

*(Дәвамы. Башы журналның 16 нчы санында)*

## III

28 июнь көнне Кенәр авылы аша Кызылъярга киттек. Яңа һәм Кече кенәр авыллары инде кушылып беткән. Авыл шулай зурайган. Олы мәктәп, яхшы итеп эшләнелгән мәдәният йорты бар. Матур, кызыл, ак кирпечле төзек биналар. Халыкның тырышлыгы да, уңганлыгы да күренеп тора. Кышын мәктәпләренә дә, китапханәләренә дә очрашуларга чакырачакларын әйткәч, бераз шикләнеп тә куйдым: мин Арча яклары хакында нәрсә сөйли алырмын икән? Китапларымны укыган булсалар инде...

Кызылъяр авылына юл алдык. Кәүсәрия абыстайга барырга куштылар. Анда борынгы китаплар бар икән. Ул хәзер Тәнзилә әбиләрдә яши, ди. Үз өе дә монда гына. Китапларын шунда, диләр. Аннары, Айсылу ханым Галимҗановада «Коръән тәфсире», Габделхәй Тракторчыда әби-бабайдан калган борынгы китаплар күп, имеш. Ул алар хакында иптәшләренә кибет буенда мактанып сөйләп торган әле, җитмәсә.

Көн нигәдер салкынча, җилле һәм авыр кебек тоела иде. Әллә авыллары калкурак җирдә булгангамы? Салкын җил изү һәм җиңнәрдән тәнгә уза. Агачларның башларын идереп газаплый. Хәтта Зират агачлары да авыр сулап ыңгырашып куйгандай итәләр.

Кызылъярлар безне алтын эзләп йөрүче чегәннәргәме тиңләделәр? Сүзләре һаман да эредән йөрде. Болар, мөгаен, иске байлар авылы булгандыр? Кемгә барып керсәң дә, күңелне тардан тотып, коры сүзне мул яудырып, зиһенне кысрыклап тоту ягын карыйлар. Ихаталары – ныклы. Заманча бар да. Машиналы, мал-туарлы болар. Барысы да яхшы, югыйсә.

Әмма күңелләрендә тынычлык, бәхет тойгысы юк. Мәчетләре дә буш тора. Анда намаз укыгач, юлыбызны дәвам иттек.

Арча ягындагы иң борынгы авылларның берсенә – Түбән Орыга килдек. Монда XVII гасырда, үз заманында акылы, зиһене, галимлеге белән танылып, тарихыбызда эз калдырган шәхесләребездән Бисары улы Янсары-хафиз яшәп, 1687 елда вафат булган. Аның бабасы – Килдеш бәк, ә ул – Килеваз («Калавыз» түгел) бәкнең улы икән.

Оры авылы зиратында булып, аның кабер ташын укыганлыгы хакында Риза Фәхретдинов «Асар» китабында язып уза. Янсары-хафизның Ючәнәһам исемле кызы Иванай улы Юныска никахлы икәнлеген дә ачыклый. Янсариның «хафиз» аталуы мәсьәләсенә тукталып, бу сүзнең мәгънәләрен төрле яклап тикшерә, керәшеннәрдә поп-атакайны да «хафиз» дип атауларына игътибарын юнәлтә, «абыз, абыстай» сүзләренең дә менә шушы «хафиз»га бәйле ясалуын ача.

Иванай улы Юныска килгәндә, ул үз заманында шөһрәтле имам һәм мөдәррис булып җитлегә. Оры авылында зур мәдрәсә тота, балалар укыту белән шөгыльләнә. Аны «Юныс әфәнде», «Юныс ахун» дип атап йөрткәннәр. Бабасы Усай исемле икән.

Юныс хәзрәтнең әтисе Иванай Кәче авылында имамлык һәм мөдәррислек иткән. Кодасы Янсари-хафиздан соң, бер ел кичеп, 1688 елда вафат була. Казан төбәгендә зур нәсел калдыра.

Иванай мулланың язу эшенә маһирлыгын Р. Фәхретдинов аерым күрсәтә. Ш. Мәрҗани бу нәселдә зур галимнәр булганлыгын үз хезмәтләрендә искә ала.

Юныс хәзрәт 1636 елда туган. Р. Фәхретдиновның язганынча, Казан ханлыгы басып алынганнан соң, Урта Азия якларына китеп, Бохарада белем алып кайткан беренче кеше ул булган. Зур гыйлем туплап, аң-белемдә маһирлыгы белән танылырга өлгерән. Юлда кәрван белән кайтышында, күчмәләр кулына төшеп, аны казакъларның данлыклы ханы мәшһүр Әбул-

Хәйрнең улы Чыңгызхан каршысына китерәләр. Егетнең төс-кыяфәте, күркәм тәрбиясе, тирән белемнәре һәм саф зиһене хан хәзрәтләренең күңелендә мәрхәмәт хисләрен уята. Ул аны үз янында калдыра. Әмма берникадәр вакыттан соң, егетнең сагыш утында көюен күреп, кәефен аулау нияте белән кызы Мәһәлбикә-солтанга өйләндерә. Кыз, әлбәттә, бик тә чибәр икән. Хан баласы, шуңа да «солтан» титулы белән йөртелә.

Әмма Юнысның күңеле барыбер дә туган якларына ашкына. Ватанпәрвәрлек хисләренә бирелгән киявен, Мәһәлбикә-солтан белән бергә, казакълар ханы Чыңгызхан асыл ватанына кайтып килергә җибәрә. Әмма алар монда төпләнеп калалар.

Юныс хәзрәт Оры авылында мәдрәсәдә укыта башлый. Тирән гыйлем иясе булуын истә тотып, аңарга четрекле мәсьәләләрнең берсе – бу мәмләкәттә гошер садакасын җыю тиешлеме-юкмы, шуны раслап чишү эше йөкләнелә. Ул аның ваҗиб, ягъни саваплы икәнлеген дәлилләп фәтва яза. Голамә тарафыннан кабул ителеп, шул фәтвасы соңгы гасыргача үз көчендә кала килә, дини басма китаплар арасында ул хактагы хәбәрләрне очратырга була.

Озакламый Юныс хәзрәтне Оры авылына имам итеп сайлыйлар. Ул мөдәррис, ягъни мәдрәсә профессоры сыйфатында да танылa. Әмма хатыны Мәһәлбикә-солтан вафат була. Аны Оры зиратына җирлиләр.

Юныс ахун икенче хатын алырга ниятли. Аңа Янсари хафизның кызы Ючәнәһамне димлиләр.

Аның белән дә бик тату һәм мәхәббәт тигезлегендә матур яшәгәннәр.

Юныс хәзрәт өч угыл үстергән, исемнәре Нәзер, Сәфәр, Мәкъсүт икән. Болардан шулай ук укымышлы нәселләр таралган.

Фарсы теленә бик оста булып, Юныс хәзрәт күп әсәрләрен шул телдә язган, Иран ягы әдипләренең һәм галимнәренең хезмәтләренә шәрехләр төзегән, үзеннән бай һәм кызыклы гыйльми мирас калдырган. Китапларында үзен «Юныс ахун», «Мулла Юныс», «Юныс бине Иванай Казани» им-

залары белән күрсәткән. Танылган әсәрләреннән берсе – «Шәрхе Габдулла» атала. Соңыннан ул Казанда берничә кат басылган, дини йолаларны үтәү, иман, намаз һәм башка фарызларны башкару хакындагы дәлилле, ышанычлы китаплардан санала.

Татар халкы XIX йөз шагыйре Әбелманих Каргалының тормышы һәм иҗаты хакында яхшы хәбәрдар. Алар хакында мәктәп дәреслекләреннән үк яхшы билгеле. Әмма аның бабалары Арча ягыннан икәнлеген искә дә алмыйбыз. Ул данлыклы шагыйрьләр һәм имамнар нәселеннән чыккан.

Әбелманихның бабасы Габдессәлам – Урай (Уразмөхәммәт) улы. Аның әтисе – Колмөхәммәт, бабасы – Колчура, нәсел башлары Кылап бәктән. Асыллары белән алар Алат юлындагы Мәңгәр авылы кешеләре.

Габдессәлам башта Ташкичү авылына күченә, анда имам-мөдәррис була, зур мәдрәсә тота. Дистә еллар буе Кариле имамы Хәсән улы Габдессәлам ахун мәдрәсәсендә камил белем алуга ирешкәнлеге яхшы мәгълүм. Мәдрәсәдә укыган чагында гарәп теле грамматикасына бәйле хезмәт яза һәм сүзлек төзи. Бу кешенең чыннан да Әбелманих Каргылының бабасы булуын Р. Фәхретдинов «Асар» хезмәтендә ачык дәлилләп яза, фикерен раслауда шагыйрьнең үз сүзләреннән дә файдалана, әсәреннән өзек китерә. Тагын да шунысы әһәмиятле, Габдессәламнең бер кызы Стәрлетамак ягындагы Кырмыскалы авылы имамы Вәлид бине Мәкъсүт бине Афак бине Дусмөхәммәттә кияүдә була. 1744 елда Патшабикә Елизаветта (аны да татарлар «Әби патша» дип атап йөрткәннәр) татар һөнәрчеләренә һәм сәүдәгәрләренә Сакмар елгасы буенда шәһәр төзергә фәрман бирә. Эш башына Казан ягы Саба авылынан курку белмәс Габделхаяли улы Сәгыйть баса, үз тирәсенә гайрәтле, хөр җанлы татарларны туплый. 1750 елда башкалар белән бергә Габдессәлам дә шул якларга күченә, Оренбургта имам һәм мөдәррис була. Аның Ташкичү мәдрәсәсендә укыткан чагында ук шәкертләрен китап язарлык, иркен фикерләрлек дәрәҗәдә

тәрбияли алганлыгын Ш. Мәрҗани тарихи хезмәтләрендә дәлилләп, мисаллар белән искә алган.

Габдессәламнең үз мөгаллиме Хәсән улы Габдессәлам исә асылы белән Уфа ягы кешесе була. Ул Кариле авылына килеп, монда исеме тирә-якка танылган остаз-мөдәррис буларак таныла. Күп кенә шәкертләр тәрбияли. Әмма ир балалары булмау сәбәпле, тәрбиясез калгач, Минзәлә елгасы буендагы Шыгай авылына китә. Монда кызы кияүдә була. Шулай итеп, Шыгай авылында кияүләре Сөләйман улы Мөхәммәтшәрифтә яши, атаклы Шыгай мәдрәсәсендә укыта. Аннары Мәлем авылындагы кияүләре Зәйнетдин йортына күченә. Кабере дә шул Мәлем авылында.

Гали Чокрыйның әнисе Гөлбаһар нәкъ менә шушы нәселдән.

Хәсән улы Габессәлам исә данлыклы Котлыгыш Әс-Семети улы Мортаза әфәндедә белем алган. Ә ул, үз чиратында, Дагыстан якларында укып кайткан, хаҗи да икән. Р. Фәхретдин хәбәренә күрә, 1723 елда Мортаза-хафиз намаз укуга бәйләнешле әһәмиятле гарәпчә китап язган .

Хәсән улы Габдессәлам Курса авылында да белем алган. Ул монда Таип улы Рафыйк мөдәррис мәдрәсәсендә укыган. Шунысы игътибарга лаеклы, имам Рафыйк үзе дә заманында Мортаза-хафизның шәкерте булган.

Габдессәламнең Рафыйк хәзрәткә күчүе мөдәррисенең вафаты сәбәбенә бәйле аңлатыла ала. Ул заманнарда гыйлем ияләре күп булмаган. Рафыйк Курсави бик күп бәхәсләр уяткан мәсьәләләрдән берсе – кыска төннәрдә ястү намазын уку тиешлеге хакында рисалә язган шәхес тә әле.

Бу кешеләр фикер иясе Габденнасыйр Курсави кебек алдынгы карашлы галимнең җитлегеп мәйданга чыгуында зур роль уйнаганнар, билгеле. Габденнасыйр кебек даһиларга бөек халыклар һәйкәлләр куялар, бездә дә андый гамәлләр булырга тиеш иде, югыйсә.

Габденнасыйр Курсавиның әтисе Ибраһим исемле, бабасы – Ярмөхәммәт. Ул Курса авылыннан Иштирәк нәселенең дәвамчысы. Габденнасыйрның улы – Насыйр. Шунлыктан ләкабе, шәригать кысала-

рында, Әбуннасыйр була. Бу исә «Насыйрның әтисе» дигән сүз. Шунлыктан берәүләр аны «Әбуннасыйр Курсави» диләр, икенчеләр «Габденнасыйр Курсави» исеме белән белдерәләр. Бу исә «ике төрле кеше хакында сүз бара булса кирәк» дип уйларга җирлек тудыра. Алар икесе дә бер үк зат, ягъни Насыйрның атасы Габденнасыйр Курсави, югыйсә.

Габденнасыйр Курсавиның әтисе Ибраһим 1790 елда вафат булган. Әнисе – Әмин кызы Миһербан, Максабаш авылы Мансур бай нәселеннән.

Габденнасыйрның апасы Мәрхүбә исемле булган. Мәчкәрә авылыннан Габдессәлам улы Габдуллага кияүгә чыккан, Габденнасыйрны гына түгел, Гобәйдулла, Муса, Мөхәммәтҗан, Хәсәнбану исемле балаларын да үстергән. Р. Фәхретдинов аны «Мәшһүр хатыннар» исемлегенә керткән. Мәрхүбә абыстай 1827 елда вафат булган.

Габденнасыйр Курсави 1776 елда дөньяга килгән. 37 яшендә, 1812 елда, Рамазан аеның соңгы унынчы көнендә вафат булган. «Буның вафат улмасы илә Казан вә Болгар исламнары, бәлки гомумән ислам галәме олуг бер галимнәрене заигъ итмешләрдер», – дип яза шушы хакта белдереп Риза Фәхретдинов[1]. Һәм ул бу очракта да мең өлеш хаклы.

Бала чагында Габденнасыйр, белем алу максатын күздә тотып, туган авылы Курсадан Малмыж ягы Мәчкәрә авылы мәдрәсәсенә китә. Аннары аны гарәп-фарсы телләрен яхшылап үзләштерү теләге Бохарага кадәр китерә. Ул монда батыйни вә заһири гыйлемнәрне, ягъни интуиция һәм тәҗрибә юллары белән хакыйкатьне табу ысулларын, замананың бөек галимнәреннән һәм шәехләреннән өйрәнә, гарәп-фарсы телләрендә камил дәрәҗәдә укырлык, язарлык, иркен аралашырлык дәрәҗәләргә ирешүе белән бергә, мәгънәләргә, ягъни белемнәрнең эчтәлегенә, чын асылына төшенүгә дә ирешә. Бохарада уздырыла торган галим-голамәнең бәхәс мәҗлесләренә йөри. Монда үзенең яхшы зиһен һәм гыйлемнәр иясе булуын, кыен мәсьәләләрне чишә алырлык көчле акылы һәм аңы барлы-

[1] Фәхретдинов Р. Асар. – Өченче кисәк. – Казан: Бертуган Кәримовлар, 1903.-Б.95.

гын күрсәтә. Даны тарала. Хәтта ул килмичә бәхәс мәҗлесләре башланмау очраклары ешая.

Әмма уйланмаган хәлләр килеп чыга. Габденнасыйр Курсави, фикер өлгерлеге һәм хакыйкатьне ачык күрә белүе аркасында җитәкче даирәләрнең «күңелен болгатуы» сәбәпле, алга таба Бохарада кала алмый, үз ватанына кайта. Аңа бай җизнәсе Габделсәлам улы Габдулла олы мәдрәсә салдырып бирә. Габденнасыйр Курсави аны алдынгы карашлы һәм югары белемнәр учагына әверелдерә.

1807 елда ул Бохарага икенче тапкыр китә, анда бераз торгач, кирәкле китапларын кабат укып, күчереп язып, тикшереп-өйрәнеп чыккач, Хива шәһәренә юл ала, монда да китапханәләрдә була. Аннары Әстерханга килә, шуннан соң, Идел буйлап сәяхәт итә-итә, асыл ватанына кайта.

Ә 1812 елда Габденнасыйр Курсави хаҗ сәфәренә кузгала. Алар Казанда җыелышып, аннан Истанбулга киләләр. Әмма Габденнасыйр юлда авырый башлый. Истанбулга барып ирешкәндә авыруы тагын да көчәя һәм ул шунда вафат була. Искедәр бистәсе Солтаннар зиратында җирләнә.

Габденнасыйр Курсави күп төрле остазлардан белем ала. Әмма аларның арасында ике галим аның фикерләре оешуда, күзләре ачылуда төп урынны алып торалар. Аларның беренчесе – Мәчкәрдән имам-мөдәррис Мөхәммәтрәхим булган. Ә Мөхәммәтрәхим үзе Ашыт авылы Йосыф мулланың улы икән. Икенчесе – Бохара шәехе Ниязколый Төрекмәни, Шаһнияз улы. Бу остазы да гаҗәеп зур акыл иясе, фикер чыганагы һәм итагатьле кеше булган.

Габденнасыйр Курсавиның язган китап һәм рисаләләре арасында тугызы бүгенге көндә дә әһәмиятле саналалар. Аларның кайберләре: «Әл-Иршад», «Китабул-ләваих», «Шәрхүл-гакаидүл нисфиятүл кадим», «Шәрхүл-гакаидүл нисфиятүл җәдит», «Рисаләтүл-исбатул-саффат», «Китабул-нәсаих», «Шәрхул-мохтасарул-Манар», «Хашиятүл-гакаидүлҗәдит», «Төрки телендә Һәфтияк шәриф тәфсире». Шушы хезмәтләре

белән ул ислам дөньясын яңа фикерләр белән баету гына түгел, бәлки яшәеш барышын һәм илаһият кануннарын суфичылыктан аралап алып аңлата башлаган бөек галим дә санала.

Габденнасыйр Курсави озын буйлы, киң маңгайлы, куәтле кеше булган. Күзләре туры карашлы һәм олы икәннәр. Башкаларның сорауларына ачык итеп, аңлатып җавап бирүчән, ә сөйләшүе – туры сүзле, төгәл, матур. Үткенлеге белән сокландырган да, куркуга да салган. Табигатеннән үк укымышлы кеше икәнлеге күренеп торган. Гәүдәгә – арык, холыкта – сабыр, акылы – камил, фикерләре – дөрес, нәсыйхәтләре – яңача, кабатланмас сурәттә үтемле һәм дәлилле, зиһене – ачык һәм тугыры, әйткәннәрендә матур гыйбәрәтләр һәм чагыштыру-ишарәләр күп булып, сүзләре үзе белән сөйләшүчеләрнең күңеленә рәхәтлек белән йогучан булганнар. Мәгърур һәм вәкарьле дә икән әле, җитмәсә. Һәмма бу сыйфатлары аңа карата башкаларда хөрмәт, олылау хисе уяткан, әмма көнчелекле кешеләрдә дошманлык хисе дә тудырган. Шунлыктан халык арасында алары да, болары да күп булган. Әмма Әбүннасыйр Курсави боларына бик игътибар итеп тормаган. Олы адәмнрәгә күрсәтелгән ихтирамны аңа кече яшеннән татырга туры килгән.

Мәчкәрә мәдрәсәсендә укыган чагы икән, Габденнасыйрның әтисе үлә. Мөгаллиме Мөхәммәдрәхим хәзрәт аның акыллы, зиһенле һәм аңлы шәкерт булуына соклануын яшерми, укуын дәвам иттерүен сорый. абденнасыйр Курсавиның киләчәктә зур галим буласын башкаларга да яшермичә әйтә килә. Аның үсеп, зур галим мәртәбәсен алуын халыкта өмет итә башлыйлар. Бу хакта Ш.Мәрҗани үз хезмәтләрендә соклanып искә ала, хәтта халкыбыз эчендә чын галимнәрне аера һәм күрә белүчеләрнең барлыгына куана.

Габденнасыйрга иптәшләре дә, тормышы бермә-бер авырлашса да, укуын ташламаска киңәш итәләр. Һәм ул Бохарага китеп бара, анда да ачлы-туклы гомер кичерә. Әмма гыйлемгә омтыдышын һич кенә дә туктат-

мый. Мәчкәрә мәдрәсәсе шәкерте чагында ук аның фикерле булуы, укыган китапларын тәмам истә калдырулары, дәресләрдә һәм аерым оештырылган гыйльми бәхәсләрдә аларны дәлил итеп сөйләп бирүләре мәртәбәсе үсүгә хезмәт итә, инде яңа сыйфатлары да ачыла. Бохара галимнәрен ул гаҗизлектә калдыра башлый. Иман һәм шәригать мәсьәләләрендә аның ачык һәм аңлы сөйләүләре, замана үзгәрешләре һәм тормыш таләпләре белән бергә һәркайсын янәшә куеп аңлатулары үзләрен белем иясе хисабында йөртүче адәмнәрнең ачуларын китерә һәм алар аның өстенән Бохара әмиренә белдереп хат язалар. Бу вакытта Габденнасыйр Курсави Ниязколый Төрекмәнидә дүрт ел белем алган, аның алдынгы шәкерте хисабында санала башлаган икән. Тагын шунысы да бар, Казан ягыннан килгән шәкертләр андый бәхәс мәҗлесләренә йөрмәү ягын караганнар. Ул утырышлардагы шау-шулар, бер-берсен асылсыз инкарь итүләр, кәфергә чыгарулар бик еш булганлыктан, аның ише урыннардан читтәрәк йөрүне хәерлегә исәпләгәннәр. Әмма Габденнасыйр Курсави бу ише бәхәс мәйданнарына тәҗрибә урыны буларак та караган, аларны хакыйкатьне эзләү өчен уңай урын итеп тә белгән. Әфләтунча фикер йөртүе, акылы, зиһене аны игътикад мәсьәләсендә яңа мәгънәләр табуга китергән.

Бохара әмире махсус мәҗлес җыйдырып, илендәге галимнәрне чакырып, Габденнасыйр Курсавины кәферлектә гаепләгәндә дә бары тик тиран рәвешендә эш иткән, хәтта шәригать таләпләрен дә исәпкә алмаган. Аның ясаган хөкемен һәм дини, һәм тарихи нигездә тикшереп, XX гасыр башында Р. Фәхретдинов бу эшнең ни әмирлек, ни казыйлык ягыннан гадел һәм дөрес башкарылмаганлыгын ачыклап аңлатып язарга мәҗбүр була[1].

Ш.Мәрҗани дә үз чорында, Бохарада укыган вакытларында, «Габденнасыйр эше» белән махсус кызыксына һәм ул вакыйгада катнашкан имам-мөдәррисләрнең соңыннан үкенүләрен, Курсави замандашлары

[1] Фәхретдинов Р. Асар. – Өченче кисәк.-Б.119-121.

арасында аны аңларлык галимнәрнең булмавын искәрүләрен, бу хакта яшерми әйтүләрен хезмәтләрендә хәбәр итә.

Бохарадан Әстерханга килгәч, Габденнасыйр хәтта шыга мәзһәбе галимнәре мәҗлесенә чакырыла. Ул аларны шаккатыра. Һәммә яктан бу мәзһәпнең үзенчәлекләрен ачык аңлатып бирә. Аның белән ярышырлык, фикерләрен инкарь итәрлек галимнәрнең араларында табылмавы аларны борчуга сала.

Габденнасыйр Курсави диндә сәләфләр (сәләфият) юлын өстен куя, әмма аңа да тәмам мөкиббән түгел, тәнкыйди карашы булган шәхес. Моңа Ш. Мәрҗани дә игътибар иткән, ул аны хәтта «биш йөз елга бер туа торган галим» дип атаган. Курсавиның китапларын укыган кешеләр, аның фикерләрен һичбер бәхәссез кабул итеп, тормыш тәртипләрен үзгәрткәннәр, хаталарын төзәткәннәр. Шундыйлардан мисал итеп «Асар»да Р. Фәхретдинов Табул ягыннан Хуҗамбирде исемле галимнең вакыйгасын искә ала[1]. Ул, Г. Курсавиның «Әл-Иршад»ын укыгач, мәсләген үзгәртә, игътикадын яңарта.

Г. Курсави Хивага килгәч, шәһәр башлыгы аңа атап аерым мәҗлес оештырган. Гыйлеменә һәм данына соклануын яшермичә, ике йөз алтын акча биреп, аның иңенә халат салган һәм үзләрендә имам-мөдәррис булып калуын үтенгән. Бу кадәрле олы хөрмәтләр күңелләрне яуларлык дәрәҗәдә күрсәтелсә дә, Габденнасыйр ата йортына кайтырга тиешлеген дөрес мәгънәдә белдерә алган.

Аның Хивага килүен мөгаллиме Ниязколый Төрекмәнигә хөрмәте буларак та аңларга кирәк. Кайда гына бармасын, Г. Курсавиның үз шәхесенә карата көчле соклану хисләрен уятыр дәрәҗәдә бөеклеген танымый мөмкин түгел.

Китапларындагы аңлатмалар, фикер сөреше гаҗәеп дәрәҗәдә җитди рәвештә булып, икеләнерлек урын калдырылмыйлар, фәнни мәгънәләр

[1] Шунда ук.- Б.123.

кысасында язылганнар. Шул сәбәпле кешеләргә тәэсирләре дә көчле. Дини-рухани эчтәлектә, Аллаһыга тугрылык, Мөхәммәд пәйгамбәргә олы хөрмәт, ислам динен саф, бернинди катнашсыз, һәм иң әһәмиятлесе – һәртөрле суфичыл, шагыйранә фикерләрне, әүлияви күрсәтмәләрне читкә кую, аларның асылсыз икәнлекләрен аңлау-аңлату нигезендә язу, яшәү – болар үзләре генә дә ул заман өчен күрелмәгән хәл иделәр. Габденнасыйр Курсави ислам динен хорафи карашлардан арындыру юлын ачты, рухани дөньяның таләпләрен һәм чикләрен дөрес билгеләде. Бу исә халыкны урта гасырчылыктан котылдыру, яңа заманга алып керү иде. Аның алдынгы карашларын татар дөньясы үз вакытында ук кабул итүе халкыбызга карата хөрмәт хисен тагын да ныгыта.

*(Дәвамы бар)*

*Фәрит Яхин, профессор,*
*филология фәннәре докторы*

# «Ислам баласы»

1925 елның феврале. Казан татарлары мөфти Ризаэтдин бин Фәхретдиннең килүен көтә. Аның килүе очраклы булмый. Мөселманнарның дини яшәешендә башлап җибәрүчесе мөфти үзе булган реформалар күзәтелә башлый. Аның тарафдарлары һәм хатын-кызларның мәчеткә йөрүен тыю, догаларны гарәпчә генә кылу, Коръән тәфсирләрен һәм башка күп әйберне тыю кебек диннең тышкы атрибутларын нык саклаучылар арасында әледән әле бәхәсләр туып тора. Эш шуңа таба бара: ортодоксаль карашлылар бәйсез Диния нәзарәте булдыру турында сүз кузгата. Мөфтинең Казанга килүе республика җитәкчелегенең Үзәк Башкарма Комитет (ЦИК) карарына каршы килгән рәвештә балаларга дини белем бирү һәм руханиларны әзерләү мәсьәләләрендә киртәләр коруына да бәйле була.

Ризаэтдин бин Фәхретдин Казанга 20 февраль көнне килә. Шушы көннәрдә Галиев мәдрәсәсенең элеккеге бинасында урнашкан Вахитов исемендәге мәктәптә Исхак Закиров исемле унбиш яшьлек укучы яшьтәшләренә үзе чыгарган «Яшь динче» кульъязма газетасын тәкъдим итә. Анда ул дини тематикага үзе язган шигырен, дөньяви характердагы башка материаллар, М. Акчуринның «Сөембикә ханбикә һәм аның улы Үтәмеш» хикәясен, башваткычлар, юмористик хикәяләр, Уфада яңа гына чыккан «Ислам» журналыннан материаллар урнаштыра. «Яшь динче» гади укучы дәфтәре рәвешендә була. Исхак материалларны энесе Госман ярдәме белән әзерли. Бер айдан соң алар журналның Габдуллаһ Тукай истәлегенә багышланган тагы бер санын чыгара. Баш биттә Исхак халык шагыйренең портретын ясый. Беренче сандагы кебек үк, монсында да дини тематикага караган материаллар да урнаштырыла. «Рамазан» шигыре ураза аена багышланган була. Анда Аллаһы Тәгаләнең рәхимлегенә

дан җырланып, ураза тотарга өндәү була. Тышлыкта «Рамазан ае мөбарәк булсын!» дип язылган була.

Илдә партия күрсәтмәләре буенча дингә каршы көрәш башланганда, яшь «дин каһарманнары»н нәрсә рухландыра? Бар басмалар дәүләтнең сугышчан атеизм сәясәтен хуплый. Эшчеләр клубларында нәтиҗәсе алдан ук билгеле булган диспутлар оештырыла. Яшь атеист комсомоллар динне яклап чыгыш ясаучыларның чыгышларын махсус боза. Мондый вәзгыятьтә мөселман руханиларының бу чараларда катнашырга баш тартуы гаҗәп түгел. Әмма хакыйкатьне эзләргә омтылучы яшьләр да булган. Алар арасында дини гаиләдә үскән Исхак Закиров та була. Ул матбугатта «дин белгечләре»нең, Коръәнне белми торып, аңа ирекле рәвештә тәфсир кылуларын, мәчетләргә йөргәннәре өчен генә татар зыялыларыннан көлүләрне, Исламның дәүләт мәнфәгатьләренә капма-каршы куелуын күрә. Журналны чыгару Исхакның үз фикерен ачык рәвештә әйтеп, аны яшьтәшләренә җиткерү омтылышы була. Аллаһы Тәгалә аңа сизгер һәм ярдәмчел йөрәк һәм Коръән нигезендә әти-әниләре тәрбияләгән яхшы сыйфатлар бирә. Журналының беренче санында «Әти һәм әни бриллианттан кыйммәтлерәк» шигырен очраклы гына урнаштырмый ул. Журналның беренче ике саны Исхак көткән кызыксыну уята алмый, әмма бу аның күңелен төшерми, һәм ул яшьтәшләре, яшьләр белән бергәлектә чыгарылачак журнал булдыру турында карар кабул итә. Бу фикерне Вахитов исемендәге мәктәпнең шәкертләре Гомәр Габитов, Зөфәр Габдуллин, Габделхак Сәгыев, Г. Тукай исемендәге 9 санлы мәктәпнең укучылары Хәмид Шакиров һәм Әнвәр Исламов хуплап чыга. 1925 елның май аеннан журнал «Ислам баласы» исеме астында чыга башый. Беренче коллектив санда дини характердагы материаллардан тыш, Г. Габитовның «Таткино» мәкаләсе урнаштырыла. Мәкаләсендә автор бу яңа оешманың барлыкка килүен энтузиазм белән кабул итә, шул ук вакытта фильмның хәтта титрлары рус телендә булуын үкенеч белән искәртә. Бу санда ук «Ислам» жур-

налына язылу башлануы һәм Крым руханиларының «Гасры мөселманлык» журналын чыгара башлавы турында мәгълүмат урнаштырыла. Киләсе санда Г. Габитов «Дин тәгълиматы башлангычы» мәкаләсен урнаштыра. Мәкаләсендә ул яшьләрне Ислам динен өйрәнергә һәм аның кануннарын тотарга өнди. Мәчетләрдә балаларны укыту башлануы Гомәрне киләсе санга «Зур сөенеч» дип аталган кыска гына мәкалә язарга рухландыра. Монда ук аның татар милләтен уяныргa, уйланырга һәм эш башларга өндәгән «Тормыш юлында» дип аталган шигыре урнаштырыла. Үзе ул милләт мәнфәгатьләре хакына авырлыклар алдында туктап калмаска әзер булуын әйтә. Журналның 1926 елның февралендә чыккан 13 нче санында Исхак Закиров Пермьдә мөселман театры ачылуы, аның керемнәре мәчет тотуга баруы, Пермь һәм Мәскәүдә хатын-кызларга мәчетләргә йөрергә рөхсәт ителүе турында сөенеп яза. Казанда яңа төзелгән мәчет манарасына ярымай урнаштырылуы уңаеннан, Исхак журналның октябрь санында бу вакыйгага бәйле чаралар турында һәм яңа мәчеткә материаль ярдәм күрсәтергә чакырган мәкалә урнаштыра.

Декабрь санында Казан мөселманнарының Мәккәгә Ислам конгрессына баруы турында кыска мәкалә урнаштырыла. Яшь авторлар татар җәмгыятендә гарәп әлифбасыннан латинга күчүгә бәйле башланган процессларны күзәтеп барган. Саннарның берсендә Габитов Бакуда узган төрки съезд нәтиҗәләре турында мәкалә урнаштыра. Ул яңалифкә каршы чыккан татар делегациясен яклап чыга. Яңа әлифбаны кертүгә каршы булган иң мөһим сәбәпләр арасында, Габитов гарәп имлясендә язылган төрки-татар әдәбиятының онытылуын атый. Автор яңа әлифбаны мөмкин кадәр тизрәк кертү яклы булган Фатыйх Сәйфи эшчәнлеген тискәре бәяли һәм Галимҗан Ибраһимов белән Гыйбәд Алпаров фикерләрен хуплый. Г. Ибраһимовның атеист булуына карамастан, яшь авторлар аның татар мәдәнияте өчен күрсәткән бәяләп бетергесез хезмәтен таный. Барлык мәкаләләрендә дә авторлар теге яки бу шәхесне ышанулары буенча

түгел, ә милли мәдәнияткә керткән өлеше һәм әхлакый сыйфатлары буенча бәяли. Монда эчкечелек өчен вазифасыннан алынган, ә соңыннан материаль иминлеген кайгыртып республиканың үзәк динсезләр шурасына кереп, дингә каршы пропаганда алып барган Арча кантоны мулласы Ш. Хәмиди турында әйтеп китәргә мөмкин. Журнал авторларының иң өлкән яшьтәгесе Зөфәр Габдуллин «Журналның киләчәге» мәкаләсендә: «Журналның динне яклау һәм динсезләр тарафыннан бәйләнүләргә каршы тору бурычы бик авыр, иң югары хезмәт кую һәм чыгымнарны таләп итә. Бу безнең бурычыбыз», – дип яза. Киләсе «Хакыйкать кемдә?» мәкаләсендә ул, Казанда булган ике дингә каршы диспут турында хәбәр итеп, атеистларның уңышын аларның үзләренә кирәкле президиум сайлап, уңайлы шартлар булдырулары белән аңлата. Һәм гомумән үзләрен намуссыз тотулары белән. Ул шушы саннан башлап, журналның дингә каршы пропагандага активрак каршы торырга тиешлеген ассызыклый. Чыннан да, 28 нче саннан башлап, журналның эчтәлеге үзгәрә. Әдәби һәм кайвакыт балаларча беркатлы мәкаләләрдән авторлар дини характерлы эчтәлеклерәк язмаларга күчә, шулай ук Казан мөхтәсибәте эшчәнлеге турында да яза. Исхак Закировның «Мин ни өчен мөселман?» мәкаләсе эчтәлеге һәм нигезлелеге буенча көчле була. Ул атеистларның, дәүләт ярдәмен кулланып, иркен рәвештә динне яклап чыгарга мөмкинчелек бирмәүләрен ассызыклый. Ислам критикларыннан көлеп, Исхак аларның Коръәнгә каршы чыга алмауларын раслый, чөнки алар аны өйрәнмәгән. Моннан тыш, бу активистларның күпчелеге татар телен белмәгән дә. Автор фикеренчә, Коръәндә турыдан туры әйтелгәнчә, атеизмны киң белем алып кына җиңәргә мөмкин. Журналның соңгы – 37 нче саны 1928 елның февралендә чыга. Соңгы, чөнки вакыйгалар аның язмышын алдан билгеләп куя. Журналның күләме яшь авторларга иҗтимагый-сәяси һәм дини тормышта барган вакыйгаларга карата мөнәсәбәтен тулы дәрәҗәдә белдерергә мөмкинлек бирми. Шуңа күрә алар журналга кушымта итеп

брошюралар чыгара башлый. Барлыгы кулдан язылган 8 сан дөнья күрә. Аларда рәсми матбугатта чыккан материаллар анализлана. «Карт динсез»нең 1928 елның 20 мартында «Кызыл Татарстан»да басылган дини карашларны Совет законнары белән туры китерү мөмкин булмавы турындагы мәкаләсенә багышланган брошюра игътибарга лаек. Исхак Закиров, дәүләт гражданнарның дини карашларыннан аерым булырга тиешлеген, һәм ул ниндидер бер дингә өстенлек бирсә, моның белән динара ызгышлар тудырып, җинаять кылуын әйтеп, «Карт динсез»нең фикерләрен кире кага. И. Закировтан кала, брошюра авторлары арасында Педагогия техникумы шәкерте Зөфәр Габдуллин һәм Исхак белән бергә 1923 елда Казаков мәчете мөәзине Шәрифҗан Ибраһимовтан башлангыч дини белем алган Габдуллаһ Сәгыев була. Алар журналның редакция бүле була. 1927 елда Исхак үз уставлы оешма булдырып, яшьләр арасында дини-агарту һәм мәдәни эшчәнлекне оештыруның оешканрак формаларын кулланырга карар кабул итә. Аны дуслары хуплап чыга. 1927 елның 24 апрелендә якынча 10 кеше беренче оештыру мәсьәләләре буенча җыелыш уздыра. Аларның иң өлкәне – унсигез яшьлек Зөфәр Габдуллин, ә яшьләре – мәкаләләр авторы Габдуллаһ Габдрахманов, Мәгъсүм Габитов һәм Зәйнулла Җиһаншин була. Оешманың уставы кабул ителә. Анда «Хакыйкать йолдызы» дип аталган оешмада 14-18 яшьлек (журналда элегрәк эшләгәннәр өчен яшь буенча чыгармалар эшләнә), дин тотучы, журналны укучы һәм мәкаләләр язучы яшьләр була алуы билгеләнә. Һәр әгъзага 5 тиен күләмендә взнос билгеләнә. Оешма әгъзасы динне яклау буенча пропаганда чараларында катнашырга тиеш була. Моннан тыш ул пөхтәлекне сакларга, гигиена кагыйдәләрен үтәргә һәм шәхси мәсьәләләр буенча оешмага зыян китермәскә тиеш була. Мәкаләләрне язганда, мөмкин булган хаталардан көлүләрдән куркып, малайлар тәхәллүсләр куллана. Алар аралашканда да кулланылган. И. Закиров – «Изак», З. Габдуллин – «Зигин», Г. Габитов «Илһам» була. Журналны чыгарудан тыш, оешма

әгъзалары өчен төрле уеннар оештырыла. Шундый уеннарның берсен Исхак уйлап чыгара. Ул «Дәүләтле уен» дип атала. Товар-акча мөнәсәбәтләре имитацияләнә. Моның өчен уенчык акчалар һ. б. эшләнелә.

Әмма тиздән журнал чыгару да, бу уеннар да туктатыла, чөнки яшь мөселманнарның эшенә Берләшкән дәүләт иминлеге идарәсе (ОГПУ) кысыла. Евгения Гинзбургның «Крутой маршрут» документаль повесте буенча билгеле булган следователь Царевский, әле Гинзбург эшенә кадәр үк «халык дошманнарын» эзләү һәм фаш итү алымнарын булдыра. Аның беренче тәҗрибәләреннән «Хакыйкать йолдызы» яшьләр дини-милли оешмасы турында эш» була, аны тикшерү буенча карарны ул 1928 елның 29 маенда чыгара. Оешманың күп әгъзаларыннан, шул нисбәттән унөч яшьлек Әнвәр Исмәгыйлевтән һәм әти-әниләрендә Усть-Сысольск шәһәрендә булганда кулга алынган Габделхак Сәгыевтән дә сорау алына. Царевский бу яшүсмерләрдә «зур эш» эшли алмаячагын аңлый һәм аңа фаш ителгән мөселман контрреволюционерлары отчетына кертелергә тиеш булган күз уңында тотылган өлкәннәрне дә өсти. Протоколларда күренекле галим Галимҗан Шәрәф (мәкаләләрендә малайлар аны матбугат бәйләнүләреннән яклап чыга), Казаков мәчете мулласы Гаяз Якупов (И. Закиров аңа тикшереп чыгарга журналның бер санын китергән була), шул мәчетнең мөәзине Шәрифҗан Ибраһимов (Царевский фикеренчә, малайлар анда законсыз рәвештә дини белем алган) һәм Исхакның әтисе (малайлар аның өендә җыела торган була) исемнәре дә атала. Царевский әһәмиятле берни җыя алмый. Әмма теләсә нинди вак фактлар да эшкә китә. Хәтта журналның гыйнвар саннарының берсендә Ш. Мәрҗанинең туган көне – баш хәрефтән, ә В. Ленинның вафат булган көне юл хәрефеннән язылуы «контрреволюция һәм советларга каршы булу» дип санала. Сорау алганда малайлар фәкать дөреслектә булганны гына сөйли. Ә Исхакның әтисе Кадыйр абый улы белән горурлануын әйтә. Әлбәттә, Царевский эшне ахырына ук җиткерә. Ул Казаков мәчете мәхәлләсе вәкилләре За-

киров Кадыйр Закир улы, Ибраһимов Шәрифҗан Әхмәт улы, Якупов Гаяз Сәгетдин улы һәм оешманың иң өлкән вәкиле Зөфәр Габдуллинга илле сигезенче статья буенча гаепләү карары чыгара. Берләшкән дәүләт иминлеге идарәсенең Мәскәүдәге Коллегиясе карары буенча, өлкәннәр өч елга Соловецк концлагеренә, ә Зөфәр Габдуллин өч елга Себергә җибәрелә.

«Ислам баласы» кулъязма журналының кыска тарихы шулай тәмамлана. Әмма очерк геройларының тормышы моның белән бетми. Сиксән елга якын элек булган вакыйгалар 1995 елда, бу юлларның авторы шул вакыйгаларның соңгы шаһите – Исхакның бертуган абыйсы Госман Закировны эзләп тапкач кабат терелә.

*Ровель Кашапов,*
*РФнең Татарстан Республикасында Федераль*
*куркынычсызлык хезмәте музее директоры*

*Рәмзилә Шафикова тәрҗемәсе*

# Нәсыйхәт

# Дингә карата ник җавапсызбыз?

Чыннан да, кеше холкының сыйфатлары аның иманы белән тыгыз бәйле. Чөнки иман – ул җаваплылыкның нигезе. Шул ук вакытта иман үзе гыйбадәт белән бәйле. Гыйбадәтләрне (сүз фарыз гыйбадәтләр – намаз, ураза, хаҗ, зәкәт хакында бара) үтәүдә кимчелек бар икән – бу очракта кешенең иманы да зәгыйфь. Ә иман зәгыйфь булганда, ягъни, кеше Аллаһның әмерләрен искә алудан ерак булганда, шәхеснең төрле холык проблемалары да ачыклана.

Авырудан дәваланыр өчен, иң беренче аның төп сәбәбен ачыклау кирәк. Сәбәбен тапкач кына дәвалану дөрес рәвештә бара һәм файдалы булачак. Шуңа күрә, холыкка килгәндә дә, кешенең әхлакый сыйфатлары аның игътикадыннан, гомеренең хак мәгънәсен табудан торадыр. Иң беренче холыкка тәэсир итүче нәрсәләр ул – иман һәм гыйбадәт. Димәк, холык проблемасын чишү хакында сөйләгәндә, ничек, нинди юллар белән әхлакый сыйфатларны яхшыртырга дигәндә, иң беренчедән гыйбадәт, тәкъвалык мәсьәләләрен күтәрү мөһим.

Күргәнебезчә, хәзерге көндә өммәтебез эчендә гыйбадәткә карата кимчелекләр күп. Бүгенге көндә мөселман өммәтебезне шартлы рәвештә ике төргә аерып була.

Беренче төр мөселманнар – Аллаһның әмерләрен үтәргә тырышучы мөэминнәр. Димәк, намаз уку, ураза тоту, зәкәт бирү, хаҗ кылуга карата игътибарлы, ягъни төп вазифаларны (фарызларны) үтәүчеләр һәм гөнаһтан саклану юлында көч куючы мөэминнәр.

Икенче төр мөселманнар – Аллаһка иман китерүчеләр, ләкин Аллаһның әмерләрен үтәмәүчеләр, фарыз гамәлләрне кылмаучылар һәм гөнаһ кылудан сакланмаучылар.

Гыйбадәт хакында сөйләгәндә, кешеләр, хәтта этник мөселманнар, шулай диләр: «Мин Аллаһка болай да ышанам, нигә миңа намаз укырга,

ураза тотарга һ.б.?» Йә кемдер: «Мин әле яшь, бөтен гомер әле алда. Уйнап, шаярып калыйм, эш – дөнья, мәчеткә пенсиягә чыккач йөрермен!» – ди. Йә кемдер: «Минем зур гөнаһлар кылганым юк, кеше рәнҗеткәнем юк, җәһәннәмгә аяк басмамын», – ди. Һәм башка шундый фикерләр ишетергә мөмкин.

Әлбәттә, бу күренеш наданлык аркасында. Халык диннең нәрсә икәнен аңлап бетерми, аның нигезләрен белми. Бүгенге көндә дингә карата үзенә бер стереотип барлыкка килгән: «мин аерым – дин аерым», «мин монда – ә дин каядыр шунда, янәшәдә». Кеше шуңа ияләшкән: бик кирәк чакларда гына динне искә алабыз. Бик авыр хәлләрдә генә Аллаһның ярдәменә ашыгабыз. Рәхәт вакытта дин турында онытыла, «дин кирәк түгел, мөмкинчелек һәм вакыт юк», дибез. Аллаһны, гомер Бирүчене искә алыр өчен, биш-ун минут вакытыбыз да жәл. Әлбәттә, бу җавапсызлык һәм кызганыч хәл.

Бу хакта Коръәни-Кәримдә шулай диелгән:

وَإِذَا مَسَّ الْإِنسَانَ الضُّرُّ دَعَانَا لِجَنبِهِ أَوْ قَاعِدًا أَوْ قَائِمًا فَلَمَّا كَشَفْنَا عَنْهُ
ضُرَّهُ مَرَّ كَأَن لَّمْ يَدْعُنَا إِلَىٰ ضُرٍّ مَّسَّهُ ۚ كَذَٰلِكَ زُيِّنَ لِلْمُسْرِفِينَ مَا كَانُوا
يَعْمَلُونَ ﴿١٢﴾

**«Кыен хәлләрдә калган чакларда кеше кырын яткан килеш тә, утырып та, аягүрә дә Безгә ялвара (бәладан коткаруыбызны өмет итеп) дога кыла. Безнең ярдәм белән бәла-каза узып киткәч, әйтерсең лә, ул ярдәм сорап, безгә ялвармаган да (искә дә алмый)».**

«Юныс», 10:12

Шуңа күрә, дингә карата җавапсызлык сәбәпләрен ачыклау аеруча мөһим. Алар түбәндәгеләр:

Беренче сәбәп – Аллаһның бар булуында шикләнү.

Коръәни-Кәримдә күп аятьләрдә Аллаһ Үзенең барлыгы хакында төрле галәмәтләргә, мәхлукларына игътибар итәргә чакыра, һәм шушы галәмәтләр хакында уйланып, кеше «Аллаһ бар икән» дигән фикергә килергә тиеш.

Кайвакыт Аллаһ хакында сөйләгәндә, кеше Аны күрергә теләвен таләп итә: «Миңа Аллаһны күрсәтегез. Күрсәм, Аның барлыгына ышанырмын!», – ди. Әйе, без Аны күрмибез, ләкин Аллаһ әмере белән бу хәлнең үз хикмәте бар. Шулай ук, белгәнебезчә, башка күренми торган затлар да бар: фәрештәләр, җеннәр, җаныбыз, һава, микроорганизмнар һ.б.

Әйтергә кирәк, беренчедән, иманның мәгънәсе дә шунда ки: кеше Аллаһны күрмичә, Аның барлыгына ышанырга тиеш. Күренми торган, сизелми торган нәрсәнең барлыгын чын күңел, бөтен йөрәк белән кабул итү, аңа ышану – иман була. Ә Аны күрсәң, «иман» сүзе үзенең төп мәгънәсен югалта. Һәм шул ук вакытта гомернең мәгънәсе дә шунда – сынаудадыр! Иман китерерме – юкмы, шикләнерме – юкмы.

Икенчедән, динебез өйрәткәнчә, кеше бу дөньяда тою әгъзалары белән Аллаһны таный алмый. Аны күзләребез белән күрә алмыйбыз, колак белән ишетмибез, кул белән тотып карый алмыйбыз, борын белән исни алмыйбыз, тел белән дә тәмгә ялап карый алмыйбыз. Нигә? Чөнки тән әгъзалары материаль затларны гына танырга юнәлттерелгән. Ә Аллаһ Тәгалә материаль түгел. Һәм бу хәл, бу вакыйга Аллаһның кануны. Ул кешелекне шулай яратты: Үзенең теләге һәм хикмәте белән.

Әлбәттә, моны безгә Аның бөек, бер кимчелексез сыйфатлары өйрәтә. Мәсәлән: «Әл-мухаләфәт лил-хавәдис» – Аллаһ бөтен мәхлуклардан аерылып тора. Ул беркемгә һәм бернәрсәгә охшамаган. Аны бернәрсә белән дә чагыштырырга мөмкин түгел. Чөнки, Аллаһтан тыш, бөтен нәрсәнең кимчелеге бар. «Әл-кыямү бинәфсиһи» – Ул бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Димәк, Аллаһка карата форма, вакыт, урын, әгъзалар, тән дигән нәрсәләр

юк. Ул ашамлыкка, һавага, кояшка, суга һ. б. нәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Мохтаҗлык сыйфаты мәхлукатларга гына хас, ә Аллаһ Тәгалә Бар Итүче, Яралтучы (Халик).

Ничек итеп Аны күрергә? Урыны юк, кыяфәте юк... Әлбәттә, күреп булмый. Аның яшәве мәхлукның яшәвенә охшамаган бит.

Бу хакта Аллаһ Тәгалә шулай ди:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ ۖ ﴿١١﴾

**«...Ул бернәрсәгә дә һәм беркемгә дә охшаш түгел...»**

«Шура / Киңәш», 42:11

Аллаһның барлыгына иң төп дәлилләр – ул Аның галәмәтләре, ул да булса, мәхлуклары, ягъни әйләнә-тирә дөнья булып тора. Мәсәлән, Аллаһ Тәгалә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَكُم مِّن تُرَابٍ ثُمَّ إِذَا أَنتُم بَشَرٌ تَنتَشِرُونَ ﴿٢٠﴾ وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَتَفَكَّرُونَ ﴿٢١﴾ وَمِنْ آيَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّلْعَالِمِينَ ﴿٢٢﴾ وَمِنْ آيَاتِهِ مَنَامُكُم بِاللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَابْتِغَاؤُكُم مِّن فَضْلِهِ ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَسْمَعُونَ ﴿٢٣﴾ وَمِنْ آيَاتِهِ يُرِيكُمُ الْبَرْقَ خَوْفًا وَطَمَعًا وَيُنَزِّلُ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَيُحْيِي بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا ۚ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَاتٍ لِّقَوْمٍ يَعْقِلُونَ ﴿٢٤﴾

**«Сезнең туфрактан яралтылуыгыз Аның кодрәтенә дәлилдер. Соңра сез үрчеп, җир йөзенә таралдыгыз. Үзегездән хатын-**

**нарны яралту да, ул хатыннар белән бергә яшәвегез дә, ир белән хатын арасындагы мәхәббәт һәм наз, бер-береңнең хаталарын кичерә белү, һичшиксез, Аллаһның кодрәтенә ачык дәлилләрдер. Хактыр ки, бу эшләрдә фикерле белүче кавемнәр өчен гыйбрәтләр бар. Аның күкләрне һәм җирне юктан бар итүе дә. Ана телләрегезне, тән төсләрегезне төрле-төрле итеп яратуы да – Аллаһның бәхәссез дәлилләредер. Хактыр ки, боларда хәбәрдарлар өчен гыйбрәтләр бар. Төннәрен йокы ләззәтен татуыгыз да, көндезләрен ятып хәл алу һәм ризыкны табуыгыз да – Аның могҗизаларына ачык дәлилдер. Хактыр ки, бу хәлләрдә дә саңгырау булмаганнар өчен гыйбрәтләр бар. Аның дәлилләреннән берсе шулдыр. Ул яшен яшьнәтеп, сез куркып, өмет бирә. Ул яңгыр яудырып, корып үлгән туфракка җан өрә. Хактыр ки, фикерле белгәннәр өчен гыйбрәтләр бар».**

«Рум», 30:20-24

فَلَا يَنظُرُونَ إِلَى الْإِبِلِ كَيْفَ خُلِقَتْ ﴿١٧﴾ وَإِلَى السَّمَاءِ كَيْفَ
رُفِعَتْ ﴿١٨﴾ وَإِلَى الْجِبَالِ كَيْفَ نُصِبَتْ ﴿١٩﴾ وَإِلَى الْأَرْضِ كَيْفَ
سُطِحَتْ ﴿٢٠﴾

**«Алар дөянең ничек яралтылганы турында уйлап карамаслармы? Күкнең ничек биек итеп яралтылганын уйланмаслармы? Ул тауларның ничек итеп беркетелгәне, җирнең ничек түшәлеп куелганы турында уйланмаслармы?»**

«Гашийә / Каплаучы», 88:17-20

Чыннан да, Аллаһның барлыгына дәлилләр бик күп, хәтта, кешенең гакыл иясе булуы да. Ләкин без шушы бөтен нәрсәгә ияләшкән. Һәм, бер

дә уйланмыйча, дөнья нигъмәтләрен рәхәтләнеп кулланабыз. Шуңа күрә бу аятьләрдә Аллаһ Тәгалә кешеләрне фикерләргә өнди, галәмәтләренә каратып, Үзе белән таныштыра.

*Рафикъ Рафаэль улы Йосыпов,*

*Казан Ислам университеты мөгаллиме,*

*Ислам фәннәре факультеты мөдиренең урынбасары*

# Тәүбә

Галимнәр фикеренчә, һәр кылынган гөнаһ өчен тәүбә кылырга кирәк. Шул ук вакытта, әгәр гөнаһ бары тик (гөнаһ кылучы) колга һәм Аллаһы Тәгаләгә генә кагылса, ә кешеләрдән беркемгә дә кагылмаса, бу очракта кешенең тәүбәсе өч шартны канәгатьләндерергә тиеш:

1) мондый гөнаһны кылудан баш тартырга;

2) кылган гөнаһы өчен үкенергә;

3) киләчәктә бу гөнаһны беркайчан да кылмаска катгый карар кабул итәргә тиеш.

Әгәр югарыда зикер ителгән шартларның берсе генә үтәлмәсә дә, тәүбә (тулысынча) дөрес булып саналмый.

Кеше тарафыннан кылынган гөнаһ ничек тә булса икенче бер кешегә кагылса, тәүбә югарыда әйтелгән өч шартка тагын бер шарт өстәлә: аның гамәленнән зыян күрүче каршында гаебен төзәтү. Әгәр сүз (үзләштерелгән яки урланган) акчалар яисә башка матди зиннәтләр турында барса, аларны хуҗасына кайтарып бирергә[1] кирәк, әгәр эш гайбәткә яки Коръән һәм сөннәт аша билгеләнеп, ваҗиб җәза (хәдд) тиешле булган теләсә нинди башка бер гөнаһка кагылса, бу очракта гаепле кешегә ирекле рәвештә үзен бу җәзага китерергә яки зыян күрүчедән гафу үтенергә тиеш, әгәр инде хүлә[2] белән бәйле булса, бу вакытта гаепле кешегә зыян күрүченең[3] рөхсәтен алырга кирәк.

Булган бөтен гөнаһлар өчен дә тәүбә кылырга кирәк. Әгәр кеше гөнаһларының бер өлеше өчен генә тәүбә кылса, аның тәүбәсе, сөннәт әһелләренең фикеренчә, дөрес булып санала ала, ләкин ул калган гөнаһлары өчен дә тәүбә кылырга тиеш, чөнки Коръән, сөннәт һәм

1 Кайтарасы әйбер инде булмаса, аны компенсацияләү

2 Берәр кеше турында начар сөйләү

3 Аның турында сөйләргә рөхсәт алу

галимнәрнең бердәм кабул иткән фикерләре тәүбә кылуның ваҗиб булуына ишарәли.

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә:

... وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ﴿٣١﴾

**«Әй иман китергән бәндәләр, барыгыз да Аллаһ Тәгаләгә тәүбә итегез һәм Аңа кайтыгыз, бәлки сез гафу ителүегез сәбәпле уңышка ирешерсез, газаптан котылырсыз».**

«Нур», 24:31

وَأَنِ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ ثُمَّ تُوبُوا إِلَيْهِ ﴿٣﴾

**«Дәхи гөнаһларыгыз өчен Аллаһтан гафу сорагыз, соңра тәүбә итеп Аллаһка кайтыгыз».**

«Һуд», 11:3

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا ﴿٨﴾

**«Ий мөэминнәр, Аллаһка чын ихлас тәүбә белән тәүбә итегез».**

«Тәхрим / Тыю», 66:8

1. Әбү Һурайра ﵁ әйтте: «Мин Аллаһ Илчесенең ﷺ: «Валлаһи, дөреслектә, мин бер көнгә Аллаһтан җитмеш тапкырдан күбрәк ярлыкау турында сорыйм һәм тәүбә итәм»[1] , – дип әйткәнен ишеттем».

2. Әл-Әгарр бин Йәсәр Әл-Мүзәни ﵁ әйтте: «Аллаһ Илчесе ﷺ: «Әй кешеләр, Аллаһка тәүбә итегез һәм Аңардан ярлыкау сорагыз, мин, дөреслектә, көнгә йөзәр мәртәбә тәүбә итәм»[2] , – дип әйтте».

3. Аллаһның Илчесенең ﷺ колы Әбү Хәмзә Әнәс бин Мәлик Әл-Әнсари ﵁ әйтте: «Аллаһның Илчесе: «Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә Үзенең

---

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

тәүбә кылучы колы өчен, сахрада югалган дөясен көтмәгәндә тапкан кешегә караганда да артыграк шатлана»[1] , – дип әйтте».

4. Әбү Муса Габдуллаһ бин Кайс Әл-Әшгари китерә: «Пәйгамбәр ﷺ : «Дөреслектә, кояш баеган тарафыннан чыкканчыга кадәр, көндез бер начар гамәл кылучы тәүбә итсен өчен, Аллаһ Тәгалә Үзенең кулын төнлә сузып торыр, һәм шулай ук төнлә начар гамәл кылучы тәүбә итсен өчен, Ул Үзенең кулын көндез сузып торыр»[2] , – дип әйтте».

5. Әбү Һүрәйрә ؓ түбәндәге хәдисне китерә: «Аллаһының Илчесе ﷺ: «Кояш баткан тарафыннан чыкканчы, Аллаһ тәүбә итүченең тәүбәсен кабул итә», – дип әйтте»[3].

6. Әбү Габдерахман Габдуллаһ бин Гомәр бин Әл-Хәттаб ؓ сүзләреннән риваять итәләр: «Пәйгамбәр ﷺ болай дип әйтте әйтте: «Дөреслектә, бөтен нәрсәгә кодрәтле һәм бөек Аллаһ, кол үлем алдыннан гырылдау тавышын чыгара башлаганчыга кадәр, аның тәүбәсен кабул итәчәк»[4].

7. Риваять ителә: Зирр бине Хөбәйш әйтте: «(Бервакыт) мин Сафван бин Гассәлгә ؓ аяк киеменә мәсех кылу турында сорау бирү өчен килдем. Ул: «Әй Зирр, сине монда нәрсә китерде?» – дип сорады. Мин: «Гыйлемгә омтылыш», – дип җавап бирдем. Ул: «Дөреслектә, фәрештәләр гыйлем эзләүчедән канәгать булуларын белдереп, аңа канатлары белән кагылалар!» – диде. Шуннан соң мин: «Мине олы һәм кече хаҗәтне үтәгәннән соң аяк киеменә мәсех кылу турындагы сорау борчый. Ә син Пәйгамбәрнең ﷺ сәхабәләреннән булдың, шуңа күрә синнән сорарга дип килдем, син аңардан бу хакта берәр нәрсә ишетмәдеңме?» – диде. Ул әйтте: «Әйе, әгәр без юлда булсак, ул безгә өч тәүлек эчендә күн оекбашларны бары тик госел бозылганда гына салырга кушты, табигый

---

1 Имам Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

3 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

4 Бу хәдисне Тирмизи китерә һәм ул моны: «Яхшы хәдис», – диде.

хаҗәтләрне үтәгәннән яки йоклаганнан соң салу лязем түгел». Аннан соң мин: «Ә син ярату турында берәр нәрсә ишетмәдеңме?» – дип сорадым. Ул әйтте: «Әйе. (Бервакыт) без Аллаһының Илчесе ﷺ белән бергә булганда, бер сахра кешесе кинәт кычкырып аңа: «Әй Мөхәммәд!» – дип мөрәҗәгать итте. Аллаһының Илчесе ﷺ шулай ук аңа кычкырып: «Мин монда!» – дип җавап бирде. Мин аңа: «Аллаһ сиңа мәрхәмәтлелеген күрсәтсен, акрынрак әйт, син бит Пәйгамбәр ﷺ каршында басып торасың, һәм сиңа болай эшләү тыела!» – дип әйттем. Ләкин ул: «Валлаһи, мин акрынрак әйтмим!» – диде. Аннан соң бу бәдәви Пәйгамбәргә ﷺ мөрәҗәгать итеп: «Берәү бу кешеләрне ярата, ләкин ул аларга кушылмады әле»[1], – дип әйтте. (Моңа) Пәйгамбәр ﷺ: «Кыямәт көнендә бу кеше үзе яраткан бәндәләр белән бергә булыр», – дип җавап бирде».

Зирр бин Хөбәйш әйтте: «Һәм ул безгә көнбатыштагы кырык (яки җитмеш) ел киңлегендәге капкаларны (яки: шулкадәр киң ки, атлы кешегә бу ераклыкны кырык яисә җитмеш ел үтәргә туры килер иде) зикер иткәнчегә кадәр сөйләвен дәвам итте».

Бу хәдисне риваять итүчеләрнең берсе Суфьян әйтте: «Бу капкалар Шам тарафында урнашкан. Аллаһы Тәгалә аларны күкләрне һәм җирне яраткан көндә тәүбә өчен ачык итеп ясатты һәм алар шул тарафтан кояш чыкканчыга кадәр ябылмаячаклар», – дип әйтте[2].

8. Әбү Сәгыйд Сәгъд бин Мәлик бин Синән Әл-Хөдри رضي الله عنه сүзләреннән риваять итәлә: Пәйгамбәр ﷺ: «Сезгә кадәр яшәүчеләр арасында бер кеше булган, ул туксан тугыз кешене үтергән, ә аннан соң (кешеләрдән) җирдә яшәүче иң галим кеше турында сораштыра башлаган, һәм аны (бәни Исраилдән булган) бер руханига җибәргәннәр. Ул әлеге рухани янына килеп, туксан тугыз кешене үтерүе турында сөйләгән

1 Бәдәви үз-үзен күздә тотып әйтә. Ул да Пәйгамбәрне вә аның сәхабәләрен ярата, ләкин алар кылган дини гамәлләрне кылмый иде әле.

2 Тирмизи һәм башка мөхәддисләр тарафыннан килә. Тирмизи: «Яхшы, дөрес хәдис», – әйтте.

һәм тәүбә кылуы файда китерерме дип сораган. Бу рухани: «Юк», – дип әйткән. Шунда ул бу руханины да үтергән һәм ул үтергән кешеләрнең саны йөзгә тулган. Аннан соң ул янә кешеләрдән җирдә яшәүче иң галим кеше турында сораштыра башлаган, аңа бер галимне күрсәткәннәр. Галим белән очрашкач, ул үзенең йөз кеше үтерүе турында сөйләгән һәм тәүбә аңа файда бирерме, юкмы, дип сораган. Бу галим: «Әйе, үкенүчегә кем тәүбә итәргә комачаулый соң? Фәлән җиргә бар, анда Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылучылар яши, алар белән бергә Аллаһка гыйбадәт кыл һәм үз җиреңә кайтма, чөнки бу җирдә явызлык хөкем сөрә», – диде. Һәм ул шунда юнәлгән, ләкин юлның яртысына җиткәч, ул үлеп китә.

Бу кеше сәбәпле рәхмәт фәрештәләре белән газап фәрештәләре үзара бәхәсләшә башлыйлар. Рәхмәт фәрештәләре: «Ул тәүбә итеп, калебе белән Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп барды!» – дип әйткәннәр. Газап фәрештәләренә килгәндә, алар: «Дөреслектә, ул беркайчан да бер генә яхшылык та кылмады!» – дип әйткәннәр. Шунда алар янына кеше сурәтендәге бер фәрештә килде һәм аны бәхәстә казый итеп сайладылар. Ул: «Бу ике җиргә кадәр булган ераклыкны үлчәгез, һәм ул кайсы җиргә якынрак булса, шул җир әһеленнән», – дип әйткән. Үлчәгәннән соң алар аны ул омтылган җиргә якынрак итеп тапканнар, һәм рәхмәт фәрештәләре бу кешене үзләре белән алып киткәннәр»[1].

9. Габдулла бин Кәгъб бин Мәлик ﷺ сүзләреннән риваять итәләр: Кәгъб ﷺ сукырайгач, аны җитәкләп йөртүче улы Кәгъб бин Мәликнең Пәйгамбәр ﷺ белән бергә Тәбук сугышында катнаша алмыйча Мәдинәдә калуы турында сөйләде.

Кәгъб әйтте: «Мин Тәбук сугышыннан башка Аллаһының Илчесе катнашкан бер генә сугышны да калдырмадым. Алай дисәң, мин аның белән Бәдер сугышында да булмадым, ләкин ул вакытта сугыштан калучыларның берсе дә шелтәгә дучар ителмәделәр, чөнки

[1] Имам Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан

Аллаһның Илчесе башка мөселманнар белән бергә Мәдинәдән бары тик корәешлеләрнең сәүдә кәрваннарын яулап алу өчен генә чыктылар, ә Аллаһ Тәгалә аларны (үзләре бу хакта килешмәгән) дошманнары белән очраштырды. Моннан тыш, мин Аллаһның Илчесе белән Гакабә кичендә, Исламга хыянәт итмәскә бәйгать биргәндә бергә булдык һәм Бәдер сугышы кешеләр арасында бик абруйлы булып йөрүгә карамастан, мин Гакабәне Бәдер сугышына алмаштырмас идем.

Минем вакыйгага килгәндә, мин Аллаһның Илчесе ﷺ белән бергә Тәбук сугышына бармаган вакытта, дөреслектә, мин бик куәтле һәм яхшы тәэмин ителгән кеше идем. Аллаһ белән ант итәм, моңа кадәр минем беркайчан да ике ана дөям булмады, ләкин бу сугыш вакытында минем дөяләрем бар иде...

...Кәгъб әйтте: «Күренергә теләмәгән азчылык, бу хакта берәү дә белми дип санадылар, ләкин бу хәл мондый кеше турында Аллаһ Тәгаләдән вәхи килгәнче генә дәвам итте. Аллаһның Илчесе ﷺ җимешләр өлгергәч, бу походка чыкты, һәм ул башка мөселманнар белән бергә бу походка әзерләнде, мин исә алар белән бергә әзерләнү өчен иртәләрен өйдән чыга башладым, ләкин бернәрсә дә эшли алмыйча, үз-үземә: «Әгәр мин теләсәм, моны эшли алам», – дип әйтеп кире кайта идем. Башкалар җитди рәвештә һөҗүмгә әзерләнгәндә, мин һаман шулай эшләвемне дәвам иттем. Ахырда Аллаһының Илчесе башка мөселманнар белән бергә иртән юлга чыкты, ә мин шулай итеп берни дә эшли алмадым. Шунда мин янә иртән чыгып әзерлек өчен бернәрсә эшләмичә кире кайттым, һәм мин бу хәлдә булганда, сугышта катнашучылар бик тиз хәрәкәт итеп, бик еракка китәргә өлгерделәр, ә мин юлга чыгып аларны куып тотарга карар иттем, ләкин бу миңа насыйп булмады. Аллаһының Илчесе ﷺ киткәннән соң, мин кешеләр арасында пәйдә булдым. Монафикълыкта гаепләнүчеләрдән, яисә Аллаһы Тәгалә аклаган зәгыйфь бәндәләрдән

башка үземә охшаш[1] кешеләрне очратмавым мине бик күңелсезләндерә иде.

Аллаһның Илчесенә килгәндә, ул Тәбукка килеп җиткәнче мине искә төшермәгән, ә инде бу урынга килеп җитеп, кешеләр арасында утырганда: «Ә Кәгъб бин Мәлик нәрсә эшли?» – дип сораган. Бәнү сәлимә кабиләсеннән берәү: «Әй Аллаһының Илчесе, аны ике киеме[2] һәм тәкәбберлеге тоткарлады», – дигән. Шунда Мүгәз бин Җәбәл ﷺ: «Син шундый ямьсез әйттең! Аллаһ белән ант итәм, әй Аллаһның Илчесе, безгә аның турында бары тик яхшы ягы гына билгеле!» – дип әйткән. Аллаһының Илчесе ﷺ бернәрсә дә әйтмәгән...

...Кәгъб әйтте: «Аллаһының Илчесенең Тәбуктан кайтуы турында белгәч, мине калтырау биләп алды һәм мин үз-үземә: «Иртәгә миңа анык ачуыннан ничек котылырга?» – дип, гаиләә әһелләремә һәр хикмәтле кешеләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итеп, ялган акланулар уйлый башладым. Кешеләр Аллаһның Илчесе Мәдинәдән бик якында дип сөйләшә башлагач, миннән бөтен ялган китте[3], мин ялган белән берничек тә аның ачуыннан котыла алмаячагымны белдем һәм дөресен сөйләргә карар кылдым...

...Иртән Аллаһының Илчесе Мәдинәгә кайтты, ә ул берәр сәфәрдән кайтса, гадәттә иң әүвәл мәчеткә килеп ике рәкәгать намаз укый, ә аннан соң (күпмедер вакыт) шунда кешеләр белән утыра иде. Ул боларның барысын да эшләгәч, аның янына Мәдинәдә калган кешеләр килеп аклана башладылар һәм үзләренең акклануларын антлар белән ныгыттылар. Мондый кешеләр сиксәнгә якын җыелдылар, ул аларның акклануларын һәм антларын кабул итте, аларны ярлыкауны сорап Аллаһка мөрәҗәгать итте, аларның яшерен уйларын хөкем итүне Аллаһыга калдырды. Аннан соң мин аның янына килдем, аңа сәлам бирдем, ул ачуын яшерүче

[1] Ягъни, бу походта катнашмаучылар

[2] Кыйммәтле кием күз алдында тотыла

[3] Кәгүб ялган акланулардан баш тартырга карар кылуын күздә тота

кешенең елмаюы белән елмайды һәм: «Монда кил», –диде. Мин аңа якынрак килеп, аның каршысына утырдым, ә ул миннән: «Сине калырга нәрсә мәҗбүр итте? Син дөяләр сатып алмадыңмыни?» – дип сорады».

Кәгъб әйтте: «Мин: «Әй Аллаһының Илчесе! Аллаһ белән ант итәм, әгәр мин хәзер башка кеше каршысында утырсам, ялган акланулар ярдәмендә аның ачуыннан котылган булыр идем, чөнки мин оста телле кеше. Ләкин, Аллаһ белән ант итәм, әгәр бүген сине алдасам, ә син минем ялганымнан канәгать калсаң, Аллаһы Тәгалә барыбер тиздән дөреслекне ачар һәм син миңа ачуланырсың[1]. Әгәр мин сиңа хакны сөйләсәм, син миңа моның өчен (хәзер үк) ачуланырсың, ләкин мин моның өчен[2] бар нәрсәгә кодрәтле һәм олуг Аллаһ мине хәерле чыгышка китерер дип өметләнәм! Аллаһ белән ант итәм, минем акланырлык сәбәбем юк, һәм Аллаһ белән ант итәм, мин калган вакытта моңарчы беркайчан да булмаган кебек куәтле һәм тәэмин ителгән идем!»

Кәгъб әйтте: «Шунда Аллаһының Илчесе, галәйһиссәлам әйтте: «Бу эшкә килгәндә, ул дөресен әйтте. Тор, һәм Аллаһы Тәгалә синең хакта карар кабул иткәнче, көт».

(Бәнү сәлимә кабиләсеннән кешеләр килеп, пәйгамбәрдән ярлыкауны сорарга куша башладылар)

Кәгъб әйтте: «Аллаһ белән ант итәм, алар мине (шулкадәр нык) шелтәләүләрен дәвам иттеләр, ахыр чиктә минем Аллаһның Илчесе янына кайтып, «мин дөресен сөйләмәдем», дип әйтердәй булдым, ә аннан соң мин алардан: «Башка берәү белән минеке кебек хәл булдымы?»[3] – дип сорадым. Алар әйттеләр: «Әйе, тагын ике кеше син әйткәнне әйттеләр, һәм аларга да сиңа әйтелгән сүзләр әйтелде».

---

1 Ягъни, «Аллаһы Тәгалә сиңа мин ялганлаган нәрсәне күрсәтер һәм мин барыбер синең ачуыңнан качып котыла алмам»

2 Ягъни, «хакны әйткәнем өчен»

3 Ягъни, «кылган гамәлләре аклануга лаек түгеллеген аңлап хакны әйтүче кешеләр тагын табылдымы?»

Кәгъб әйтте: «Ул ике кеше кемнәр?» Алар: «Мөрар бин Рабига Әл-Гамири һәм Хиләл бин Өмәййә Әл-Вакифи», – диделәр».

Кәгъб әйтте: «Моны әйтеп алар миңа Бәдер сугышында катнашучы ике изге кешенең исемен атадылар, һәм мин: «Миңа алардан үрнәк алырга кирәк», – дидем.

Һәм алар миңа әлеге ике кешенең исемен атаганнан соң, мин бернәрсәне дә үзгәртмәскә карар иттем[1]. Аллаһының Илчесе ﷺ килгәндә, ул (кешеләргә Мәдинәдә) бөтен кеше арасыннан бары тик безнең өчебез белән генә сөйләшүдән тыйды»...

...Мин бу халәттә тагын ун көн тордым, бу көннәр үткәч, кешеләргә безнең белән сөйләшүне тыйган вакыттан алып илле көн үтеп тә китте. Илленче кич үткән кичтә мин иртәнге намазны өйләребезнең берсенең түбәсендә укыдым, һәм шунда Аллаһы Тәгалә зикер иткән халәттә [2] утырдым, җаным кысылды, җир дә никадәр киң булуына да карамастан миңа кысан булып тоелды. Шул вакытта мин кинәт Сәл[3] тавына менеп, шуннан бөтен тавышына: «Әй Кәгъб бин Мәлик, шатлан!» – дип кычкыручы кешенең тавышын ишеттем. Моны ишетеп, мин сәҗдәгә егылдым, чөнки җиңеллек килгәнен аңладым, һәм дөрестән дә иртәнге намаз вакытында Аллаһның Илчесе ﷺ кешеләргә Аллаһы Тәгаләнең безнең тәүбәләребезне кабул итүе турында игълан итүе билгеле булды. ...Мәчеткә кергәч мин Аллаһының Илчесенең кешеләр арасында утырганын күрдем. Талхә бин Гобәйдуллаһка килгәндә, ул урыныннан сикереп торып миңа ташланды: минем кулымны кысарга һәм мине котларга тотынды. Аллаһ белән ант итәм, мөһәҗирләрдән[4] аңардан башка берәү дә тормады һәм Кәгъб Талхәнең бу гамәлен беркайчан да онытмаячак!»

---

1 Ягъни, үз сүзләреннән баш тартмаска

2 Бу хакта Коръәндә зекер ителүе күз алдында тотыла

3 Сәл тавы Мәдинә тирәлегендә урнашкан

4 Мөһәҗирләр – Пәйгамбәр ﷺ белән бергә Мәккәдән Мәдинәгә күчкән мөселманнар

Кәгъб әйтте: «Мин Аллаһның Илчесен ﷺ сәламләгәч, ул: «Син анаң тудырган көннән алып үткәннән бирле иң хәерле көнең өчен шатлан!» – диде, һәм шул вакытта аның йөзе шатлыктан балкый иде. Мин: «Әй Аллаһның Илчесе, бу синнәнме яки Аллаһтанмы?»[1] – дип сорадым. Ул моңа: «Юк, бу – бар нәрсәгә кодрәтле һәм олуг Аллаһтан!» – дип җавап бирде. Аллаһның Илчесен берәр нәрсә шатландырганда, аның йөзе нурлана һәм айның бер кисәге кебек була, һәм монда нәрсә турында икәнлеге безнең барыбызга да мәгълүм иде.

...Янә шулай ук: «Әй Аллаһның Илчесе, дөреслектә, Аллаһ Тәгалә мине бары тик хакны әйткәнем өчен генә коткарды[2], һәм тәүбәм кабул ителүгә шөкер итеп мин үлгәнче хаклыктан башканы сөйләмәячәкмен!» – дип әйттем».

Кәгъб әйтте: «Һәм Аллаһы Тәгалә (мондый аятьләрне) иңдерде: «Тәхкыйк, Аллаһ пәйгамбәрнең вә аңа ярдәм белән ияргән мөһаҗирләрнең һәм ансарларның авыр сәгатьләрдә пәйгамбәргә ярдәм иткәннәре өчен һәр кимчелекләрен кичерде. Алардан бер таифәнең Тәбук сугышына чыкмаска авышканнан соң, аларны да кичерде, чөнки алар күңелләрен яхшыртып, сугышка чыктылар, әлбәттә, Ул мөэмин бәндәләренә рәхимле вә шәфкатьле. Янә өч кешене гафу итте, алар Кәгъб бин Малик, Һилал бин Өмия, Мүррә бин Рабиглар, алар гозерсез Тәбук сугышына чыкмадылар, шуның өчен мөселманнар алардан киселделәр, һичберсе аларга якын бармады, бу эш аларга бик авыр булды. Кайгылары катылыктан хәтта аларга киң җир тар булды, вә күңелләре дә тараеп-кысылды, алар Аллаһ гәзабыннан котылырга юл юклыгын һәм Аллаһның үзенә генә ялварырга тиеш икәнлекне бик яхшы белделәр. Соңра аларга тәүбә итсеннәр өчен рәхмәт кылды, тәхкыйк, Аллаһ тәүбәләрне кабул итүче вә рәхимле. Ий мөэминнәр! Аллаһ хөкемнәренә хыйлаф булудан сакланыгыз! Һәм саклanучы тугры кешеләр белән бергә булыгыз!».

[1] Кәгъб гафу итүнең кемнән булуы турында сорый.

[2] Ягъни, «бернинди гозерсез килеш сугышта катнашмавым өчен мине»

Кәгъб әйтте: «Аллаһ белән ант итәм, Аллаһ Тәгалә миңа Исламга юл күрсәткәннән соң, Аның миңа биргән иң бөек нигъмәте – минем Аллаһның Илчесе белән дөрес булуым һәм аны алдамавым булды. (Чөнки алдаган булсам) мин дә ялганлаучылар кебек үк һәлак булыр идем. Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә вәхи иңдереп, ялганчыларның – Аның кем турында булса да әйткәннәреннән иң яманнары булуын хәбәр итте:

«Сугыштан алар янына кайтсагыз, алар Аллаһ белән ант итәләр, кимчелекләрен гафу итүегез өчен: Алардан бизегез! Тәхкыйк, алар – нәҗесләр, вә җәза йөзеннән, монафикъ булганнары өчен, урыннары җәһәннәмдер. Алар сезгә ант итеп акланырга тырышалар алардан риза булуыгыз өчен. Сез алардан риза булсагыз да, фәсыйк кешеләрдән Аллаһ һич тә разый булмас»[1].

*Имам Нәвавиның*

*«Изгеләр бакчасы» китабыннан*

[1] «Тәүбә», 9:95-96

# Йәгез, бер дога

# Гает намазы ни рәвешле кылына?

Бәйрәмнең беренче көнендә иртән иртүк торып, госел-тәһарәтләр алып, хушбуйлар сөртенеп, матур яңа киемнәрне кияргә кирәк. Бәйрәм намазы, гадәттә, гаетнең беренче иртәсендә мәчетләрдә кылына, намазга кадәр вәгазь-хөтбәләр укыла, соңыннан, кояш чыгып, якынча 40-50 минут (асылда 30 минут) узуга, намаз үзе кылына. Расүлебезнең ﷺ Корбан гаетендә сөйләгән хөтбәсендә болай дип әйткәне риваять кылына: «Безнең бу көнне кылган беренче гамәлебез – намаз булыр. Соңыннан корбанлыкларыбызны бугазларбыз. Бу рәвешле эшләгәнегез, һичшиксез, минем сөннәтемә туры китереп гамәл кылган булыр»[1].

Хәнәфи мәзһәбендә ике рәкәкатьтән торган гает намазы – ваҗиб хөкемендә, шәфигыйларда исә – сөннәт.

Безнең мәзһәб буенча, үз акылында булган, балигълек яшенә җиткән, сау-сәламәт, ирекле һәм сәфәрдә булмаган һәр ир-атка гает намазын кылу – ваҗиб.

Бәйрәм намазлары җәмәгать белән кылына һәм ике рәкәгатьтән тора. Намаз вакыты җитүгә, имам азан вә камәт әйтмичә генә бәйрәм намазы кылуга ният итә. Җәмәгать тә, аңа ияреп ният кыла. Гает намазлары мәчетләрдә яки махсус ясалган намаз кылу мәйданнарында укыла, ялгыз кылынмый.

## Бәйрәм намазының кылыну рәвеше

Имам кычкырып «Аллаһу әкбәр» сүзен әйтеп тәкбир китерә дә, кулларын кендек астына куеп бәйли. Аңа ияреп җәмәгать тә эчтән генә тәкбир китерә. Соңыннан имам да, җәмәгать тә үз эчләреннән «Сөбханәкә» дога-

[1] Бохари, Гыйдәйн

сын укыйлар. Дога тәмам булгач, имам да, җәмәгать тә өч мәртәбә тәкбир әйтәләр, һәркайсында кулларын колак турысына күтәреп, яңадан аска төшерәләр. Өченче тәкбирдән соң куллар кендек астына куеп бәйләнә. Тәкбирләр арасында кыска гына пауза ясала. Моннан соң имам кычкырып «Фатиха» сүрәсен һәм тагын бер өстәмә сүрә укый, бу вакытта җәмәгать тын гына тыңлап басып тора. Соңрак, рөкугъка кителә һәм ике сәҗдә кылынып, беренче рәкәгать тәмам була.

Икенче рәкәгатькә торып баскач, имам янә кычкырып «Фатиха» белән бер өстәмә сүрә укый. Аннан соң, беренче рәкәгатьтәге кебек кулларны бер күтәреп, бер төшереп өч мәртәбә тәкбир әйтелә. Өченче тәкбирдән соң рөкугъка кителә. Алга таба ике сәҗдә кылынып, «Әттәхият», «Салават»лар укылганнан соң, ике якка сәлам бирелә.

Намаз укылып беткәч, имам мөнбәргә менеп хөтбә сөйли. Хөтбәдә, гадәттә, бәйрәмнең кешеләрне берләштерүче, татулаштыручы, ярдәмләшүгә этәрүче форсат булуы турында әйтелә.

Хөтбә тәмам булгач, халык корбан чалырга таралыша.

*«Корбан» китабыннан,*

*«Хозур» нәшрият йорты, 2016*

# Корбан

# Корбанның мәгънәсе һәм тарихы

Гыйбадәт – адәм баласының ихтыяҗлары арасында иң мөһиме, тик ихлас гыйбадәт ярдәмендә генә ул рухи камиллеккә ирешә ала. Гыйбадәттән ерак торган кешеләр исә, еш кына күңелләре кыйналып, җаннарына тыңгылык таба алмый йөриләр. Рухи камиллек юлына аяк басып, төрле-төрле мәшәкать вә хәсрәтләр аша уза-уза гөнаһ керләреннән арынган бәндәләр, бәхет-сәгадәткә ирешеп, җан тынычлыгы табып, диндар гомер кичерәләр. Андыйларны фани дөньяның дәһшәтле чоңгыллары бервакытта да үзләренә тартып һәлак итә алмас.

Һәрбер адәм баласы рухи ихтыяҗларына дәрман табып, Раббысына шөкер итүче кол, илаһи канун-кагыйдәләргә итагатьле бәндә булып яшәсен өчен, Аллаһы Тәгалә кешеләргә кайбер гыйбадәтләрне ваҗиб кылган. Тик ул гыйбадәтләр шифалы дару кебек, табиб киңәшләрен сүзгә-сүз тоткан вакытта гына дәвалаучы хасияткә ия. Намаз, ураза, зәкәт һәм хаҗ кебек асыл гыйбадәтләр белән янәшә, Аллаһы Тәгаләнең фазыл-рәхмәте вә ризалыгына ирешеп, Аңа якынрак булу өчен билгеләнгән кайбер башка гыйбадәтләр дә бар. Шундыйларның берсе – корбан.

«Корбан» сүзе изге Коръән китабыннан алынган. Аның тамыры гарәп теленең «карубә» – «якынаю» фигыленә барып тоташа. Шулай итеп, «корбан» – нәрсәгә дә булса якынаю, дигән мәгънәне аңлата булып чыга. Диндә бу «якынаю»дан максат бер генә – Аллаһының рәхмәтенә ирешү. Моның өчен мөселман кешесенә үзен, малын вә җанын Хак Тәгаләгә багышлау шарт. Аның корбан чалуы да, ахыр чиктә, Раббысының боерыгын үтәү максаты белән генә булыр. Корбан бәйрәменең асылын адәм баласының Аллаһы әмеренә буйсынуын реаль гамәл белән исбатлавы тәшкил итә. Корбан итеп китерелергә тиешле әйберне дә Аллаһы Тәгалә үзе билгеләп куйган, ул да булса – махсус шартларга ия булган хайван. Бөек Раббыбыз үзенең сөекле бәндәсе Ибраһим пәйгамбәрнең ﷺ буй-

сыну вә итагатен сынавы буларак, корбан ителергә тиешле булган газиз улын махсус хайванга – куй тәкәгә – алыштырган. Бу кыйсса барчаларыбызга да яхшы мәгълүм.

Ибраһим пәйгамбәрне ﵇ Раббысы тугрылык сынавы аша уздырырга карар кыла. Башта ул малы белән сынала: Аллаһы Тәгалә аңа «Аллаһы» сүзен әйткән һәрбер кешегә байлыгын өләшергә боера. Шул рәвешле, Ибраһим пәйгамбәр ﵇ тора-бара кулындагы барча мөлкәтне таратып бетерә, ләкин ахырдан Аллаһы Тәгалә аңа малын бик күп мәртәбәләр арттырып кайтарып бирә. Соңыннан Хак Тәгаләнең бу тугры бәндәсе үз җаны белән имтиханга тартыла. Ул бу юлы да Раббысы хакына мәҗүси кавемдәшләре ташлаган учакта янып үләргә әзер булуын исбатлый. Аллаһы Тәгалә аның бу фидакарьлеген дә кабул итә һәм дөрләп янган ялкын телләрен хуш исле гөлбакчага әверелдерә. Ниһаять, шәфкатьле пәйгамбәрнең тугрылыгы үз якыннары аркылы сынала. Картаймыш көнендә Раббысы аңа бер угыл бирә. Ибраһим ﵇ аны үз җаныннан да артык күрә. Улы да бу мәхәббәткә хөрмәт һәм олылау белән җавап кайтара. Ләкин хак төшләр аркылы Раббысы Ибраһим пәйгамбәргә ﵇ бәгырь җимешен корбан итәргә кирәклеген белдерә. Йокыдан торуга, мәрхәмәтле ата төшен улына сөйләп бирә. Улы исә, атасының сөйләвен сабыр гына тыңлап бетергәннән соң, итагать вә тәслимиятнең иң камил үрнәген күрсәтә. Изге китабыбыз Коръәндә бу хакта болай диелә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَى فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَى قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Ул әйтте: «И улым! Төшемдә сине бугазлавымны күрдем. Бу хакта ни әйтерсең?» (Угылы) әйтте: «И әтием! Сиңа ни боерылган булса, шуны кыл. Аллаһы теләсә, мине сабырлык кылучылардан табарсың».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:102

Ата белән угыл билгеләнгән урынга килеп җиткәннән соң, Ибраһим ﷺ улын корбан китерү нияте белән җиргә яткыра. Коръәндә бу хакта түбәндәгеләрне укыйбыз:

فَلَمَّا أَسْلَمَا وَتَلَّهُ لِلْجَبِينِ ﴿١٠٣﴾ وَنَادَيْنَاهُ أَن يَا إِبْرَاهِيمُ ﴿١٠٤﴾ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ ﴿١٠٥﴾ إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ الْبَلَاءُ الْمُبِينُ ﴿١٠٦﴾ وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾

**«(Ата белән угыл) икесе дә Хак әмеренә ризалык күрсәтеп, Ибраһим улын йөзтүбән яткыргач, Без: «Әй Ибраһим! Тәхкыйк, төшеңне растадың», – дидек. Дөреслектә, Без изгелек кылучыларны шулай бүләклибез. Бу ачыктан-ачык бер сынаудыр. Инде Без аны олы бер корбан белән йолып алдык».**

«Саффат /Сафта Торучылар», 37:103–107

Шул рәвешле, Аллаһы Тәгалә аның тугрылыгын кабул итә һәм улы урынына корбан итәргә дип күкләрдән бер тәкә иңдерә. Бәс, безнең дә чалган корбаннарыбыз Хак Тәгаләгә тугрылыгыбызның бер дәлил вә исбатыдыр.

Корбан – үзең өчен аерата кадерле булган нәрсәне Аллаһыга багышлаудыр. Илаһи рәхмәт ошбу корбанны итен мохтаҗларга тарату мөстәхәб булган хайван белән алыштырган. Моның хикмәтен бигрәк тә авыл җирендә яшәүчеләр, тырышып-кадерләп үстергән малкайларын Аллаһы ризалыгы өчен чалган тәкъва мөселманнар яхшы аңлый булса кирәк. Күңелен кызгану хисе биләп алса да, ул Аллаһы Тәгалә әмеренә хилафлык кылмас. Хак Тәгалә «Корбан чал!» дип боерган икән, адәм баласы бу әмергә буйсынып, үзе өчен кадерле булган әйберен корбан итәргә тиеш. Чөнки Аллаһының фәрманы бар нәрсәдән өстендер.

Корбан – бик борынгы заманнардан килгән гыйбадәт. Аллаһыга якынайтучы гыйбадәт буларак, корбан төшенчәсе булмаган бер генә дин дә юктыр, мөгаен. Аның башы Адәм ﵇ чорына ук барып тоташа. Изге Коръәндә Адәм пәйгамбәрнең ﵇ ике улы Кабил белән Һабилнең корбан чалу кыйссасы бәян ителә:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ ابْنَيْ آدَمَ بِالْحَقِّ إِذْ قَرَّبَا قُرْبَانًا فَتُقُبِّلَ مِنْ أَحَدِهِمَا وَلَمْ
يُتَقَبَّلْ مِنَ الْآخَرِ قَالَ لَأَقْتُلَنَّكَ ۖ قَالَ إِنَّمَا يَتَقَبَّلُ اللَّهُ مِنَ الْمُتَّقِينَ ﴿٢٧﴾

**«Аларга Адәмнең ике угылының хәбәрен хаклык белән ирештер. Менә алар икесе дә корбан китерде, берсенеке кабул ителде, ә икенчесенеке исә кабул ителмәде».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5:27

Бу вакыйганың асылы шуннан гыйбарәт: ике бертуган арасында гауга кубып, мәсьәләнең хәл ителүе өчен икесеннән дә корбан сорала. Кемнеке Аллаһы тарафыннан кабул кылынса, шул – хаклы. Көтү көтеп көн күргән Һабил корбанлыкка иң кадерле малын – симез тәкәне куя. Иген игеп, шактый мая тупларга өлгергән Кабил исә корбанга дип сәләмә генә бер бодай көлтәсен китереп сала. Кабилнең корбаны кабул ителми.

*«Корбан» китабыннан,*

*«Хозур» нәшрият йорты, 2016*

# Корбан чалуның әһәмияте

Корбан бәйрәмендә корбан чалу – малың белән башкарыла торган вәҗиб гыйбадәт. Моның хакындагы вәхи хиҗрәтнең икенче елында иңдерелгән.

Корбан Аллаһ исеменә атап чалына һәм Ул биргән нигъмәтләр өчен шөкер итү билгесе, Аның рәхмәтенә якынайтучы сәбәп булып тора. Пәйгамбәрнең ﷺ бер хәдисендә әйтелгән: «Саран кешеләрнең иң хәерсезләре – корбан итеп хайван чалырга тиеш булып та корбан чалмаганнары». Корбан бәйрәмендә Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ корбан итеп ике баш хайван чала торган булган. Берсен – үзе өчен, ә икенчесен – үзенең өммәте өчен. Җитәрлек байлыгы булган һәм Раббыларының тагы да күп нигъмәтләренә лаек булырга теләгән мөселманнар шулай ук ике баш яки күбрәк хайванны корбан итеп чала ала.

Корбан чалу йоласы җәмгыятьтәге социаль элемтәләрне рәткә сала. Байлыгы булган кешеләргә, Аллаһы Тәгалә каршында һәм җәмгыять каршында булган кайбер бурычларын хәтерләтә. Күпмедер дәрәҗәдә мөмкинчелекләре бар икән, алардан игелекле максатларда файдаланырга өйрәтә. Әгәр матди кыйммәтләргә өстенлек бирелгән җәмгыятьтә, фәкыйрьләр турында кайгыртасы урынга, халык аларны күрмәмешкә салышырга мөмкин. Аллаһы Тәгалә исә кешеләрнең аңындагы әлеге ялгышлыкны төзәтеп, киресенчә, ярлы халык турында, аның тамагын туйдыру хакында кайгыртырга әмер, чөнки без барыбыз да Раббыбыз каршысында бертигез. Бөтен кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булырга кирәклеге турында Аллаһы Тәгалә шуны әйтә: **«Гыйбадәт кылыгыз Аллаһка, Аңа тиң кушмагыз. Гел яхшылык эшләгез ата белән анага һәм барлык якыннарга, ятимнәргә, фәкыйрьләргә,якын күршеләргә һәм ерак күршеләргә,якын дуска, юлчыга һәм сезнең**

**карамакта булган барча кешегә. Аллаһ артык горурланып, масайганны яратмас».**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Аллаһы Тәгаләнең әмере Пәйгамбәрнең ﷺ сүзләрендә дә чагылыш тапкан: «Үзе тук була торып та, күршесе ач булган кеше бездән түгел (ягъни аның иманы зәгыйфь)»[1].

Пәйгамбәрнең ﷺ әйткәненнән аңлашылганча, хәленнән килгән һәр кешегә башкаларга ярдәм итү вазифасы йөкләнгән.

Корбан чалу йоласы кешеләр арасында булган аерманы бетерә, аларны үзара якынайта һәм дуслык, бердәмлек хисләрен ныгыта, чөнки бәйрәм көннәрендә мөэминнәр гел игелекле эшләр генә эшләргә омтылалар, якыннарына карата гына түгел, бөтен кешеләргә карата яхшы мөгамәләдә булырга тырышалар, сәдака таратырга ашыгалар һәм шулай ук корбан итеп чалынган хайван итен бәйрәм күчтәнәче итеп кешеләргә өләшәләр. Бәйрәм көннәрендә һәр мөселманның өендә кунакчыллык һәм юмартлык хисе хакимлек итә.

Мондый бәйрәм көннәре бөтен дөнья күләмендә тынычлыкка юл ача, Җир йөзендә яшәгән халыкларның барысы үзара килешеп һәм бердәм булып яшәсен өчен мөмкинчелек тудыра. Корбан бәйрәме кешеләрне берберсен хөрмәт итәргә, үзара ярдәмләшергә өйрәтә, аларны игелекле һәм фидакарь булырга өйрәтә. Корбан чалуның мәгънәсен аңлавы кыен түгел. Раббыбызның гаделлеген, гыйлемен һәм хикмәтен үз эченә алган корбан чалу йоласы бөтен дөньяда яшәүче, ачлыктан, хәерчелектән интеккән кешеләрнең тамагын туйдыруга юнәлтелгән, чөнки ул мескеннәр дә башкалар кебек кешечә яшәргә хокуклы. Әгәр уйлап карасаң, байлыгы булган кеше ничәмә-ничә кешегә шатлык китерә ала, иң мөһиме, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә һәм рухи кәнәгатьләнү хисен тояр-

[1] Хәйсами, «Мәҗмәүз - Зәвәид», VIII, 167

га мөмкинлек ала. Әмма кайбер бай кешеләр үзләрен гомерләре буенча мондый хисләрне тоюдан мәрхүм итә.

Шул рәвешле, чалынган корбан мөэминнең рухын сафландырып кына калмый, җирдәге мохтаҗ халыкның беразга гына булса да тамагын туйдырырга мөмкинлек бирә.

## Кемнәргә корбан чалу вәҗиб

Аллаһы Тәгалә әйткән: **«Шуның өчен намаз кыл син, корбан чал Раббың өчен».**

«Кәүсәр», 108:2

Корбан чалу вәҗиб булсын өчен кеше түбәндәге шартларга туры килергә тиеш:

1. Мөселман булырга.
2. Акыллы булырга.
3. Балигъ булырга.
4. Сәфәрдә булмаска.
5. Көмеш яки алтын нисабы күләмендә мал-мөлкәткә ия булырга (бер ел буе нисабка хуҗа булу шарты юк).

## Корбан чалу кайчан һәм ничек башкарыла

Корбанны Корбан бәйрәменең элекке өч көнендә чалалар, ләкин моны бәйрәмнең беренче көнендә эшләсәң хәерлерәк. Бәйрәм намазы укылган шәһәрләрдә һәм авылларда корбанны шул намаздан соң чалалар. Бәйрәм намазы укылмаган авылларда корбан чалуны таң аткач башкаралар. Хәдистә әйтелгән: «Бүген (ягъни бәйрәм көнендә) безнең беренче эшебез – бәйрәм намазын уку, аннары корбан чалу. Кемнәр шулай

эшләсә, сөннәтебезне үтәр. Кемдер моннан (намаздан) алдарак чалса, гаиләсенә бирелгән гади ит булып саналыр»[1].

Төнлә белән корбан чалу мәкруһ булып санала, чөнки караңгы булганлыктан кеше ялгышлык җибәрергә мөмкин. Корбан чала торган урын яхшылап яктыртылса, бу гамәл мәкруһ булмый.

Бәйрәмнең өченче көнендә ахшам намазыннан соң корбан чалырга ярамый.

Үзе чала белгән кеше корбанны үзе чала, белмәгән кеше исә берәр бүтән мөселманга әйтеп чалдыра ала. Корбанны Китап әһелләренә чалдыру мәкруһ булып санала, бу эшне мөшрикләргә, динсезләргә тапшыру бөтенләй рөхсәт ителми. Корбан өчен әзерләнгән хайваннарны яхшы карарга кирәк. Суйган чакта хайванны газапламас өчен, кисә торган пычаклар үткен булырга тиеш. Чала торган җиргә хайванны аякларыннан өстерәп китерергә ярамый; хайванны яткырып бәйләгәннән соң, суяр өчен пычак эзли башлау яисә пычак кайрау яхшы түгел; бер хайванны икенчесе каршында чалу хуш күрелми. Корбан чалу эшенең мондый һәм күп кенә бүтән нечкәлекләре, Аллаһның җирдәге барлык мәхлукләренә карата бик тә сак һәм игътибарлы булырга кирәклеген аңлата.

Түбәндәге ниятне әйтергә: «Йә Аллаһы Тәгалә, ризалыгыңны алыр өчен корбан китерәм». Хайванның башын кыйблага каратып, сулъяк сыртына яткырсаң яхшырак була. «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» сүзләрен әйтеп, хайванның бугазын, сулыш алу юлларын һәм муендагы кан тамырларын кисәргә кирәк. Суйган вакытта тәшрик тәкбирен әйтеп торырга кирәк:

اَللّٰهُ اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ لَا إِلٰهَ إِلَّا اللّٰهُ وَاللّٰهُ اَكْبَرُ اللّٰهُ اَكْبَرُ وَلِلّٰهِ الْحَمْدُ

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, лә иләһә илләллаһ. Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр вә лилләһил хәмд

---

[1] Имам Бохари, «Гидәин», 8,10; «Әдхә», 1,11; имам Мөслим, «Әдхә», 7

«Аллаһ Бөек, Аллаһ Бөек, Аллаһтан башка илаһ юк. Аллаһ Бөек, Аллаһ Бөек, бар мактаулар Аллаһка».

Һәм түбәндәге аятьне әйтеп торырга кирәк:

**«Әйт: Укыган намазларым вә бугазлаган корбаннарым фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә эшләнәләр вә тере булуым һәм үлмәклегем бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһы Тәгалә эшедер. Аллаһның һич тиңдәше юк, вә мин һичкемне һичнәрсәне Аңа тиңдәш кылмаска, фәкать Аллаһка гына халис кол булырга Аның тарафыннан боерылдым һәм мин мөселманнарның әүвәлемен».**

«Әнгәм / Терлек», 6:162-163

Хайванның җаны тәненнән аерылганчы, башын бөтенләй кисеп алырга яки тиресен туный башларга кирәкми. Корбан чалган вакытта «Бисмилләһи» дип әйтү җитми, «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» дип әйтергә тиешле. Корбан суючы кеше белә торып «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» дип әйтмәсә, хайванның ите хәрамга әйләнә. Әгәр әйтергә онытса, анысы гафу ителә.

## Корбан итеп чалынган хайванның ите белән тиресен ни эшләтергә

Корбан итен кешеләргә таратырга яисә үзеңә калдырырга була. Аны өч өлешкә бүлсәң хәерлерәк (мәндүб): бер өлешен туганнарга һәм дусларга таратырга, икенче өлешен фәкыйрьләргә өләшергә, ә өченче өлешен үзеңә калдырырга.

Корбан итеп чалынган хайванның итен сатарга яисә итчегә түләр өчен кулланырга ярамый, мәкруһ була. Тирене үзең куллансаң була, һәм

шулай ук аны мохтаҗларга яисә хәйрия оешмасына бирергә дә була. Корбан итен мөселман булмаган кешеләргә күчтәнәч итеп бирергә ярый.

## Нәзер корбаны

Нәзер корбаны – кеше үз теләге белән үзе өчен вәҗиб иткән корбан. Нәзер корбаны ике төрле була:

1. Бернинди шарткада бәйле булмаган нәзер. Мәсәлән, «Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалырмын», – дип. Әлеге очракта кеше нәзер корбанын кайчан теләсә шул вакытта чалырга мөмкин.

2. Берәр төрле шартка бәйле нәзер. Мәсәлән, кемдер: «Әгәр фәлән кеше авыруыннан савыкса, мин Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалачакмын», – дип әйтсә, әлеге авыру кеше сәламәтләнгәннән соң, бу сүзләрне әйткән кеше өчен корбан чалу вәҗиб була. Бу очракта корбанны алданрак та, теләгең тормышка ашканны көтеп тормастан да чалырга була.

Нәзер корбаны итеп чалынган хайванның итен, бу хайванны корбан итеп китергән кешенең үзенә ашарга ярамый, һәм шулай ук аның хатынына, ата-анасына, әби-бабасына, балаларына һәм оныкларына да бу итне ашау тыелган. Моннан башка, нәзер корбаны итен шулай ук хәлле дип саналган, ягъни нисабка хуҗа булган кешеләргә дә ашарга ярамый.

Корбан бәйрәмендә, шулай ук, вафат булган туганнарга багышлап та корбан чалалар. Бу очракта корбан итен таратсаң да, үзеңә калдырсаң да була. Ә васыять буенча чалынган корбан итен мохтаҗларга өләшәләр.

## Корбан итеп чалырга рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән хайваннар

Бары тик шул хайваннарны гына корбан итеп чалырга мөмкин: сарык, кәҗә, сыер, буйвол һәм дөя. Кәҗә белән сарык ким дигәндә бер яшьлек булырга тиеш, сыер белән буйвол – кимендә ике яшьлек, дөягә биш

яшьтән дә ким булмаска тиеш. Әгәр зурлыгы ягыннан бер еллык сарык кебек булса олы гәүдәле алты айлык сарыкны да корбан итеп чалырга була. Кәҗә өчен бер яшькә җиткән булуы катгый шарт.

Хайванны берничә көн алданрак сатып алып, абзарда тотсаң бик яхшы була. Бер-берсенә охшаган берничә сарык бер абзарда тотылса, үз сарыгыңны тамгаласаң яхшырак.

Бер сарыкны яки бер кәҗәне бер кеше генә корбан итеп китерә ала. Бер сыерны, буйволны яки дөяне бердән алып җидегә хәтле кеше корбан итеп китерә ала. Гаиләдән аны тәэмин итеп торучы бер кеше корбан чалса җитә.

Кошларны (әтәч, тавык, үрдәк һ.б.) һәм куш тояклы кыргый хайваннарны (мәсәлән, кыр кәҗәсе, кыргый буйвол һ.б.) корбан итеп чалмыйлар.

Корбан итеп чалыначак хайванның кайбер җитди булмаган кимчелекләре булырга мөмкин, мәсәлән, мөгезе бераз кителгән, берничә теше бозылган булса яки бераз аксакласа. Ләкин хайванны корбан өчен яраксыз иткән кимчелекләр дә бар:

1. хайванның бер яисә ике күзе дә сукыр булса;

2. бер яисә ике мөгезе дә төбенә тикле сынган булса;

3. колагының яки койрыгының яртысы киселгән булса;

4. хайван аксак булып, аякларында басып тора алмаса;

5. тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;

6. хайван ашый алмаслык дәрәҗәдә тешләренең күбесе бозылган булса;

7. хайван чирле булса;

8. хайван бик тә хәлсез булса;

9. имчәкләре бозылган булса;

10. кәҗәнең яисә сарыкның бер имчәге, сыер белән буйволның ике имчәге корыган булса.

## Хәләл һәм хәрам итләр

Ислам кануннары буенча, мөселманнарга ашарга рөхсәт ителгән хәләл ит булып йорт хайваннарының һәм йорт кошларының ите санала, шул хисаптан, сыер, үгез, дөя, ат, сарык, кәҗә, тавык, торна, тәвә кошы, күгәрчен, каз итләре. Шулай ук һәртөрле балык рөхсәт ителгән.

Әбү Хәнифә фикере буенча ат итен ашау мәкруһ тәнзиһи (катгый булмаган рәвештә тыелмаган нәрсәләр) хөкеменә керә. Элек атларны атланып йөрер өчен дә, йөк ташыр өчен дә, сугыш кырында да кулланганнар. Әлеге фикер шуңа таянып әйтелгән.

Югарыда санап кителгән хайваннарның һәм кошларның итләре хәләл булсын өчен, хайван сую йоласын үтәргә кирәк. Бу йола, суйган чакта Аллаһы Тәгаләнең исемен искә алып («Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» диеп), хайванның муен тамырларын, бугазын һәм сулыш юлларын кисүдән гыйбарәт. Әлеге йоланы үтәүче кеше мөселман һәм үз акылында булырга тиеш.

Зур казык тешләре булган һәм үләксә ашый торган ерткыч хайваннарның итен ашау тыелган. Аларга арысланнар, юлбарыслар, бүреләр, шакаллар, сыртланнар, гепардлар, төлкеләр, аюлар, этләр, кәлтә еланнар һ.б. керә. Хайван сую йоласын үтәгән очракта, үлән ашаучы кыргый хайваннарның (болан, кыргый сыер, куян һ.б.) итен ашарга рөхсәт ителә. Утлы ату коралы кулланып хайван аулаганда, аткан мизгелдә «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» диеп, Аллаһның исемен искә алырга кирәк. Әгәр дә хайван яраланган гына булса, аучы кулына пычак алып, сую йоласын тәмамларга тиеш була.

Ишәк, качыр, мәче, тиен, фил итләрен һәм ерткыч кошларның (бөркет, лачын, кара гриф, карга, карчыга, тилгән) итен, ярканатларның итләрен шулай ук ашарга ярамый. Дуңгыз итен ашау катгый тыелган.

Җирәндерә торган хайваннарның итен һәм бөҗәкләрне дә ашамыйлар, мәсәлән, тычканнарны, бакаларны, еланнарны, чебеннәрне,

коңгызларны, күбәләкләрне, чаяннарны. Сигезаяк, моллюск, диңгез кысласы һәм башка балыклар санына кермәгән диңгез хайваннарының ите дә шулай ук ашарга яраксыз булып санала. Коры җирдә дә, диңгездә дә яши торган сөйрәлүче хайваннарның итен дә ашамыйлар. Мәсәлән, ташбака, крокодил итен.

*«Ислам дине нигезләре» китабыннан,*
*«Хозур» нәшрияте, 2017 ел*

# Хаҗ

# Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ хаҗы

Җәбир ؓ Расүлүллаһның хаҗын җентекле итеп тасвирлаган. Җәгъфәр ибн Мөхәммәд әтисенең болай дип сөйләгәнен тапшырган: «Без Җәбир ибн Габдуллаһка ؓ килдек. Ул аның янына кемнәр килүе белән кызыксынды. Чират миңа җиткәч, (аның соравына) мин: «Мин – Мөхәммәд ибн Гали ибн Хөсәен», – дидем. Ул кулларын минем башыма сузды, аннан (киемемнең) өске һәм астагы төймәсен ычкындырды да, күкрәгемә кулын куйды (ул вакытта мин яшь егет идем) һәм: «Рәхим ит, абыемның улы! Нәрсә турында телисең, шуны сора», – диде. Һәм мин инде сукырайган Җәбиргә сораулар бирә башладым. Намаз вакыты җиткәч, ул намаз укый башлады. (...)

Намаздан соң мин: «Миңа Пәйгамбәребез ﷺ хаҗы хакында сөйлә», – дип үтендем. (Шуннан соң Җәбир тугыз бармагын бөгә һәм) «Расүлүллаһ ﷺ (Мәдинәдә) тугыз ел яши, алар дәвамында хаҗ кылмый. Ә унынчы елда ул кешеләргә хаҗ кылырга ниятләвен белдерә. (Шуннан соң) Мәдинәгә бик күп кеше җыела, аларның һәркайсысы Пәйгамбәр ﷺ эшләгәннәрне кабатларга тырыша. (Күпмедер вакыт үткәч) без аның белән бергә юлга чыктык, ә Зөл-Хөләйфә дигән урынга җиткәч, Әсма бинт Гомәйс Мөхәммәд ибн Әбү Бәкерне ؓ таба. (Бала тапканнан соң) ул аңа нишләргә кирәклеген белергә дип, Пәйгамбәргә кеше җибәрә. Расүлүллаһ: «Госел ал, озын һәм киң тукыма белән кан килгән урыныңны бәйлә һәм ихрамга керә аласың», – ди.

Шуннан соң Пәйгамбәр ﷺ мәчеттә ике рәкәгать намаз укый һәм әл-Кәсвага атлана. Дөя Әл-Бәйдкә җиткәч, мин бар яктан – алдан да, арттан да, уңнан да, сулдан да – аны җәяүлеләр һәм атланган кешеләр әйләндереп алганын күрдем. Пәйгамбәргә ﷺ Коръән аятьләре иңдерелә иде, аңа аларның мәгънәсен билгеле иде, һәм ул нәрсә эшләсә, без шуны кабатладык. (Башта) ул: «Ләббәй-кә, Аллаһуммә, ләббәй-кә, ләббәй-кә,

лә шәрикә ләкә, ләббәй-кә. Иннәл-хәмдә вә нигъмәтә ләкә вәл-мүлкә, лә шәрикә ләкә» («Мин Синең каршыңда, Аллаһым, мин Синең каршыңда, мин Синең каршыңда, Синең һичбер тиңдәшең юк, мин Синең каршыңда. Дөреслектә, барча мактау, нигъмәт һәм өстенлек Сиңа хас. Синең тиңдәшең юк»), – сүзләрен әйтә башлады һәм кешеләр кычкырып аларны кабатлады. Пәйгамбәребез моңа каршы берни әйтмәде һәм тәлбия сүзләрен кабатлавын дәвам итте». Җәбир болай ди: «Без бары хаҗ кылырга ниятләгән идек, (чөнки бу вакытта) гомрә (кылырга мөмкин булуын) белмәдек. Әмма без Пәйгамбәр белән бергә (Кәгъбәгә) җиткәч, ул (Хәҗәре әсвәд урнаштырылган) почмакка тиде, аннан соң тиз һәм вак адымнар белән өч тапкыр, һәм гадәти адым белән дүрт тапкыр (Кәгъбәне урады). Шуннан соң ул: **«Мәкам Ибраһимны намаз урыны итегез»** (2:125), – сүзләре белән мәкам Ибраһимга килде, һәм бу урын аның белән Кәгъбә арасына туры килерлек итеп басты. Һәм «Әл-Ихлас», «Әл-Кәфирун» сүрәләрен укып, ике рәкәгать намаз укыды. Шуннан соң ул (Кәгъбәнең) почмагына кайтып (Хәҗәре әсвәдне) үпте. Чыккач, ул Сафага юнәлде. Аңа килеп җиткәч: **«Сафа һәм Мәрвә таулары, әлбәттә, Аллаһка гыйбадәт кыла торган урыннардандыр»** (2:158), – аятьнең өлешен укыды. Аннан соң: «Мин Аллаһ башлаганнан башлыйм», – сүзләре белән Сафадан башлады һәм тауга менгәч (Кәгъбәне күреп) «Ләә иләһә илләл-лааһ», «Аллаһу Әкбәр» сүзләрен әйтеп: «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаек зат юк! Барча өстенлек, мактау Сиңа хас. Аның бар нәрсәгә дә, һичшиксез, көче җитәрлек. Аллаһтан башка гыйбадәткә лаек зат юк, Ул колына булышып, сүзендә торды, ялгызы бердәм кабиләләрне җиңде», – диде. Ул бу сүзләрне өч тапкыр кабатлады, һәм һәр әйткән саен Аллаһка догалар белән мөрәҗәгать итте. Аннан соң ул аска төште. Үзәнлеккә төшеп җиткәч, Мәрвәгә таба йөгерде. Тауга килеп җиткәч, янә адымга күчте. Мәрвәгә менгәч, ул Сафада эшләгәннәрне кабатлады.

Ә Мәрвәгә соңгы тапкыр менгәч: «Әгәр мин хәзер белгәннәремне элегрәк белгән булсам, корбан хайваннарын үзебез белән кудыртып алып килмәгән булыр идем. Һәм гомрә кылыр идем. Үзләре белән корбан хайваннары булмаганнар ихрамнан гомрәдән соң (бу кылганнарын гомрә дип санап) чыксын», – диде. Сурака ибн Мәлик ибн Җүгшүм: «Пәйгамбәребез, бу безгә быел гына кушылганмы, әллә һәрвакыт шулай эшләргәме?» – дип сорый. Расүлүллаһ ﷺ кулларын бармакларын бер-берсе белән аралап куша да: «Гомрә хаҗга керә, гомрә хаҗга керә. Бу мәңгегә, мәңгегә», – дип җавап кайтара.

Бу вакытта Йәмәннән Гали Пәйгамбәр өчен корбан хайваннарын куып китерә һәм ихрамнан чыгучылар арасында Фатыйманы күрә. Ул буялган тукымадан тегелгән кием кигән һәм күзенә сөрмә тарткан була. Гали моны хупламавын белдерә, ә ул: «Моны миңа әтием боерды», – дип әйтә. (Инде соңрак) Гыйракта булганда Гали еш кына болай дип сөйли иде: «Шуннан соң мин Пәйгамбәр янына барып Фатыйманы шелтәләдем һәм аның фикерен сорадым. Расүлүллаһ: «Ул дөресен әйткән. Ул дөресен әйткән», – дип җавап кайтара. Аннан соң: «Хаҗ кылыр алдыннан син ни дип әйттең?» – дип сорый. Мин: «Йә Раббым, ихрамга Синең илчең нинди максат белән керсә, мин дә шул максат белән керәм», – дип җавап бирдем. Пәйгамбәр: «Мин үзем белән корбан хайваннары алып килдем, шуңа сиңа да ихрамнан чыгарга кирәкми», – ди». Гали Йәмәннән һәм Пәйгамбәр инде куып китергән корбан хайваннарының саны исә йөз була.

Шуннан соң Пәйгамбәрдән һәм үзләре белән хайваннар куып китерүчеләрдән кала башкалар ихрамнан чыга, чәчләрен кыскарта.

Ә «әт-тәрвия» көне (8 нче зөл-хиҗҗә) җиткәч, алар барысы да Мина үзәненә бара һәм хаҗ кылырга дип ихрамга керә. Пәйгамбәр үзәнгә ﷺ дөясенә атланып бара. Минада ул өйлә, икенде, ахшам, ястү һәм иртәнге намазны укый. Монда кояш чыкканны көтә һәм Нәмир тавында киез чатырын куярга боера.

Шуннан соң Расүлүллаһ юлга кузгала. Корәешләләр аны Мөздәлифәдә (Әл-Мәшгарәл-хәрамда) туктар дип уйлый. Җаһилият чорында корәешләләр анда һәрвакыт туктаган. Әмма Пәйгамбәр Гарәфәткә җиткәнче, бер җирдә дә тукталмый. Намирда аның чатыры инде куелган була, һәм ул шунда туктый. Кояш баюга таба (төштән соң) ул Әл-Кәсваны китерүләрен сорый, аңа атланып Гарәфәт үзәненә төшә һәм кешеләргә хөтбәсе белән мөрәҗәгать итә[1].

(Хөтбәдән соң Биләл) азан әйтә һәм намаз башлануын хәбәр итә, Пәйгамбәр ﷺ (кешеләр белән) өйлә намазын укый. Аннаң соң Биләл тагын намаз башлануын хәбәр итә, Пәйгамбәр (кешеләр белән) икенде намазын укый. Ә бу ике намаз арасында ул башка бернинди намазлар да укымый. Аннан соң Пәйгамбәр Гарәфәткә юнәлә, анда дөясе Әл-Кәсвәне (Әр-Рахмә тавы итәгендә яткан) ташларга таба шулай итеп бора ки, җәяүлеләр уза торган юл Пәйгамбәр каршында була һәм ул йөзе белән кыйблага баса. Шул рәвешле ул кояш баеганчы тора. Аннан соң Пәйгамбәр ﷺ артына Усәмәне утырта һәм тезгенне шундый нык тарта, Әл-Кәсваның башы иярнең уртасына тия. Ул кешеләр тыныч булсыннар, ашыкмасыннар өчен уң кулын алга суза. Ниндидер калкулыкка җиткән саен, ул дөясе өскә менгәнче тезгеннәрне бераз бушата, Мөздалифәгә җиткәнче шулай бара. Анда ул ахшам һәм ястү намазларын укый. Бу намазларга бер азан әйтелгән була, намаз башлануы ике тапкыр аерым хәбәр ителә, алар арасында бернинди нәфел намазлар укылмый. Аннан соң Пәйгамбәр ﷺ таң беленә башлаганчыга кадәр ял итә. Таң беленә башлагач, азан һәм камәттән соң ул иртәнге намазны укый. Аннан соң Әл-Кәсвәгә атланып Әл-Мәшгарәл-хәрамга килә, йөзен кыйблага юнәлдереп, таң атканчы Аллаһка догалар кыла, «Аллаһу Әкбәр», «Ләә иләһә илләл-лааһ» сүзләрен кабатлый. Кояш чыкканчы Пәйгамбәр ﷺ артына матур чәчле, ак тәнле, матур кыяфәтле булган Әл-Фазыл ибн Габбасны утыртып кузгала. Пәйгамбәр ﷺ юлда

---

[1] Хөтбәнең тәрҗемәсе хәдистән соң китерелгән.

булганда, яныннан хатын-кызлар үткән. Алар дөяләрдә махсус корылган өсте бөркәүле чатырларда барган. Әл-Фазыл аларга карый башлый, ә Пәйгамбәр ﷺ аның йөзен кулы белән каплый. Әл-Фазыл йөзен башка якка бора һәм тагы карый башлый. Пәйгамбәр аның йөзен башка яктан каплый, әмма Әл-Фазыл кабат йөзен бора һәм карый башлый һәм бу алар Мөхассар үзәненә барып җиткәнче шулай дәвам итә. Анда Пәйгамбәр дөясен ашыктыра башлый, урта юлдан әл-җәмрат әл-кубра (баганасына) янында үсеп утырган агач яклап килә. Үзәннең эчке, түбән ягыннан (бу баганага) кечкенә җиде таш ата, ыргыткан саен «Аллаһу Әкбар» сүзләрен кабатлый. Аннан соң корбан чалу җиренә юнәлә һәм үз куллары белән алтмыш өч (дөя) корбан чала. Калганнарын исә Гали чала. Пәйгамбәр казанга чалынган һәр дөянең ит кисәген салып пешерергә боера. Ә ит пешкәч, алар икесе дә ит тә, шулпа да ашый. Аннан соң Пәйгамбәр ﷺ атланып Кәгъбәгә юнәлә. Мәккәдә ул өйлә намазын укый, соңыннан хаҗиларны Зәм-зәм суы белән тәэмин итүче Габделмотталиб нәселе кешеләре янына килә һәм: «Миңа да су алыгыз, әгәр кешеләр сезнең белән су эчерү хокукы өчен көрәшә башлавыннан курыкмасам, мин үзем дә сезнең белән су алыр идем», – дип әйтә. Алар аңа бер савыт су тапшыра һәм Пәйгамбәр эчә», – дип сөйли».

*Имам Мөслим «Сахих», Хаҗ китабы, 51 бүлек:*
*Пәйгамбәрнең хаҗы турында, 714 санлы хәдис*

# Пәйгамбәребезнең ﷺ саубуллашу хөтбәсе

Барча мактауларыбызны Аллаһка житкерәбез! Без мактыйбыз Аны, Аның ярдәмен һәм гафу итүен сорыйбыз һәм бөтен гамәлләребездә Аңа мөрәҗәгать итәбез.

«Әй, кешеләр, сүзләремне яхшы тыңлагыз, чөнки белмимен ки, моннан соңгы елда монда сезнең белән очрашачакмынмы, юкмы, һич билгеле түгел. Дикъкать итегез ки, моннан соңгы елда мине тагын башка күрмәячәксез».

Кешеләр! Бу көннәрегез ничек мөкатдәс булса, бу аегыз һәм шәһәрегез (Мәккә) ничек мөкатдәс булса, сезнең җаннарыгыз, малларыгыз һәм намусларыгыз да шундый мөкатдәс һәм изгедер. Яхшы белегез ки, җаһилият заманасына караган һәрнәрсә минем аякларым астына салынган. Әй, кешеләр, иртәгә Раббыгыз белән кавышачаксыз һәм бүгенге һәр хәл һәм хәрәкәтегез өчен соралачаксыз. Шуңа күрә миннән соң иске адашканлыгыгызга кайтып, бер-берегезнең башларыгызны чабар булмагыз.

Бу васыятемнне мондагылар монда булмаганнарга да җиткерсен. Бәлки дә алар ишеткәннәрне сездән яхшырак саклый белерләр.

Әй кешеләр, кемдә кеше мал-мөлкәтеннән берәр әманәт булса, аны хуҗасына кайтарсын. Фаизның һәр төре хәрамланып, аякларым астына салынгандыр. Ләкин тиешле бурычны кайтару да кирәк. Золым итеп, золым күрүчеләр булмагыз. Шуңа күрә фаизның Аллаһ әмере белән хәрам икәнлеген белегез. Элеккеге җаһилият заманасыннан калган бу ямьсез гадәтнең һәртөрлесе аягымның астындадыр. Беренче итеп юк итәчәгем фаиз, Габделмотталибның улы Габбаска тиешле булган бурычтан үскән фаиздыр.

Әй кешеләр, элеккеге җаһилият заманасыннан калган кан учларының бөтенесе юкителмеш. Беренче итеп гафу кылыначак кан үче, Габделмотталибның оныгы Рабиганың кан үче.

Әй кешеләр, шайтан сезнең бу туфракларыгызда яңадан тәэсир һәм хакимиятен кору өчен көчен мәңгегә югалтмыш. Ләкин сезгә хәрам кылган шушы олы гөнаһлардан тыш кечкенә саналган гөнаһларга үрелсәгез дә, аны мәмнүн итәрсез. Шуңа күрә динегезне саклап калдыру өчен болардан да тыелыгыз.

Әй кешеләр! Хәрам айларның вакытларын күчерү – ул имансызлыкны куәтләндеру. Шул гамәл имансызларны начар гамәлләргә этәрә. Чөнки алар Аллаһ тарафыннан тыелган айлар санын бер елда рөхсәт ителгән дип таный, ә башка елда – тыя. Моның белән алар Аллаһ какшамас дип билгеләгәнне боза. Һәм алар Аллаһ үзгәрүчән дип билгеләгәнне какшамас дип таный.

Дөрестән, Җир вә Күкләр барлыкка килгәннән башлап, вакыт билгеле бер рәвешле үтә. Аллаһ өчен айларның саны – унике – аларның дүртесе изге айлар. Аларның өчесе җөмәдәил-ахыр белән шәгъбан арасындагы булган айлар бер-берсе артыннан килә: зөлкагдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм раҗәп.

Әй кешеләр, хатын хакларын күзәтү һәм бу хосуста Аллаһтан куркуыгызны үгетлимен. Сез хатыннарыгызны Аллаһның әманәте буларак алдыгыз, аларның намус һәм гыйффәтләрен Аллаһ исеме белән сүз биреп үзегезгә хәләл иттегез. Сезнең хатыннарыгыз өстендә хакларыгыз, аларның да сезнең өстегездә хаклар бар. Сезнең хатыннарыгыз өстендә булган хакларыгыз: аларның өй-йортларыгызга рөхсәтегез булмыйча беркемне дә кертмәүләре һәм әдәп саклаулары.

Хатыннарыгызның сезнең өстендә булган хаклары, аларны кием, ризык һәм торыр йорт белән тәэмин итүегездер.

Әй кешеләр, сезгә шундый бер әманәт калдырамын ки, әгәр аңа бөтен көчегез белән тотынсагыз, һич адашмаячаксыз. Ул әманәт Аллаһ китабы Коръәни Кәрим һәм Аллаһ расүленең сөннәтедер.

Әй кешеләр, сүземне яхшы тыңлагыз һәм яхшы хәтерләгез. Мөселман мөселманның кардәшедер. Дин кардәшегездән булган хакларын хөрмәтләмәү берегезгә дә хәләл түгел. Үзе генә рөхсәт биреп, кичермәгән булса.

Әй кешеләр, нәфселәрегезнең дә сезнең өстегездә билгеле хаклары бар. Шуңа күрә үзегезгә золым итүчеләр булмагыз.

Әй кешеләр, шөбһә юк ки, Аллаһ һәр хак сахибенә хаккын бирмештер. Варис өчен васыять кирәк түгел. Бала кемнең түшәгендә туган булса, шуныкыдыр. Ләкин зиначы мәһрүм калырга тиеш. Атасыннан башкасына, хуҗасыннан икенчесенә булганлыгын сөйләүче рәхмәтсез кеше өстендә Аллаһ фәрештәләренең һәм бөтен кешеләрнең ләгънәте бар. Моның кебекләрнең тәүбәләрен, нәфел гыйбадәтләрен, гаделлек һәм шәһадәтләрен Аллаһ кабул итмәс.

Әй кешеләр, Раббыгыз бер. Атагыз да бер. Барыгыз да Адәм балалары, Адәм исә туфрактан. Аллаһ янында иң кыйммәтлегез, Аңа иң күп хөрмәт күрсәткәнегездер. Шуңа күрә гарәпнең, гарәп булмаган бер кемсә өстендә бернинди өстенлеге юк. Өстегезгә әмер итеп берәр әгъзасы булмаган бер кол да булса билгеләнгән булса, Аллаһ Китабы белән идарә иткәнче, аны тыңлагыз һәм итәгать итегез.

Әй кешеләр! Иртәгә сезне минем турында сорарлар, сез ни нәрсә дип әйтерсез? «Аллаһ илчелеген башкардың, вазыйфаңны җиренә җиткердең, безгә васыять һәм үгеттә булдың» – диеп шәһадәт итәрбез. Моңа, Пәйгамбәребез шәһадәт бармагын күккә күтәреп: «Аллаһым шаһит бул! Аллаһым шаһит бул! Аллаһым шаһит бул!» – дип боерды.

Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

# Әдәби сәхифә

**Муса Акъегет**

# Хисаметдин мелла

*(Башы журналның 16 нчы санында)*

## IV

Кышкы вакытларда хикәябездә язылган затларның тормышлары гадәтенчә кичеп, дикъкатькә лаек бер нәрсә дә юк иде. Белешләребез Гали бай вә Сибгатулла әфәнде сәүдә эшләре белән мәшгуль улып, бүген – Мәскәүдә, иртәгесен – үз шәһәрләрендә, вә берсе көнне бер сәүдә үзәгендә вакыт уздыралар иде. Белешебез Бикбулат мулла үз вазифасын үтәү белән мәшгуль улып, муллаларга сәдака бирергә кирәклекне мәхәлләсенә киңәш итеп вә кисәтеп-искәртеп, аучы куян вә үрдәкне өмет итеп саклаганы кебек, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде.

Белешебез Хәнифә туташ тегү тегеп, китап укып вакыт уздырмакта иде. Белешебез Хисаметдин мелла, сабыйларны укытудан башка, арыш вә солыларын суктырып вә сатып кәсеп итеп, эшсез һич ятмас иде. Чөнки бу кеше укымыш улып, белер иде ки, кәсеп вә эш шәригать буенча намаз вә руза тоту кеби фарыз вә гыйбадәттер. Әмма кыш кичеп, яз башлары җитү белән Хисаметдин мелланың тормыш рәвеше бераз алмашынды. Кыш вакытына караганда хәзерге заманда шәһәргә күбрәк барырга гадәтләнде. Моның асыл сәбәбе бу ки, язганыбыз Хәнифә белән очрашуы меллага бик көчле тәэсир итте, шәһәргә барган вакыт Габбас агайга төшәр иде вә йортта, капка алдында, яисә урамда Хәнифәне очратырга тырышыр иде. Вә күп тапкыр морадына ирешер иде. Ахрысы, Хәнифә туташка да мелла белән очрашкалау хуш иде, чөнки туры килгән вакытларда кыз белән егет бер-берсенә карашып уза башладылар.

Мелланың шәһәргә еш килгәләп йөрүе дикъкатьсез калмыйча, беркөн Габбас ага да аңа эндәшеп: «Мелла, син шәһәрне ярата башладың, элекке вакытларга караганда хәзер күбрәк киләсең», – диде.

– Әйе, Габбас ага, һәрвакыт эшләр белән киләмен; аны-моны алырга кирәк була, үзем килмәсәм, минем эшемне кем эшләсен? Мин ялгыз бит, – дип җавап бирде Хисаметдин мелла.

Әмма бу килешендә Хисаметдин бик уңышлы вә бәхетле булды. Гүзәл Хәнифәнең чистарынып-таранып, киенеп-ясанып базарга чыгып китүен меллабыз тәрәзәдән күрде. Бераздан, халыкка белдермичә, гүя үз эшенә киткән кебек, мөсафирханәдән чыкты вә бер-ике йортны узгач, Хәнифә туташны куып җитте. Вә узып киткән чагында яшь егет әйләнеп караганда, кыз шәкәр иреннәрен вә энҗе тешләрен күрсәтеп көлеп алды. Мелла да, чын күңелдән шатланып, кызга гыйшыклык көлкесе илә җавапланды. Ике яшь, бер-берсенә багышып, бәхетле булдылар. Халыкның дикъкате тупланмасын дип, мелла, бераз калып, кызның артыннан китте. Хөрмәтле укучыларым, хәзер, әлбәттә, аңладыгыз ки, бу ике яшь бер-беренә гашыйк улмышлар.

Бара торгач, яшь кыз бер кибеткә керде. Шәһәр тротуарларында йөрегән адәмнәр һәрвакыт күп булганлыгы мәгълүмдер; кем кемгә кирәк, һәркем үз эшендәдер. Меллабыз, кибеттән ерак китмичә, йөренеп калды. Гаҗәптер ки, әүвәл вакытларда меллабыз кызны узып киткәндә күрсә дә бик шат була иде, ә инде хәзер бер күрү белән генә канәгатьләнмичә, морады янә артты. Вә хис итте ки, йөрәге кыз белән еш хәбәрләшмәкне, күрешмәк вә күзгә-күз сөйләшмәкне тели. Гыйшыклык шулай ул. Ахыр чиктә, кыз кибеттән чыккан вакыт, Хисаметдин мелла тугры аңа каршы барып узганда, әкертен генә бу сүзләрне әйтеп алды: «Хәнифә ханым, иртән таң илә бакчада сарайдан егерме бишенче казык төбендә, таш астында бер гаҗәеп нәрсә табарсыз. Аллаһ өчен, алып карагыз, үтенәмен!» – вә

сүзләрен бетереп узып китте. Хәнифә туташ исә, бер җавап та бирмичә, туры өенә китте. Хисаметдин мелла Әбүзәр бәккә юлланды.

Юлда күргәнебез Әбүзәр Дәүләтгилдиев яшьлек улып, ак йөзле, назлы вә нечкә-гүзәл табигатьле егет иде. Гимназиянең 7 нче сыйныфында укый иде. Бер рус өендә ике бүлмә фатир алып тора иде. Ике дус гадәттәгечә исәнләшеп күрешеп, гади нәрсәләр хакында бик озак сөйләшмәделәр, сүзләре Әбүзәр бәкнең башында озак вакытлар йөргән гомуми мәсьәләләргә күчте:

– Мелла, синең ышану-инануың бик яхшыдыр, – дип сүзгә кереште Әбүзәр бәк, – тугры әйтәсең, Ислам дине – иң хакыйкать дин, иң олуг дин, мин үзем дә шушы инануда торамын. Ләкин Аурупа әдипләренең кайберләре, Ислам диненә тиеп, кимчелекләр табалар. Ни өчен алар исламиятне аңламыйлар икән? Син миңа әйт, – диде.

– Нинди кимчелек табалар? – диде мелла.

– Мәсәлән, Аурупа әдипләре диер ки, исламият хатын җенесене хур күреп, кысынлыкта тота, имеш. Ислам хатыннары укый-яза аз белер, имеш.

– Ялганчыдыр синең Аурупаң, Ислам шәригате хатыннар хокукын һич тә кысмый; уку хакында исә хәзрәте Расүл димеш ки, гыйлем үгрәнмәк һәр мөслимгә һәм мөслимәгә фарыздыр. Безнең хатыннарыбыз надан булсалар, монда үзебез гаеплебез, юкса һич исламият түгел, – дип аңлатты мелла Хисаметдин. – Аурупаның Ислам дине хакында хата сүзе бик күп. Икенче мисал: аурупалыларның уйлавынча, исламият эшлексезлек вә ялкаулыкка ярдәм итә, имеш. Шуңа күрә Аурупа халкындагы, мәсәлән, инглиздәге кебек булмыйча, исламнарның кәсепчелеге вә һөнәрчелеге бик начар вә түбән дәрәҗәдә, имеш. Инглиз кебек кәсепче улмадыгыбызга сәбәп шулай ук үзебез, һич тә шәригатебез түгел. Киресенчә, шәригать юлы белән барсак, безгә инглиздән остарак булу тиеш килә. Шәригатебез урламак вә башка кебек яман кәсептән тыеп, яхшы вә хәләл кәсепне,

киресенчә, саваптан хисап итәр. Чөнки Расүле әкрәм саллаллаһе галәйһи вә сәллам димештер ки. (...)

– Бу хәдиснең мәгънәсе нәдер? – сорады Әбүзәр бәк.

– Бер кемсә хәләл кәсеп кылмакыннан арып кич үткәрсә, тиеш булыр аңа җәннәт. Вә кич үткәрер икән, Аллаһ ул кешедән разыйдыр, – җавап биреп, мәгънәсен әйтте Хисаметдин, һәм болай дип өстәде: ягъни хәдиснең мәгънәсенчә, эшлеклелек һәр җәһәттән файдалы вә саваплыдыр.

– Исламиятнең тырышлык вә гайрәткә өйрәтүен тарихка мөрәҗәгать итеп тә беләбез, – сүзгә кереште Әбүзәр бәк, – мәсәлән, әүвәлдә күчмә-кыргый тормышта вә хайван кебек яшәгән гарәпләр исламиятне кабул итү белән үзгәрделәр. Исламият нәтиҗәсендә тырышлык вә гайрәтләре артып, гарәпләр хәлифәләр заманында шундый бер мәмләкәт төзеделәр ки, ул вакыт гарәп җиреннән олуг җир юк иде: Азиядә булган Һинд елгасыннан Аурупадагы Пиренеи тауларына кадәр гарәп җире, Ислам дәүләте булып, бу дәүләттә исламият аркасында никадәр булдыклы хакимнәр, никадәр камил табиблар вә голәмәләр мәйданга чыкты! Кыскача әйткәндә, исламият нәтиҗәсендә гарәпләр мөстәкыйль бер мәдәният төзеделәр.

– Минем уйлавымча, бәян иткәнең олуг гарәп җиренең харап булуына сәбәп хәлифәләрнең исламият күрсәткән юлдан чыгуларыдыр. Юкса хәлифәләр Ислам шәригатенчә торсалар иде, ул дәүләт хәзер дә яшәр иде, – диде Хисаметдин мелла. Бу сүзләрне дигәч, Хисаметдин, сәгатенә багып: «Сәгать күп икән, миңа мәктүп язмак кирәк», – диде. Вакыт иреште. Каләм-кәгазь алып, башка бүлмәгә кереп, Хисаметдин Хәнифәгә бер мәктүп язды (...)

Хатны конвертка салып вә Әбүзәр илә саубуллашып, мелла мөсафирханәгә кайтты. Ястү намазы җитешкән вакытларда меллабыз, комган алып, гүя тәһарәткә чыкты вә бакчага кереп, сарай читеннән егерме дүрт казык санап, егерме бишенчесенә җитешеп, әлеге хатны куйды вә таш бастырды ки, җил очырмасын. Намазларын укып, эшләрен

тәмамлады. Фәкать бу төнне мелла бик рәхәтсез кичерде, чөнки җавап булырмы йә булмасмы? Шундый уй-фикерләр аның йокысын качырды. Икенче көн иртә Хисаметдин, бакчага чыгып, хатның куйган җирдән алынганлыгын күреп, гаять шат булды. Мәктүпне Хәнифә туташ кабул итеп алган икән, карап карыйк, җавап булырмы? Җавап булачак вакытны, ягъни икенче көн-иртә вакытны көтү меллабызга бик кыен булды. Бу бер көн меллага бик озын тоелды, һәрничек булса да шәһәрдә киереп, базарга, кибетләргә чыгып, көч-бәла илән бу көнне уздырды. Карынын кайгырткан гади кеше ураза вакытында көннең узуын ничек көтсә, шулай меллабыз да көннең тиз үтүен тели иде. Ниһаять, зарыгып көтелгән икенче көннең иртәсе булды. Вәгъдәләнгән вакыт җитте.

Хисаметдин мелла, кемгә дә белдермичә, гүя йөреп кермәк нияте белән бакчага чыкты вә теге казыкның янына килеп, тетри-тетри вә курка-курка ташны күтәреп, мәктүпне алды. Үз мәктүбе алынмыш икән, бу мәктүп аңа охшамаган иде.

Өйгә кереп, мәктүпне ачып, мондый сүзләрне укыды:

*«Гыйззәтлү Хисаметдин хәзрәтләре!*

*Мәктүбегездән аңлашылдыгына күрә, мәхәббәт вә гыйшыкыңызны белдергән булсаңыз да, бу гыйшыкыңызга ышанып карау мөмкин түгелдер дип уйлыйм. Чөнки куәтле вә чын мәхәббәт бер-беребезнең тышкы кыяфәтләребезне күреп кенә хасил булмас, сез тышкы күренешемне яраттыгыз, бәлки мин эчтән яманмын? Бәлки әхлаксызмын. Куәтле гыйшык икебезнең дә әхлак вә табигатебез беленгәч барлыкка килер, һәм никадәр әңгәмәләрегездән яхшы фикерле, Ислам сөюче булуыгызны аңласам да, сез минем әхлагымны вә табигатемне белмисез. Сезнең тугры кеше булуыгыздан ышанам ки, сез гашыйк булгансыз, ләкин гашыйк булгансыз тышкы кыяфәтемә. Мондый гыйшык исә ышанычлы түгел, шуңа күрә бер-беребезнең табигатьләре вә әхлаклары аңлашылмадыкча катгый җавап бирергә батырчылык итә алмыйм. Мәгълүмегез Хәнифә».*

Бу хатны укып, мелла уй-фикер дәрьясына батты. Әмма хатның эчтәлегеннән сизелгәнчә, мәхәббәткә катгый каршылык күренмәгәнлектән, мелла бераз юанды, ләкин мәхәббәт тарафы бераз көчәйде. Чөнки беренче: ихтирам күрсәтеп, Хәнифә ханым хатка җавап язган; икенче: мелланың гашыйк булуына да ышанган; өченче: җавабын шулай итеп язган ки, җавапка җавап язарга юл калдырган.

Әлеге хәбәрләшүдән соң Хисаметдин тиз көндә янә шәһәргә юнәлде, ләкин, шик чыкмасын өчен, бу юлы Габбас агайга төшмәде. Дусты Әбүзәр бәккә төште. Шулай да, ничек булса да, егерме бишенче казык төбенә мелла тагы мәктүп куйды. Бу мәктүбендә Хәнифәгә җавабы өчен рәхмәт әйтеп, соңра гыйшыклык белән тулып сибелгән сүзләре арасында игълан итте ки, Хәнифә ханым көтелмәгән бер вакыйгага хәзерләнсен.

Икенче мәктүп ирешдектән өч көн соңра, көн урталары кичкәч, Хәнифә туташ кече бүлмәдә тәрәзә төбендә тегү тегеп утыра иде. Кинәт урамнан тәрәзә янына вак-төяк сатучы бер венгр пәйда булды. Венгрның башында зур кара эшләпә, өстенә кара сюртук кигән. Бу венгр Хәнифә туташка эндәшеп, ярты-йорты русча сөйләп, инә-төймә алырга тәкъдим итте, вә янә диде: җепләр, оеклар, борын яулыклары кирәкмәсме? Венгрның тавышы Хәнифәгә бер таныш тавыш кебек ишетелде. Күзләре дә, тавышы да Хисаметдин мелланыкына охшаган. Шулай да зур кара сакал, озын мыеклар Хисаметдин мелланыкы кебек түгел. Хәнифә туташ башын тәрәзәдән чыгарып дикъкать иттектә, әлеге венгр татарча әкертен сөйли башлады: «Җаным, Хәнифә ханым, синең белән күзгә-күз күрешеп сөйләшүне йөрәгем тели».

Инде, хөрмәтле укучыларым, бу ялган венгр Хисаметдин мелла иде. Гыйшыклык дәрте шулай эшләргә мәҗбүр итте. Сюртук вә эшләпәләр тапмак меллага көч түгел, мыеклар, сакаллар вә кашлар куймак шәһәрдәге парикмахерның һөнәре иде. Туташыбыз, бердән, бу мелланы танып, һаман нишләргә белмичә аптырап вә югалып калды. Гашыйк вә гашый-

ка арасында аз гына тынлык булып алды. Шуннан соң ялган сатучы сабырсызланып: «Җаным, кил якынрак, сиңа сүзем бар», – дип әкертен генә дәште. Ике яшь бер-берсенә якынлаштылар. Сатучыбыз киндерен сүтеп үзе инә вә төймәләрен күрсәтер, үзе әкертен генә колактан колакка мәхәббәт сүзләре чәчәр. Төрле сүз арасында Хисаметдин мелла: «Газизә Хәнифә, синең ялгыз тышкы кыяфәтеңә түгел, шулай ук матур күркәм холкыңа гашыйк булдым», – диде.

– Каян белдең минем яхшы холкымны? – дип, назлы вә нечкә тавыш илә сорады Хәнифә.

– Синең хакта турылыклы кешеләрдән яхшы сүзләр ишеттем. Яшьлектән гыйлем вә укуны сөйгән кешенең әхлак вә фикерләренең яман булуы шөбһәледер. Бир җавап, миңа мәхәббәт итәсеңме?

– Итәмен, – сүзе Хәнифәнең авызыннан гүя ирексездән атылып чыкты. Бу сүз венгр сурәтенә кергән Хисаметдинга никадәр ләззәтле, никадәр хуш сүз иде ки, тәэсире колагыннан бөтен тәненә китте. Моннан соң ялган венгр Хәнифә туташка бер ядкяр чыгарып:

– Моны сиңа ядкяр-истәлек итәмен, – дип, алтын йөзек Хәнифәгә бирде.

– Нинди йөзегең нурлы, – диде Хәнифә.

– Синең йөзең кебек. Ки, багаек.

Хәнифә туташ көлә-көлә кияр:

– Бак, нинди чак килде, әйтерсең бармагыма үлчәнгән.

– Килешсә, бик хуп, – диде ялган венгр.

– Бик килешә, мин моны ерак яшерермен вә аулакта йөзегеңне чыгарып киеп вә карап сине исемә алып шатланырмын.

Шул вакыт Хәнифәнең анасы ишектән кереп:

– И кыз гына! Ни монда тубалчылар белән маташасың? Тиз бире кил, эш бар, – дип, Хәнифә туташны чакырып алды.

Ялган венгр исә үз юлына китте.

## V

Шул көн кич Әбүзәр бәкнең арендага алган фатирында бер җәмгыять булды. Бу җәмгыять өч кешедән гыйбарәт булып: бере Әбүзәр бәк, бере Хисаметдин мелла вә бере теләнче ятим Мохтар иде. Җәмгыятьнең тышкы яктан торышына карасаң, хәйран калырсың. Әбүзәр бәк бәһалы кара сукно сюртук, чалбар кигән. Алтын ука илә чигелгән тәкыясы вә алтын сәгатьләре мал иясе вә зур бәкләрдән иде кенә бер дәлил кеби күренерләр иде. Теләнче Мохтарның өстендә кырык ямаулы сары чикмән, пычрак чабаталары паркетлы идәнне пычратмышлар вә чуарламышлар. Хисаметдин мелланың өстендә яхшы сукно бишмәт, аягындагы читекләре яхшы килешерләр иде. Сорамак мөмкин ки, бу өч, бер-берсеннән аерылып торган кешеләр нидән берләшкәннәр соң? Бере бәк, гимназист, бере укымышлы мелла, берсе гади теләнче. Нидән алар бер-беренә ярашканнар? Нидән дуслашканнар? Сәбәбе будыр ки, бәк илә Хисаметдин мелланы милләт мәнфәгатен кайгыртуда булган уртак сыйфат якынайткан иде. Алар, татарны наданлык дәрьясыннан коткарып, гыйлемнәр илә нурландыру кирәк икәненә һәр икесе бер үк дәрәҗәдә ышаналар иде.

Ышану һәм фикер уртаклыгы булган кешеләр арасында якын дуслык барлыкка килүе билгеледер. Сәүдәгәр сәүдә уенда булган башка сәүдәгәр белән белешер, игенче игенче илә катнашыр һәм башкалар. Мохтарга килгәндә, бу зат үзе галим булмаса да, боларның милләт өчен тырышып йөрүләрен аңлады. Үзе белде ки, Мохтарны теләнеп йөрүдән яптырып тыюлары боларның милләтпәрвәрлегеннән иде. Чөнки дин кардәше сораnмак илә фәкыйрьлек бәласенә дучар булмасын дип яптырганлыкларын Мохтар яхшы аңлады. Сүз ачылгач, ябылу хакында да берәр сүз әйтик. Хисаметдин мелла, шәһәргә килеп, авылдашы Мохтарның теләнеп йөрүен күреп:

– Бу эштән яхшырак эш тапмадыңмы? Кил, кайт бу хәрәкәттән, – диде.

Мохтарның исә, бу сүзләргә илтифат итмичә, һаман теләнүдә дәвам итүен күреп, Хисаметдин Әбүзәр бәк белән киңәш итте. Соңра бу ике дус, «урлап йөри» дип, Мохтар өстеннән полициягә жалоба бирделәр вә, ялган шаһитлык итеп, аны полиция участогына яптырдылар. Мохтар, болай эшләүнең дин кардәшлеге өчен булганлыгын аңлап, аларга мәхәббәт белән карый башлады вә, алардан үрнәк алып, үзе дә милләт файдасына гайрәт вә тырышлык итәргә карар бирде. Кыскасы, бу өч кешене үз халкын ярату – милләтпәрвәрлек берләштерде. Милли патриотизм исә, гаҗәеп эшләргә сәбәпче булып, һәр олуг эшләрнең чыганагыдыр. (...)

Бәс, бу өч дус кызышып-кызышып сөйләшмәктә иделәр. Ятим Мохтар үзе турында болай диде:

– Мине теләнчелектән тыйдыгыз, бик рәхмәт сезгә. Моннан соңра бер кәсепкә тотынырмын, дусларым! Сездән бик гыйбрәтле сүзләр ишеттем, һай, ничек мин укымый калдым! Наданлык бөек бәладер.

– Наданлыкка карама, яхшы күңелле кеше булсаң, син дә файдалы булырсың, – диде Хисаметдин мелла.

– Нинди файда? Гыйлемем дә юк, милкем дә юк. Һич булмаса милкем булса иде, исламиятебез мәнфәгатенә һәрвакыт сарыф итәргә хәзер булыр идем.

– Тугры сүз, – диде Әбүзәр бәк, – тормышта иң зур куәт – акчадыр. Бу куәт илә милли мәгарифебез юлында күп эш кылырга мөмкин булыр иде.

– Әлбәттә, акча илә мәңгелек шөһрәт казанырга мөмкин. Ләкин корсак тутырудан башка бер нәрсәне белмәгән акча иясеннән ни файда килсен? Мондыйлар кешеләргә файда итүне уйларына да китермиләр. Шуның өчен алар күмелгәч үк онытылалар, – дип бәян итте мелла.

– Юк, дуслар, минем акчам күп булса иде, атымны онытмаслар иде, – диде Мохтар. – Шулай да бер морадым бар, бай булырга телим.

– Кәсеп ит, бай булырсың, – диде Әбүзәр бәк.

– Һәрбер кеше кәсеп итеп бай булуны теләр иде, ләкин бай була алмый, – дип җавап бирде Мохтар.

– Теләкнең теләге бар, чын күңел илә теләп, тырышлык илә кәсеп итсәң, бай була алырсың. Чөнки кеше гакылы бик куәтле нәрсәдер, – диде Әбүзәр бәк.

– Сүзең тугры, тырышып кара, – дип сүзгә кереште Хисаметдин. – Хәзрәте Расүл димеш ки, кем иҗтиһат итәр, ул табар.

– Син ни өчен соң иҗтиһат итеп тапмадың, – сорады ятим Мохтар.

– Мин байлык эзләмәдем, гыйлем эзләдем. Бераз таптым, әлхәмдүлилләһ.

– Сиңа бай булу мөмкиндер, – бәянга кереште Әбүзәр бәк, – хәзер сиңа 18 яшь. Бу яшьтән кискенлек вә әрсезлек илә байлык эзләсәң, бәлки табарсың, кеше гакылы ниләр кылмас!

– Мин сатуга керешер идем, ләкин бер монет кадәр дә акчам юк. – Егерме-утыз монет (сум) акча эш башламак өчен мин дә бирер идем, – диде Әбүзәр бәк.

– Юк, юк, Әбүзәр бәктән акча алма, кеше акчасы илә эш йөртү егетлек түгел, һәм дә эш файдасыз булып китәр, чөнки акчаның кадерен белмәссең, – диде Хисаметдин.

Бу сүзләр Мохтарга никадәр ачы килсә дә, мелланы тыңлап, Әбүзәр бәктән акчаны кабул итмәде.

Бу өч дус сөйләшә-сөйләшә күп вакыт утырдылар. Төн урталары җиткәч, Мохтар мөсафирханәгә кунарга китте. Юлда баемак хакында уйланыр иде, вә шул вакыт башында мондый фикер барлыкка килде: «Үз гайрәтем илә бәлки баермын, моның өчен миңа йөз монет кирәк. Аннан соңра эшләр уңайланыр. Әмма моны ничек казанырмын икән? Сабыр! Әбүзәр бәкнең бер белеш извозчигы бар, бәкнең тәкъдиме белән бу извозчикка хезмәткә керермен, әрсезлек вә кискенлек илә һәр көн берәр кәпик (тиен) тапсаң да, заман узу белән баемый калырга мөмкин түгелдер. Шун-

дый әрсезлек кирәк ки, бер кәпик тапмай көнең узмасын. Әмма мин көн дә кәпик түгел, егерме кәпик табармын, айда – алты монет, бәс елда 72 монет була. 72 дән йөзгә кадәр күп түгел. Аннан соңра эшләр куәтләнер. Кыскасы, баемак бик мөмкин, – дип, кискен карар бирде Мохтар.

## VI

Яз башының яхшы бер көнендә Бикбулат мулла хатыны белән Габбас агайга килеп төште. Шул уңай белән Габбас аганың өендә зур бер хәрәкәт-гөрелте купты. Габбас аганың хатыны Шәмси абыстай (асылда аты Шәмсекамәр иде, ләкин атын бозып Шәмси диләр иде) күптән бу мулланың килүен өмет итә иде. Чөнки халык арасында сүз бар иде ки, Гали бай угылына Хәнифәне сорарга Бикбулат мулланы башкода итеп җибәрә, имеш. Шунлыктан Шәмси абыстай, боларның килүен күргәч, гаять шат булды. Ни өчен шатланмасын, кызын шундый байга сорарга килгәннәр. Гали бай Җаватов кебек кешеләр бөтен губернага бер-ике генә булалар бит.

Шул уйдар белән иләсләнеп, Шәмси абыстай өйдәгеләргә кычкырына башлады:

– Тиз-тиз, кызым, яхшы гына киен, ризыклы булырсың, мөдәррис әфәнде хәзрәтләре үзе һәм дә абыстай килгән ич. – Шунда ук хезмәтчеләренә эндәшеп:

– Әй, сез, яшен кебек әйләнегез, кунакларга яхшы дикъкать итегез, – диде.

Габбас ага мөдәррис хәзрәтләрен хөрмәтләп-олылап каршылады. Шәмси абыстай аның хатынын каршылап үз бүлмәсенә кертте. Моннан соң кунакларга сыйлар, хөрмәтләр башланды.

Башта гадәтчә самавыр мәйданга чыкты. Ашханәдә гайрәт вә хәрәкәт купты: коймаклар, пәрәмәчләр бер-бер артлы пешә башладылар,

камырлар басылып, катламалар, кош телләре хәзерләнде. Хезмәтчеләр, ашчылар зур бер хәрәкәттә. (...)

Ниһаять, чәйдән соң Бикбулат мулла Гали байдан күндерелгәнлеген игълан итеп, Хәнифәне Сибгатулла әфәндегә хатынлыкка бирмәк хәерле булмасмы, дип әмер иткәндәй ныгытып әйтте. Аңа җавапта Габбас ага:

– Яхшы, хәзрәт, киңәшербез. Киңәшләшкәч, катгый җавап бирербез, – диде.

Тиз заман ашханәдә янә хәрәкәт купты: шурпалар, пылаулар кунаклар өчен кайнап-кайный, хәтта ки мөдәррис хәзрәтләре йортка йөрергә чыкканда, майлы ашларның исе ашханәдән борынына җитешеп, ләззәт хисләре кичереп, теле тирәсеннән төкерек чыкты. Өйдә барчасы шат, фәкать Хәнифә туташ кына үз бүлмәсендә ябылып, кайгылы торыр. Хәтта мулла хатыны моңа игътибар итеп:

– Ни өчен соң кызыгыз яныбызга чыкмый? – дип сорады. Шәмси абыстай моңа җавабында:

– Кыз кеше бераз ятсынадыр, гаеп түгел, абыстай, – диде. (...) Икенче көн Габбас ага башкодаларның тәкъдимен кире какмыйча:

– Икенче килүегезгә сүзне тәмамларбыз, – диде.

Вә шул хәлдә башкодаларны озатты. Габбас ага вә Шәмси абыстай бөек вә бай адәмнәр арасына кереп, кардәшлек вә руглыкка ирешәчәкләренә шат иделәр. Фәкать Хәнифә туташ, үзен Сибгатулла әфәндегә бирү морадларын аңлап, янә бик тирән борчуга төште. Үз-үзен Хисаметдинга яр итеп күз алдына китермәктә иде. Чөнки Хисаметдин бу көннәрдә егерме бишенче казык төбенә куйган хатында белдерде ки, Хәнифәгә өйләнү мorады бар, эш бары Хәнифәнең теләгеннән генә торадыр.

Әмма шул вакыт ике яшьнең теләкләренә каршы Гали бай Җаватовтан башкодалар килде. Бу башкодалар Хәнифә туташка үткен пычак кебек күренделәр. Кискен пычактан да ачы нәрсә шул иде ки, атасы-анасы аны байга бирергә тырышалар. (...)

Кичке ашлар ашалды, өйдә барчасы ятып, каты йокыга талдылар. Бары Хәнифә туташ кына уяу хәлдә иде. Стенага тагылган сәгатьләр инде берне уздылар, яшь кыз, йомшак түшәгеннән торып, төрле якларга карап, һәммәсе йокыда икәнлекләрен белгәч, лампасын яндырып, каләм, кәгазь табып, мондый хат язды:

*«Хисаметдин менла әфәнде!*

*Миңа өйләнү морадыгызны хатыгыздан күреп сөендем, сезгә хәләл улмак миңа бик хуштыр, ләкин морадыбызга ирешүебез бик шикле булып китте. Чөнки Бикбулат мулла мине Сибгатулла әфәндегә сорарга бу көннәрдә килгән иде. Һәм дә атам-анам шат улып, мине аңа бирәләр. Мин никадәр каршылык күрсәтсәм дә: «Бармасаң, ирексезләп бирербез», – диләр. Шуңа күрә мин кайгыдан нишләргә дә белмим. Шулай да бу юлларны сезгә язмак илә күңелем бераз юаныч тапты. Җаннан сезгә гашыйка булып калучы Хәнифә».*

Бу мәктүпне язып, туташымыз, әкертен атлап, бакчага теге казык янына чыкты. Чөнки менланың мәктүбендә җавапны тап шул кичтә куярга кирәклеге әйтелгән иде. Казык янына җиткән вакыт Хәнифә туташ бердән туктады, төн бик тын иде, һичбер хәрәкәт ишетелми. Бары тик якындагы бер кечкенә чишмә челтерәп агадыр. Хәнифә туташның колагына бер хәрәкәт ишетелде. Төн бик караңгы түгел иде. Яшь кыз еракта бер кара нәрсә хәрәкәт иткәнен күреп, күңеленә курку төште. Яхшырак дикъкать итеп караса, белде ки, бу шәүлә адәмдер. Бу кеше, туташны күргәч, тизрәк атлый башлады. Хәнифә туташ кача башлаган иде, әлеге адәм:

– Курыкма, җаным, үзем киләмен! – дип дәшкәч, туташ бу кешене танып туктады. Бу кеше сөйгәне Хисаметдин икән. (...)

Менламыз, Хәнифәнең янына тугры килеп, диде:

– Ни өчен озак чыкмадың, саумысың, җаным?

– Әлхәмдүлилләһ! Әмма күп тору мөмкин түгел, күрешүебез миңа да хуш исә дә, куркамын ки, белмәсеннәр! – назлы, йомшак тавыш илә диде Хәнифә туташ.

– Курыкма, мин сине тиз җибәрмимен, җаным! – диде менла вә, бер казыкны җирдән суырып чыгарып, бакчага керде. (...)

– Син хәзер җавап куярга килә идең, мин сагалап көттем, – диде Хисаметдин.

– Бу хатымда мин сиңа бер яңа вакыйга турында белдермәкче булган идем, мине Сибгатулла Җаватовка бирәләр.

– Ничек ул булыр, кеше бит агач түгел, алып биреп булмый.

– Ничек булсын, мин хатымда да яздым, беләсеңме, Бикбулат мулла хатыны белән Гали байдан баш кодалый килгәннәр иде, бүген-иртәгә эшне тәмам итәчәкләр.

– Җаным, безне кем аерыр? Мәхәббәтебез шул кадәр көчле ки, безне ни Гали бай, ни атаң-анаң аера алмаячак.

– Аны син сөйлә, атай-анай әйтәләр ки, бармасаң, көчләп бирербез. Сөймәгән кешегә яр булу миңа агудыр.

– Җаным, син миңа яр булырсың. Минем мәхәббәтемне һичкем җиңә алмас. Мин сине элек әдәп өчен яхшылык белән сорармын. Әмма бирмәсәләр, миңа Аллаһ биргән ихтыяр куәтемә һичнәрсә каршы килә алмас. Бу сүзләрне әйткәндә егетнең күзләре ялтырады, тавышы бераз тетрәде, хәтта туташ бу каһәрле тавыштан бераз куркынды. Моны аңлап, менла, Хәнифәгә сөеп карап, болай диде:

– Курыкма, син мине янә элеккечә сөячәксең, ачуым килгәндә мин каһәрлемен, ләкин ачуым атаң-анаңа килде.

– Шәригатьчә дә көчләп бирү мөмкин түгел? Дөресме? – дип сорады Хәнифә туташ.

– Кияүгә чыгу эшендә кызларга тулы ихтыяр биреләдер. Алар, шәригатькә каршы килеп, яман булсалар, без дә яман булырбыз. Безнең

ихтыяр вә хөрриятебезне-ирегебезне ала алмаслар. Җаным! Кеше тормышында бер бәһале вә яхшы нәрсә – хөрриятттер. Без үз хөрриятебезне саклый белербез.

– Хөрриятсез яшәү көч вә газап-кысынкылык икәнен мин дә беләм, – диде Хәнифә туташ.

Бу сүзләр менланың күңеленә хуш килеп, диде:

– Дөрес әйттең, җаным! Фикерләрең минеке белән уртак икән.

– Болай булгач, бер-беребездән аерылмабыз! – диде Хәнифә туташ.

Зәвык вә сафа чигеп, ике гашыйк таң яралганны белми калдылар.

– Ничек урыныма кереп җитәрмен икән? Әни-фәлән намазга тормасын, җибәр, җаным, сәламәт бул! – диде Хәнифә туташ.

– Сәламәт бул! – диде Хисаметдин.

Яшьләр саубуллашып аерылыштылар. Менлабыз бакчадан чыгып юк булды. Хәнифә туташ, аяк бармакларына басып, үз бүлмәсенә узды.

*(Дәвамы бар)*